2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ЗАКОНЛЫ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ҮТӘҮ ТУРЫНДА

Д О К Л А Д

КАЗАН – 2017

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ.....5

1 БҮЛЕК. 2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1.1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшчәнлеге.....9

1.1. Работа Уполномоченного по правам ребенка с обращениями граждан 15

1.2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге 16

1.3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашуы.....28

1.4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы 37

1.5. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасында бала мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм хокукларын яклау механизмын камилләштерүгә ярдәм итү эшчәнлегенең төп юнәлешләре 41

1.6. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатендә Россия регионнары белән хезмәттәшлегенең һәм халыкара хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре.....56

1.7. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый агарту эшчәнлегенең төп юнәлешләре.....69

2 БҮЛЕК. 2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАР ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ

2.1. 2016 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр.....86

2.2. 2016 елда Татарстан Республикасында балаларның хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар 92

2.3. 2016 елда халыкара, федераль һәм республика законнарындагы бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсенә караган яңалыкларга күзәтү 99

2.4. 2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә ясалган анализга нигезләнеп, Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләргә мониторинг.....112

3 БҮЛЕК. 2016 ЕЛДА ТОРМЫШ КӨНКҮРЕШЕНЕҢ ТӨП ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫНЫҢ САКЛАНУЫ

3.1. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү 128

3.1.1. Балаларның тышкы сәбәпләр (бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр) аркасында үлүе 128

3.1.2. Рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклану хокукын тәэмин итү 149

*3.1.3. Тискәре мәгълүматтан яклау хокукын тәэ*мин итү 160

3.2. Баланың сәламәтлек саклауга һәм үсешкә хокукын тәэмин итү 169

3.2.1. Балалар үлеменә гомуми анализ 169

3.2.2. Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ 173

3.2.3. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре 185

3.2.4. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру 199

3.3. Баланың гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукын тәэмин итү 212

3.3.1. Начар гаилә проблемалары 213

3.3.2. Социаль ятимлек проблемалары 226

3.3.3. Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру 230

3.3.4. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә каршылыклар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр 239

3.4. Мәгариф өлкәсендә баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау 245

3.4.1. Мәктәпкәчә белем 245

3.4.2. Гомуми белем 251

3.4.3. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү 270

3.5. Социаль тәэмин ителешкә хокукны гамәлгә ашыру 283

3.6. Баланың торак һәм башка мөлкәт хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү 289

3.6.1. Ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның торак хокукларын тәэмин итү 290

3.6.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын тәэмин итү 295

3.6.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокуклары 300

3.6.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәт хокукларын яклау 303

ЙОМГАКЛАУ 308

КЕРЕШ

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Закон) 3 статьясында каралган Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү буенча эшләрнең торышына анализ ясау кысаларында, Законның 13 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) ел саен үз эшчәнлеге турында һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше хакында доклад әзерли.

Әлеге доклад Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан әзерләнгән еллык докладларның җиденчесе, ул 2016 ел йомгакларына багышлана. Докладта узган елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегенең төп юнәлешләре тасвирлана, шулай ук БМОның Бала хокуклары турында конвенциясендә һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турында гамәлдәге законнарында гарантияләнгән бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү эшләренең торышына бәйсез анализ ясала һәм бәя бирелә.

Доклад рәсми дәүләт статистикасы мәгълүматларын, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил соратуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары, җирле үзидарә органнары тапшырган мәгълүмат-аналитика материалларын, гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен, республиканың төрле балалар учреждениеләрендә үткәрелгән тикшерүләр һәм аларга барып кайтулар нәтиҗәләрен, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым мәсьәләләре турында фикер алышынган киңәшмәләр, очрашулар, конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр» барышында Вәкаләтле вәкил алган мәгълүматларны өйрәнүгә, анализлауга һәм гомумиләштерүгә нигезләнде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлеген күрсәткәндә, үзе игътибар иткән һәм анализлаган мәгълүматлар файдаланылды.

Доклад структурасы керештән, өч бүлектән һәм йомгаклау өлешеннән гыйбарәт.

Беренче бүлектә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең төп эшчәнлек юнәлешләре турында мәгълүмат бирелә.

Икенче бүлектә Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә гомуми мониторинг ясала. Бу бүлектә

Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елда бала хокукларының үтәлешенә кагылышлы гомуми бәя бирелә, анда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен иң яхшы яктан тәэмин итү максатларында республикада күрелгән чаралар, ясалган адымнар, башлангычлар, төп демографик тенденцияләр күрсәтелә, федераль һәм республика законнарындагы турыдан-туры балалар яшәешенә кагылышлы төрле аспектларга йогынты ясый торган яңалыклар анализлана. Монда ук, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 2016 елда кергән граждан мөрәҗәгатьләренә ясалган анализга нигезләнеп, балалар өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләр билгеләнә.

Өченче бүлектә балалар тормышының төп өлкәләрендә балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә кагылышлы вәзгыятьнең Татарстан Республикасындагы торышына анализ ясала. Төп урынны республикада балалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру хакында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хисап чорында үз эшчәнлеге барышында билгеле булган проблемалы мәсьәләләргә характеристика алып тора. Мондый характеристика Бала хокуклары турында БМО Конвенциясендә беркетелгән төп хокукларның төрләре буенча тәкъдим ителә:

баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга, иминлеккә хокукын тәэмин итү;

баланың сәламәтлек саклауга һәм сәламәт үсүгә хокукын тәэмин итү;

баланың гаиләдә яшәүгә һәм тәрбияләнүгә хокукын тәэмин итү;

баланың мәгариф өлкәсендә хокукларын тәэмин итү;

баланың социаль тәэминатка хокукын тәэмин итү;

баланың тораккa һәм мөлкәткә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү.

Бу бүлектә хокуклары бозылу ихтималы зур булган төркемнәргә караган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә аерым игътибар бирелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дөрес мәгълүмати-аналитик белешмәләр биргән һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үзенә йөкләнгән бурычларын үтәүдә булышлык күрсәткән өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары башлыкларына зур рәхмәтен белдерә.

Доклад Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ

БҮЛЕК 1

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең төп юнәлешләре «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – Закон) билгеләнгән.

Регионда гы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешен, һичшиксез, ***хокук яклау эшчәнлеге*** тәшкил итә. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, тиешле органнарның һәм учреждениеләрнең эшчәнлеген тикшерү, суд процессларында катнашу буенча алып барыла торган эш дәүләт яклавының нәтиҗәле системасын булдыру һәм Татарстан Республикасында бозылган бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызу өчен башкарыла.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшенең мөһим өлешен ***экспертиза-аналитика эшчәнлеге*** алып тора. Аны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында һәм тулаем Россия Федерациясендә балалар хәлен яхшыртуны максат иткән кайбер чаралар гамәлгә ашырыла: бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча гамәлдәге законнарны, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау механизмнарын камилләштерү, Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү буенча эшнең торышына анализ ясау, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлегендә ярдәм күрсәтү, балалар мәнфәгатьләрендә Россия регионнары арасындагы һәм халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру.


Законда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аеруча әһәмиятле функцияләренең берсе итеп агарту эшчәнлеге билгеләнгән, моңа бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча халыкны, шул исәптән балаларны, хокукый агарту, консультация ярдәме күрсәтү керә.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында документлар әйләнеше Татарстан Республикасының Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында башкарыла (алга таба – БВЭДӘС).

2016 елда документлар әйләнешенең гомуми күләме 7 705 берәмлек (2015 елда – 5 889 берәмлек) тәшкил итте.

1 нче диаграмма

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының гомуми документлар әйләнеше




1.1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшчәнлеге

2016 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 1 792 мөрәҗәгать керде. Әлеге сан 2015 елга караганда 65 мөрәҗәгатькә (4% ка) күбрәк.

2 нче диаграмма


2011-2016 елларда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең динамикасы



2016 ел дәвамында гражданнарның мөрәҗәгать итү динамикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына гражданнардан ай саен уртача 144 мөрәҗәгать керә (2015 елда – 139). Шул ук вакытта шикаятьләр белән эшләгәндә Аппаратның бер хезмәткәренә һәр айда уртача 48 мөрәҗәгать туры килә.

3 нче диаграмма

2016 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы



Законда беркетелгән «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегеннән һәркем файдалана ала» дигән принципны гамәлгә ашыру максатыннан Аппаратта граждан мөрәҗәгатьләре белән эш итүнең оештырылу рәвеше гражданнарның квалификацияле ярдәм алуы өчен шактый киң мөмкинлекләр бирә.

4 нче диаграмма


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнарның мөрәҗәгать итү тәртибе



Мөрәҗәгать итү рәвешенә килгәндә, гражданнардан алына торган мөрәҗәгатьләрнең күп өлеше язмача була. Шул рәвешле 2016 елда кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 1 062 (61,4%) мөрәҗәгать язмача, 667 (38,6%) – телдән алынды. Шул ук вакытта язма мөрәҗәгатьләргә 2016 елда туры килгән өлеш, 2015 елгы белән чагыштырганда, артты (2015 елда язма мөрәҗәгатьләр 56,5%, телдән 43,5% тәшкил итте).

5 нче диаграмма

2011-2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы *(мөрәҗәгать итү рәвеше буенча)*




Язма мөрәҗәгатьләрнең керү ысулына килгәндә, 2016 елда, 2015 елдагыча, өстенлек бирелгән ысул булып хатларны электрон элемтә чаралары аша алу калды. Шулай, узган чорда 1 062 язма мөрәҗәгатьтән бары тик 277 (26,1%) мөрәҗәгать (2015 елда – 243 (26,0%) кәгазьдә алынды, калган 785 мөрәҗәгать (73,9 %) (2015 елда – 74,0%) – электрон элемтә чаралары аркылы.

Телдән мөрәҗәгатьләрнең керү ысулы буенча төп өлеше (78%, яки 521 мөрәҗәгать), гадәттәгечә, шәхси кабул итүләр барышында каралды, калган 146 мөрәҗәгать (22%) телефон аша алынды.

6 нчы диаграмма

2011-2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы *(керү рәвеше буенча)*



2016 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итүләр 104 тапкыр оештырылды һәм үткәрелде, шулардан 53 кабул итүне Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил башкарды, моңа өстәмә рәвештә Аппарат хезмәткәрләре атна саен барлыгы 51 кабул итү уздырды.

Шулай итеп, турыдан-туры Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил уздырган 53 шәхсән кабул итүдән:

23 кабул итүне Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үзе генә үткәрде;

26 кабул итүдә федераль һәм республика дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре катнашты;


21 кабул итү республиканың муниципаль районнарына, шәһәр округларына чыгып үткәрелде;

2 кабул итү учреждениеләргә барып уздырылды;

2 кабул итү Россия Федерациясе Президентының Җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсендә үткәрелде.

7 нче диаграмма


2013 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең гражданнарны шәхси кабул итүе



Шәхси кабул итүләр вакытында барлыгы 521 граждан мөрәҗәгать итте: 303 кешене Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кабул итте, тагын 219 кешегә Аппарат хезмәткәрләре ярдәм күрсәтте һәм консультацияләр бирде.

8 нче диаграмма

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре кабул иткән гражданнар саны




Гражданнарга юридик консультацияләр мөмкин булган кадәр күбрәк күрсәтелсен һәм аларның хокукларын яклансын өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, республика муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына, шулай ук төрле учреждениеләргә барып, гражданнарны ***күчмә кабул итүләр*** уздыру тәҗрибәсен 2016 елда да дәвам итте.

Гражданнарны 25 күчмә кабул итүдән 21 кабул итү Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль районнарында (шәһәр округларында) оештырылды (2011 елда –4, 2012 елда – 9, 2013 елда – 14, 2014 елда – 17, 2015 елда – 19 районда): Апас, Әгерҗе, Актаныш, Аксубай, Алексеевск,Әтнә, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Кайбыч, Мамадыш, Менделеевск, Яңа Чишмә, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Спас, Теләче, Чирмешән муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә.

Карта

2011-2016 елларда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең муниципаль районнарда (шәһәр округларында) күчмә кабул итүләре



-2011 год (4)
-2012 год (9)
-2013 год (14)
-2014 год (17)
-2015 год (19)
- 2016 год (21)

Шулай итеп, 2016 елда гражданнарны күчмә кабул итүләр республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының яртысында диярлек (47%) үткәрелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, моңа өстәп, тагын ике мәртәбә ябык типтагы учреждениеләрдә гражданнарны күчмә кабул итте: «Пермь крае буенча Россия ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесендә һәм «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус уку-тәрбия учреждениесендә.

Берләшкән (тематик) кабул итүләр гражданнарны кабул итүнең иң нәтиҗәле формасы буларак үзләрен расладылар. 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнарны түбәндәгеләр белән 26 берләшкән кабул итү булды:



сәламәтлек саклау өлкәсендә балаларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры Г.Ю. Вафин белән (20.12.2016);



эш башкаруны гамәлгә ашырганда балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен иң яхшы тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе Р.М. Ильясов белән (08.11.2016);

Чаллы шәһәрендә медицина-социаль экспертиза узу һәм реабилитация чаралары белән тәэмин итү өлкәсендә бала хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча «Татарстан Республикасы буенча Баш медицина-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе җитәкчесе Р.Х. Низамов белән (12.07.2016);



«Пермь крае буенча Россия ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесендәге балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча Пермь краенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.В. Миков белән («Пермь крае буенча Россия ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесендә 15.03.2016);



балаларның хокукларын яклау һәм тәэмин итү мәсьәләләре буенча Алабуга муниципаль районында Татарстан Республикасы прокуроры урынбасары Г.С. Галимов белән (25.10.2016);



мәгариф өлкәсендә балаларның хокукларын яклау мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе Г.З. Габдрахманова белән (27.12.2016);



Алексеевск, Спас, Балык Бистәсе муниципаль районнарында җинаять корбаннары булган балаларның һәм җинаять кылуда шикле балигъ булмаганнарның хокукларын тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары А.С. Әхмәтшин белән (15.09.2016; 12.12.2016; 13.12.2016);



республиканың Апас һәм Кайбыч муниципаль районнарында эш башкаруны гамәлгә ашырганда балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен иң яхшы тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Е.Ю.Степанова белән (09.06.2016);



Чүпрәле муниципаль районында эш башкаруны гамәлгә ашырганда балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен иң яхшы тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары С.С.Плющий белән (15.11.2016);



Аксубай (13.09.2016), Яңа Чишмә һәм Чирмешән (01.11.2016), Теләче һәм Әтнә (06.12.2016) муниципаль районнарында балаларның хокукларын яклау һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы прокуратурасының балигъ булмаганнар эшләре һәм яшьләр турындагы законнарның үтәлешенә күзәтчелек бүлеге башлыгы А.Ф. Хөсәенов белән;



республиканың 21 муниципаль районында һәм 2 учреждениесендә Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән (23 кабул итү);



«Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус укытәрбия учреждениесендә «Реабилитация һәм адаптация үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры А.Г. Гайнетдинов белән (23.11.2016).

2016 елда күчмә кабул итүләр кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 145 кеше, шуларның 115 кешесе берләшкән кабул итүләр вакытында мөрәҗәгать итте.

2016 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә алынган язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрнең барысы да законнарда билгеләнгән тәртиптә каралды.

1.2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының, Татарстан

Республикасы территориясендә урнашкан теләсә-кайсы оешманың, аларның оештырылу-хокукый рәвешләре һәм милек рәвешләре нинди булуга карамастан, һәм аларның вазыйфаи затларының эшчәнлеген алар тарафыннан бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тану һәм үтәү күзлегеннән чыгып тикшерүдән гыйбарәт.

2016 ел дәвамында тикшерү чараларын үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булды:

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә гражданнардан килгән шикаятьләр;

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үз инициативасы;

бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары турындагы хәбәрләр һәм мәгълүмат.

Законнар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тикшерү чараларын мөстәкыйль үткәрү хокукын гарантияли. Һәм тикшерүләрнең күбесе, аерым алганда, учреждениеләргә үткәрелә торганнары, шулай уздырыла да. Моның белән бергә, Законда каралганча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклауның гамәлдәге чараларына өстәмә рәвештә алып барыла, балаларның хокукларын яклауны һәм бозылган хокукларын кире кайтаруны тәэмин итүче башка дәүләт органнарының компетенциясен бетерми һәм аларны яңадан карауны таләп итми. Моны искә алып, шулай ук контроль-күзәтү чаралары нәтиҗәләренең дөрес, тулы, объектив һәм сыйфатлы булсын өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тикшерүләрне компетентлы дәүләт органнары һәм аларның вазыйфаи затлары белән берлектә уздырырга хокуклы. Шуңа күрә тикшерү эшләренә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәттәшлек турында имзаланган килешүләргә таянып, тормышның билгеле бер өлкәләрендә күзәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль дәүләт хакимияте органнарының республикадагы территориаль бүлекләрен һәм ведомство контроле рәвешендә күзәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган республика дәүләт хакимиятенең тармак органнарын актив җәлеп итә.

Тикшерүләр алымына килгәндә, тикшерү эшчәнлеген урыннарга чыгып яисә тиешле документларга экспертиза ясау һәм аларны өйрәнү (документларны тикшерү) нигезендә оештыру тәҗрибәсе бар. 2016 елда барлыгы 147 тикшерү (2015 елда – 85) урынга чыгып оештырылды һәм үткәрелде.

Тикшерү эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү һәм алга таба аларны булдырмау турында 103 бәяләмә бирелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча тикшерүләр дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының, оешмаларының һәм вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата гражданнарның шикаятъләрен карау кысаларында үткәрелде. 2016 елда шундый 409 шикаять алынды, аларның һәрберсе тиешле дәрәҗәдә тикшерелде. 213 шикаять буенча тикшерүләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан башка компетентлы дәүләт органнары белән берлектә оештырылды:

116 тикшерү - территориаль федераль дәүләт хакимияте органнары белән берлектә;

88 тикшерү – ведомство контроле рәвешендә республика дәүләт хакимияте органнары белән берлектә;

28 тикшерү – җирле үзидарә органнары белән берлектә.

2016 елда гражданнар шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 58% очракта балаларның хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында квалификацияле консультацияләр һәм аңлатмалар бирелде, 42% очракта (170 шикаять) баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда булышлык күрсәтелде (2011 елда – 8%, 2012 елда – 15%, 2013 елда – 28%, 2014 елда 34%, 2015 елда – 35%), шулардан 77 % очракта мәсьәләнең асылы буенча уңай карарлар кабул ителде.

Мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән фактларны һәрьяклап һәм объектив өйрәнү өчен 15 очракта шикаятьләр учреждениеләргә һәм яшәү урыны буенча гаиләләргә чыгып оештырылды. Моннан тыш, ата-аналарның үз бурычларын тиешенчә үтәмәүләренә бәяле рәвештә балаларның гаиләдә начар яшәүләре турындагы кайбер хәбәрләр шул гаиләләргә барып тикшерелде. Мондый тикшерүләрнең күбесе опека һәм попечительлек органнары, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләр, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокуклары буенча муниципаль комиссияләр вәкилләре белән берлектә үткәрелде.

Гражданнар шикаятьләре буенча уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокуклары бозылу турында 59 бәяләмә әзерләде һәм тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар исеменә юллады, алар арасында:

5 – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына;

1 – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына;

1 – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

1 – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына;

1 – «Лето» балаларның һәм яшьләрнең сәламәтләнүен, ялын һәм шөгыльләнүләрен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт учреждениесенә;

19 – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлекчәсенә;

2 – дәүләткә карамаган балалар оешмалары җитәкчеләренә;

1 – предприятие җитәкчесенә;

28 – республиканың түбәндәге муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына:

Арча муниципаль районы (1 бәяләмә),

Балтач муниципаль районы (1 бәяләмә),

Биектау муниципаль районы (1 бәяләмә),

Лениногорск муниципаль районы (1 бәяләмә),

Зеленодольск муниципаль районы (1 бәяләмә),

Нурлат муниципаль районы (1 бәяләмә),

Яңа Чишмә муниципаль районы (1 бәяләмә),

Алабуга муниципаль районы (1 бәяләмә),

Ютазы муниципаль районы (1 бәяләмә),

Чистай муниципаль районы (2 бәяләмә),

«Чаллы шәһәре» шәһәр округы (4 бәяләмә),

«Казан шәһәре» шәһәр округы (13 бәяләмә).

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***үз инициативасы белән*** республиканың төрле төрдәге һәм ведомство буйсынуындагы 75 балалар учреждениесенә (2015 елда – 69 учреждениегә) күчмә тикшерүләр үткәрде.

Авыр тормыш шартларында калган балаларның, ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше булуны исәпкә алып, әлеге төркемгә керә торган *балалар өчен махсуслаштырылган учреждениеләр эшчәнлеге* хезмәтнең махсус контроленә алына. Болар – ятимнәр өчен учреждениеләр (балалар йортлары, бәләкәч йорты, ятимнәр өчен интернат мәктәпләр) һәм социаль приютлар. 2016 ел дәвамында республикадагы 13 ятимнәр учреждениесенең һәм 18 социаль приютның барысына да төрле тикшерүләр үткәрелде.


Тикшерүләр вакытында, иң беренче чиратта, түбәндәгеләрдә тәрбияләнүче балаларны тоту, тукландыру, тәрбияләү, дәвалау, реабилитацияләү, укыту, ял итү шартлары, аларның хокуклары тәэмин ителеше өйрәнелде:

12 балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютта;

«Акылга зәгыйфь балалар өчен Югары Утар балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә;

«Махсуслаштырылган республика бәләкәч йорты» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге бүлекчәләрендә.





Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында 10 бәяләмә юлланды.

Моннан тыш, балигъ булмаганнарга карата көч куллануны, балаларга карата көч белән мәҗбүр итү гамәлләре белән катнаш җинаятьләр кылуны профилактикалау мәсьәләләренең мөһимлеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2016 елның 9 июнендәге 33082-МР номерлы йөкләмәсен үтәү максатыннан 2016 елның август-октябрь айларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче балалар йортларының, ятим балалар өчен интернат мәктәпләрнең, социаль приютларның эшчәнлегенә, *балаларга карата көч куллану һәм рәхимсезлекләр кылу фактларын ачыклау өчен*, *комплексы ведомствоара тикшерүе* оештырылды.

Тикшерү чараларын үткәрүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатында ведомствоара эшче төркемнәр төзелде, алар составына Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекчәләре, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасында Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләре, мәгариф һәм социаль яклау, яшьләр сәясәте системаларының психология-педагогика хезмәтләре вәкилләре керде.

Тикшерү чараларын үткәргәндә төп игътибар түбәндәгеләргә бирелде:

1) балигъ булмаганнарга карата көч куллану һәм рәхимсезлекләр кылу фактларын ачыклау өчен, учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләр арасында тестлар эшләүгә;

2) учреждениеләр администрацияләренең суд хөкеме, шул исәптән кире алынган һәм үтәлгән суд хөкеме һәм (яки) җинаятькә бәйле эзәрлекләү булуга (булмауга) йә аерым бер җинаятьләр өчен җинаятькә бәйле эзәрлекләү туктатылуга хезмәткәрләрне үз вакытында тикшерүнең

мәҗбүри булуы өлешендә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының таләпләре үтәлешен анализлауга.


Социаль приютларда балаларга тикшерүләр үткәрүнең объективлыгын арттыру өчен балаларга тест ясатуны мәгариф системасының психология-педагогика хезмәтләре башкарды. Мәгариф системасы учреждениеләрен (балалар йортларын, интернат йортларны) тикшерүне социаль яклау системасының охшаш хезмәтләре оештырды.

Әлеге төр тикшерүләр барлыгы 28 учреждениегә үткәрелде: республика территориясендә эшләүче балалар һәм яшүсмерләр өчен 18 социаль приютның барысына да, 8 балалар йортының барысына да һәм ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен 2 интернат мәктәпкә.

9 нчы диаграмма

Тикшерүләр үткәрелгән халык

725 бала тикшерелде
(тәрбияләнүчеләрнең гомуми саныннан 86%)




Әлеге тикшерүләрнең нәтиҗәләре 2016 елның 26 октябрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе утырышында тәкъдим ителде.

2016 елның сентябрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның Россия Федерациясе Президентының «Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның эшчәнлеге турында һәм аларга ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны урнаштыру хакында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары (алга таба – РФ Президентының 481 номерлы карары) таләпләренә туры килүен бәяләү буенча *эксперт төркеме эшендә* катнаштылар. Әлеге эксперт бәяләве кысаларында республиканың 13 ятимнәр учреждениесе тикшерелде (Аппарат хезмәткәрләре 10 оешманы тикшерү эшендә катнашты).

10 нчы диаграмма

РФ Президентының 481 номерлы карары таләпләренең үтәлеше буенча үткән тикшерүләр



Тикшерүләр барышында күрсәтелгән учреждениеләрдә түбәндәгеләрнең оештырылуы өйрәнелде:

балаларның гаиләдә тәрбияләнү принцибы буенча яшәве (шул исәптән: тәрбия төркемнәре каршында ризык ашау һәм әзерләү бүлмәләре булу; социаль җайлашу өчен шартлар булу; индивидуаль киңлекне, шәхси әйберләрне алган тоткарлык булмауны оештыру, мондый әйберләре булу; гаилә традицияләрен булдыру буенча чаралар оештыру; һәркемнең үз туган көнен бәйрәм итү);

балаларны оешмага кабул итү (шул исәптән баланың ятим балалар өчен оешмада баланың вакытлыча булуын оештыру өчен шартларның булуы);

тәрбияләнүчеләр хокукларын тәэмин итү (шул исәптән индивидуаль үсеш һәм тормыш итү планнарын төзү, ятим балалар өчен оешмаларның администрациясе һәм хезмәткәрләре гамәлләре (гамәл башкармаулары) нәтиҗәсендә балаларның хокуклары бозылу; СанПиН үтәлү турында Россия кулланучылар күзәтчелеге акты булу; оешмаларга чит кешеләр килүне теркәү системасы булу; тәрбияләнүчеләр әйтмичә киткән очракта, оешма хезмәткәрләренең гамәлләре регламентлары булу; балага карата рәхимсезлек кылу яки көч куллану фактларын ачыкларга барлык персоналны өйрәтү турында белешмәләр; көч куллануга яки рәхимсезлек кылуга дучар ителгән балалар белән реабилитация эшен оештыру турында белешмәләр);

балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыруга ярдәм күрсәтү;

оешмага ата-аналар гаризасы белән урнаштырылган тәрбияләнүчеләр белән эшләү;

тәрбияләнүчеләрнең уку һәм ял вакытлары.

Үткәрелгән эксперт бәяләве нәтиҗәләре буенча профильле региональ министрлыклар тарафыннан ятим балалар өчен һәр оешма буенча «юл картасы» эшләнде, аңа аларның эшчәнлеген үстерү чаралары, шулай ук РФ Президентының 481 номерлы карары таләпләренә туры килмәве ачыкланган очракларны бетерү чаралары керә.

Моннан тыш, тикшерү барышында «Казан шәһәре Идел буе районы балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесендә, «Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан 11 нче интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә, «Акылга зәгыйфь балалар өчен Дәрвишләр бистәсе балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә тукланууны оештыру өлешендә хокук бозу очраклары теркәлде. Шулай ук «Акылга зәгыйфь балалар өчен Югары Утар бистәсе балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә тәрбияләнүчеләрнең медицина тернәкләнүе хезмәт күрсәтүләрен алуга хокукларын тәэмин итүне тиешенчә оештыруга карата искәрмәләр бирелде. Моңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасында Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы исеменә тиешле бәяләмәләр җибәрелде.

Җәйге сәламәтләндерү кампанияләрен әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләре, гадәттәгечә, җәйге чорда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең махсус контроленә алына. 2016 елда балалар сәламәтләндерү лагерьләрендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре тәэмин ителешен һәм үтәлешен тикшерү максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре республиканың 21 районында шәһәр читендә урнашкан 35 балалар лагерьләрендә булдылар.






Тикшерүләр барышында ачыкланган хокук бозулар, шул вакытта искәрмәләр бирергә нигез булган шартлар һәм аларны бетерүгә караган

тәкъдимнәр лагерьләр җитәкчеләренә һәм аларның гамәлгә куючыларын җиткерелде, аларның күбесе тикшерүләр барышында ук яки тиз арада бетерелде.

Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча 13 лагерьдә хокук бозуларның еш булуы ачыкланды, моңа бәйле рәвештә гамәлгә куючылар исеменә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тиешле бәяләмәләре җибәрелде, аларда җибәрелгән хокук бозулар күрсәтелеп, ачыкланган хокук бозуларны бетерүгә юнәлтелгән чаралар күрү таләп ителде.

11 нче диаграмма

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмәләр җибәрелгән лагерьләр исемлеге



Түбәндәге лагерьләрдә иң тупас хокук бозулар ачыкланды:

Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» дәүләт сәламәтләндерү лагерендә,

«Кояшлы дөнья» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Надежда» балалар сәламәтләндерү лагерендә (гамәлгә куючысы – «Берсут» ачык акционер җәмгыяте)

«Язгы каникуллар» балалар программалары студиясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Сталкер» балалар сәламәтләндерү лагерендә.

Моның белән бергә үзе үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча башка тикшерү-күзәтчелек органнары тарафыннан тирәнтен ведомство тикшерүләрен үткәрүне тәкъдим итү тәҗрибәсе дәвам иттерелде.

Шулай, Мамадыш районындагы ике лагерьдә («Кояшлы дөнья» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Надежда» балалар сәламәтләндерү лагерендә (гамәлгә куючысы – «Берсут» ачык акционер җәмгыяте) һәм Чаллы шәһәрендә «Олимпия» балалар сәламәтләндерү

лагере (гамәлгә куючысы – «Фест» коммерциягә карамаган предприятиесе) лагерьләр персоналын сайлап алуга карата җитди шикаятьләр булганга күрә, Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе – Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторы Е.Н.Костюшинга әлеге лагерьләргә компетенция предметы буенча ведомство күзәтчелеген үткәрү турында мөрәҗәгать итте.

7 лагерьгә урнаштыру, аларда тоту һәм эшнең оештырылуына карата санитария-эпидемиология таләпләре бозылу фактлары буенча планнан тыш ведомство тикшерүләрен үткәрү турында тиешле мөрәҗәгать ТР буенча Россия кулланучылар күзәтчелегенә җибәрелде. Моннан тыш, мондый һәр очрак буенча Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссиягә мәгълүмат бирелде.

Закон белән каршылыкта булган балалар өчен ябык типтагы махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүче балигъ булмаганнарның тору, аларга белем бирү процессын оештыру, медицина ярдәме күрсәтү шартлары даими күзәтелеп тора. 2016 дәвамында түбәндәгеләргә барылды:

«Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус уку-тәрбия учреждениесенә;




«Пермь крае буенча Россия ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесенә.





«Пермь крае буенча Россия ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесенә барып кайту йомгаклары буенча Россия Федерациясе Генераль прокуроры урынбасары С.П.Зайцев исеменә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ачыкланган хокук бозулар, прокурор күзәтчелеге тәртибендә тикшерүләр үткәрү һәм тиешле чаралар күрү турында мөрәҗәгать юлланды.

Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика районнарына һәм шәһәрләренә эш визитлары барышында түбәндәге оешмаларда тикшерүләр үткәрелде:

интернат тибындагы гомуми белем бирү һәм махсус (коррекция) мәктәпләре (Питрәч, Спас, Саба муниципаль районнары);

Үзәк район хастаханәсенең балалар бүлеге (Аксубай муниципаль районы);

Психоневрология диспансерының психиатрия балалар бүлеге (Чаллы шәһәре);



Украинадан килгән гражданнарны вакытлыча урнаштыру пунктлары (Казан шәһәре).

Югарыда әйтеп үткәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күзәтчелек эшчәнлеге кысаларына балалар учреждениеләре эшчәнлеге генә түгел, ә *тиешле хакимият органнары эшчәнлеге* дә керә.



Республика районнарына һәм шәһәрләренә эшче визитлар кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокукларын һәм мәнфәгатьләре тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыра торган муниципаль хезмәтләр (опека һәм попечительлек органнары, мәгарифкә идарә органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау органнары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр) эшчәнлегенә анализ ясады. Шулай, 2016 елда республиканың 21 районында һәм шәһәрендә урнашкан күрсәтелгән хезмәтләрнең начар гаиләләр белән эшләү, ятим балаларны гаиләгә урнаштыру, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укытуны оештыру, мәктәптә тукландыруны оештыру, балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, гаиләләр белән һәм девиант холыклы балалар белән эшләү һ.б. буенча эшчәнлеге анализланды. Күрсәтелгән эшчәнлекне өйрәнү нәтиҗәләре буенча

түбәндәге 10 муниципаль район башлыклары исеменә ачыкланган хокук бозулар һәм мондый эшләрнең җитәрлек дәрәҗәдә алып барылмавы турында 11 бәяләмә җибәрелде:

Актаныш (1 бәяләмә);
Алексеевск (1 бәяләмә);
Югары Ослан (1 бәяләмә);
Буа (1 бәяләмә);
Яңа Чишмә (2 бәяләмә);
Балык Бистәсе (1 бәяләмә);
Теләче (1 бәяләмә);
Спас (1 бәяләмә);
Чирмешән (1 бәяләмә);
Менделеевск (1 бәяләмә).

Болар белән бергә муниципаль районнар башлыклары исеменә реабилитация өчен башка муниципаль районнардагы социаль приютларга балалары җибәрелгән ата-аналар (законлы вәкилләр) белән реабилитация эшен оештырганда аларның хокуклары бозылу турында 9 мөрәҗәгать юлланды (Апаска – 2 мөрәҗәгать, Буага – 2 мөрәҗәгать, Кама Тамагына – 2 мөрәҗәгать, Лаеш, Тукай районнарына һәм Казан шәһәренең Совет районына – берәр мөрәҗәгать).

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил уздырган берничә тикшерү бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактлары турында алынган хәбәрләр һәм мәгълүмат буенча, шул исәптән җәмгыятьтә кызыксыну уяткан аерым очраклар буенча оештырылды.

2016 елда барлыгы шундый 23 очрак өйрәнелде.

Барлыкка килгән хәлләрне оператив һәм төрле яклап өйрәнү һәм алар турында фикер алышу, үзара килешенгән гамәлләр башкару һәм балалар мәнфәгате күзлегеннән иң уңай карарлар кабул итү өчен күп кенә очраклар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Координацияләү комитеты утырышларында каралды. Мондый тәҗрибә үзен оператив гамәл күрүне таләп итә торган иң кискен һәм авыр хәлләр туганда чаралар күрүнең нәтиҗәле механизмы буларак күрсәтте.

Уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләргә йомгак ясап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил күрсәтелгән фактлар буенча Алексеевск, Биектау, Сарман, Лениногорск, Алабуга муниципаль районнары, Чаллы шәһәре (2 бәяләмә) башлыклары исеменә балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында 7 бәяләмә юллады.

1.3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатьләрендә законнарны камилләштерүдә катнашуы

Балалар мәнфәгатьләрен кайгыртып, законнарны камилләштерүдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тулы күләмдә катнашуы бала хокукларының һәм мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан яклануына гарантияләрне иң яхшы тәэмин итү максатын гамәлгә ашыруның мөһим механизмы булып тора.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: карала торган өлкәдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елдагы эшчәнлеге норма чыгару эшчәнлегенә йогынты ясауның иң эре коралларының берсе – закон чыгару инициативасы хокукы булмаса да алып барылды.

Моның белән бергә, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын камилләштерүгә булышлык итү Законның 3 статьясында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең төп бурычларының берсе буларак билгеләнгән.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге бурычны гамәлгә ашыруны бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый актларны эшләгәндә катнашу буенча Законның 11 статьясында билгеләнгән вәкаләте кысаларында тәэмин итә.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең норма чыгару эшчәнлеге, иң элек, баланың законнар белән гарантияләнгән хокукларына, шулай ук аларның мәнфәгатьләренә норматив хокукый актларның туры килүен килешерүдә катнашу рәвешендә алып барылды.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан Республикасында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты эшләгән чорда норматив хокукый актларны аларның баланың законнар белән гарантияләнгән хокукларына да, шулай ук аларның мәнфәгатьләренә дә туры килүен билгеләү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерүнең аерым системасы булдырылды.

Вәкаләтле вәкилнең *федераль норма чыгару процессында* катнашуы бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы федераль закон проектларын «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.4 статьясында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына килештерүгә җибәрү процедурасы кысаларында тәэмин ителә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил *республика норматив хокукый актлары проектларын* (Татарстан Республикасы законнары,

Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре проектларын) рәсми килештерүне, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты нигезендә балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган норматив хокукый актлары килештерелергә тиешле вазыйфаи затлар исемлегенә 2013 елда кертелгәннән соң, аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү чорында мәҗбүри башкара.


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика законнары проектлары буенча фикер алышуларда катнашуның мөмкин булган башка ысулы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары тарафыннан закон проектлары алдан каралган вакытта закон чыгару процессында катнашудан гыйбарәт, ул аның исеменә алынган рәсми гарызнамәләргә бәяләмәләр бирү һәм закон проектлары буенча эшләү өчен төзелә торган эшче төркем утырышларында комитетлар инициативасы буенча катнашып башкарыла.

Карауга кертелә торган барлык норматив хокукый актлар проектлары буенча аларның халыкара хокук, федераль һәм республика законнары нормалары белән гарантияләнгән бала хокукларын һәм мәнфәгатьләренә туры килү-килмәвенә бәйсез экспертиза ясала һәм тиешле бәяләмәләр бирелә.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештерү өчен балигъ булмаганнарның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы 34 федераль һәм республика норматив хокукый акты проекты керде.

12 нче диаграмма

2012 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан каралган федераль һәм республика норматив хокукый актлары проектлары саны



Югарыда китерелгән белешмәләр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан каралган федераль һәм республика норматив хокукый актлары проектларының гомуми саны кимүне күрсәтә, бу исә балаларның һәм дә балалы гаиләләрнең хокукларына һәм мәнфәгатьләре кагылышлы кабул ителә торган норматив хокукый актларның санының гомумән кимүенә бәйле.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына 23 ***федераль закон проекты*** керде. Аерым алганда:

1. «Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» Федераль законның 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»;

2. «Ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» (ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, шулай ук алар арасыннан булган затларга эшсезлек буенча пособие түләү нигезләрен үзгәртү өлешендә);

3. «Ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» (ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның торак урыннарын тикшереп тору тәртибен һәм срогын билгеләү өлешендә);

4. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» (баланы аноним калдырып китү өчен махсуслаштырылган урыннар булдыру өлешендә);

5. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына үзгәреш кертү хакында» (балигъ булмаганнарны тоту һәм тәрбияләү буенча ата-аналарның һәм аларның башка законлы вәкилләренең үз вазыйфаларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны үзгәртү өлешендә);

6. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына үзгәреш кертү хакында» (балигъ булмаганнарны тоту һәм тәрбияләү буенча ата-аналарның һәм аларның башка законлы вәкилләренең үз вазыйфаларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә);

7. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законның 54 статьясына һәм «Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» (административ җаваплылыкка тартылган балигъ булмаганнарны суд карары буенча наркоманиядән дәвалау турында);

8. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турындагы аерым нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә);

9. «Балаларның сәламәтлегенә зыян китерә торган мәгълүматтан балаларны яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларына һәм 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ номерлы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» (мәгълүмат продукциясенең әйләнешенә карата куелган таләпләрне төгәлләштерү өлешендә);

10. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» (баланың ата-анасына, гаиләнең башка әгъзаларына яки аның законлы вәкилләренә реанимация бүлегенә керүне рөхсәт итү өлешендә);

11. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Федераль законның 51 статьясына үзгәреш кертү хакында» (баланың ата-анасына, гаиләнең башка әгъзаларына яки аның законлы вәкилләренә реанимация бүлегендә һәм интенсив терапия палатасында булу мөмкинлеген бирү өлешендә);

12. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 14.2 һәм 15 статьяларына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына баланы туганнан соң аноним калдырып китүдән яклау максатларында үзгәрешләр кертү хакында»;

13. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» (алкоголизмнан интегүче балигъ булмаганнарга, аларның бер ата-анасыннан яки башка законлы вәкиленнән хәбәр ителгән ихтыярый ризалыгы булган очракта, медицина ярдәме күрсәтү өлешендә);

14. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына балаларның ялга һәм сәламәтләнүгә, шулай ук аларның тормышлары һәм сәламәтлекләре саклануга хокукын тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында»;

15. «Россия Федерациясе Гаилә кодексына һәм «Граждан хәле актлары турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» (ярдәмче репродуктив технологияләр куллану өлешендә);

16. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 10 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» (балаларның ялын һәм сәламәтләнүен оештыруны дәүләт тикшерүе турында);

17. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына бала карау буенча айлык пособие түләү срогын озайту өлешендә үзгәрешләр кертү турында»;

18. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына үзгәреш кертү хакында» (балигъ булмаганнарны тоту һәм тәрбияләү буенча ата-аналарның яки аларның башка законлы вәкилләренең үз вазыйфаларын үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә);

19. «14 яшькәчә баланы карау буенча айлык пособиене минималь хезмәт хакы күләмендә билгеләү турында»;

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына өстәмәләр кертү хакында» (гаилә көнкүрешендәге җәнҗәл өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә);

21. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына бала хокукларын яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» (баланы үз гаиләләренә тәрбиягә алырга теләгән якын туганнарының аны әзерләве өлешендә);

22. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына бала карау буенча айлык пособие түләү күләмен һәм чорын озайту өлешендә үзгәрешләр кертү турында»;

23. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга эшсезлек буенча пособие түләү өлешендә).

Ясалган экспертизалар нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тиешле бәяләмәләр әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде, шуларның икесе тискәре бәяләмә булып, карала торган закон проектын республика исеменнән хупламаска тәкъдим ителде.

Россия Федерациясе ***Хөкүмәте карары проектын***, аерым алганда, «Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 апрелендәге 113-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын карау һәм килештерү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең законнарны балалар мәнфәгатьләрен кайгыртып камилләштерүдә катнашу буенча 2016 елгы эшчәнлегендә яңалык булды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерү өчен кергән ***региональ норматив хокукый актлар проектларының*** саны кимү, иң элек, 2016 елда республикада балалар һәм балалы гаиләләр хо-

кукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы кабул ителгән норматив хокукый актларның саны тулаем кимүгә бәйле. Шулай итеп, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 10 региональ норматив хокукый акт проектын (2015 елда – 16 проект иде) карауда катнашу мөмкинлеге бирелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетында алдан карау баскычында бәяләмә бирү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 4 *Татарстан Республикасы законы проекты* керде, аерым алганда:

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» (Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы вәкаләтләреннән мәгариф оешмаларына кергәндә һәм аларда уку чорында балигъ булмаганнарның медицина тикшеренүләре узу шартларын билгеләүне төшереп калдыру өлешендә);

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» (уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга дәүләт гарантияләрен кертү өлешендә);


«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»;

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында».

Моның белән бергә хисап елы дәвамында теге яки бу рәвештә балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы 6 закон кабул ителде.

13 нче диаграмма

2014 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы законнары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү



Шулай итеп, 2014 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил рәсми килештерү кысаларында үз фикерен кабул ителгән региональ законнарның 33% ына, ягъни 6 законның икесенә карата белдерә алса, 2015 елда биш закон проектының берсе дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә рәсми каралуга җибәрелмәде, 2016 елда исә балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы Татарстан Республикасында кабул ителгән законнарның 66,7% ы, ягъни алты законның дүртесе, рәсми бәяләмә бирү һәм килештерү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә алынды.

Региональ ярдәмче норматив хокукый актлар өлешендә 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 6 карар проекты каралды:*

1. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

2. «Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда балаларны тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын стандартын раслау турында»;

3. «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында»;

4. «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренең тибын үзгәртү юлы белән Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт казна учреждениеләрен (балалар һәм яшьләр өчен социаль приютлар) төзү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 12 ноябрендәге 862 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

5. «Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган балалар һәм яшьләр өчен иҗади конкурсларга, фестивальләргә аккредитация буенча ведомствоара комиссия төзү турында»;

6. Татарстан Республикасында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын арттыруның, юл-транспорт һәлакәтләрен киметүнең һәм алар аркасында килгән зыянны киметүнең өстәмә чаралары турында».

Моның белән бергә 2016 елда теге яки бу рәвештә балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы 17 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм күрсәтмәсе кабул ителде.

2016 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештермичә кабул ителгән 12 карар һәм күрсәтмә буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән килештерү тәртибен бозган:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының өч карары буенча (19.01.2016, № 23; 13.08.2016, № 555; 21.03.2016, № 153);

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының өч карары буенча (15.04.2016, № 225; 18.04.2016, № 236; 07.10.2016, № 724);


Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының өч карары буенча (13.10.2016, № 747; 31.10.2016, № 798; 30.12.2016, № 1057);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бер карары буенча (19.08.2016, № 576);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ике карары һәм күрсәтмәсе буенча (21.09.2016; № 664; 16.12.2016, № 2978-р).

14 нче диаграмма

2014 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү



Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы актлары (карарлары һәм күрсәтмәләре) проектларын алдан килештерүдә катнашуын тәэмин итү эше начарайды: әгәр 2014 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республикада кабул ителгән карарларның һәм күрсәтмәләрнең 80% (ягъни 29 проектның 23) буенча рәсми килештерү кысаларында үз фикерен белдерә алса, 2015 елда 65% (22 дән 14) Татарстан Республикасының ярдәмче норматив хокукый акты Бала хокукла-

ры буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерелсә, 2016 елда рәсми бәяләмә бирү һәм килештерү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы кабул ителгән карарларының һәм күрсәтмәләренең бары тик 29% (ягъни 17 дән 5) гына керде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына норматив хокукый актлар проектларын кертүнең һәм аларны карауның билгеләнгән тәртибен саклау ягыннан да, бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләренә дәүләт яклавы гарантияләрен тәэмин итү буенча да мондый тенденция булырга тиеш түгел, дип саныйбыз. Карала торган өлкәдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елдагы эшчәнлеге норма чыгару эшчәнлегенә йогынты ясауның иң эре коралларының берсе – закон чыгару инициативасы хокукы булмаган шартларда алып барылса да, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында каралган норматив хокукый актлар проектларын рәсми килештерү процедурасын башкаруны тәэмин итү бүгенге көндә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең закон чыгару эшендә катнашуының нормативларда билгеләнгән бердәнбер ысулы булып тора.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елда норма чыгару эшендә катнашу тәжрибәсенә анализ ясау йомгаклары буенча һәм законнарны балалар мәнфәгатьләрен кайгыртып камилләштерүдә катнашу хокукын тулы күләмдә гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләрне башкарырга кирәк дип саныйбыз:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертү юлы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә закон чыгару инициативасы хокукын бирү турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 89 статьясындагы 4 өлеше, 90 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне республика закон чыгару җыелышында закон чыгару барышында закон проектларын алдан караганда җәлеп итүне тәкъдим итәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты таләпләренең Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан үтәлешенә һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив хокукый акт-

лар проектларының Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бәяләмәсе булганда каралуына контрольне тәэмин итә торган чаралар күрүне оештырырга;

Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карары белән расланган Регламентның 57 пункты таләпләренең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертелә торган балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы барлык норматив хокукый актлар проектларының Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерүгә мәҗбүри җибәрелүе өлешендә берсүзсез үтәлүен тәэмин итәргә.

1.4. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд эшләрендә катнашуы бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның нәтиҗәле алымнарының берсе булып тора.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законда билгеләнгән тәртиптә суд яклавын гамәлгә ашыруы Законда каралган. Ләкин граждан-процессуаль һәм җинаять- процессуаль законнарда билгеләнгән нормалар буенча әлеге вәкаләтләр чикләнгән. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөстәкыйль процессуаль хокук бирелмәгәнлектән ул хокук суд процессында бәхәснең асылы буенча (эштә катнашучы затлар үтенечнамәсе буенча) мөстәкыйль таләпләр куя алмый торган өченче зат буларак, йә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлеше нигезендә (суд инициативасы буенча) бала хокукларының һәм мәнфәгатьләренең якламуына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән дәүләт вазыйфаи заты буларак катнаша.


Шул рәвешле бу хәл Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балаларны суд ярдәмендә яклау мөмкинлеген чикли. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала хокуклары бозылуның ачыкланган очраклары турындагы бәяләмәләрендә куелган таләпләрне республика дәүләт хакимиятенең тиешле органнары, муниципаль органнар һәм оешмалар тарафыннан үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә бу проблема аеруча кискен төс ала. Мондый очракта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокукларын яклауны күзәтчелек итү органнарына, беренче чиратта

прокуратура органнарына мөрәҗәгать итү юлы белән генә башкара ала, йогынты ясауның башка чараларын кулланырга аның хакы юк. Шуңа күрә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый вәкаләтләрен арттыру максатыннан, граждан эшләрен караганда бу институтка (федераль һәм региональ дәрәҗәләрдә) мөстәкыйль процессуаль хокук бирү өлешендә федераль законнарга үзгәрешләр кертергә кирәк.

Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законда билгеләнгән тәртиптә суд яклавында катнашу белән бергә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә киңәш бирү, процессуаль документлар төзүдә һәм кирәкле материаллар туплауда ярдәм рәвешендә судта граждан эшен карауга әзерлек кысаларында юридик ярдәм күрсәтү (алга таба – юридик ярдәм) актив башкарыла.

15 диаграмма

2012 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан яисә юридик яктан ярдәм күрсәткән суд процесслары саны



Узган хисап чорыннан күренгәнчә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан суд эшләре саны шактый (өч тапкыр) артты (2016 елда – 25 эш, 2015 елда – 8 эш), юридик ярдәм күрсәтелгән суд эшләре ике тапкырга артты (2016 елда– 51, 2015 елда – 22). Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында булган суд эшләренең гомуми санының 21 очракта – эш буенча якларның берсе инициативасы белән, 4 очракта суд инициативасы белән Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлешендә каралган тәртиптә дәүләт вазыйфаи заты буларак суд эшен карауга җәлеп ителде.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасын, юридик хезмәт күрсәтүне дә кертеп, түбәндәгеләргә бәйле бәхәсләр тәшкил итте:

балаларның яшәү урынын билгеләүгә;

ата-ананың берсе белән генә яисә туганнары белән яшәүче баланың аралашу тәртибен билгеләүгә;

балигъ булмаганнарның торак хокукларын яклауга, шул исәптән: балигъ булмаганны торак урында яшәүгә хокуксыз дип тануга; торак урын-

нан файдалануга каршылыкларны бетерүгә; торак урыннан файдалану тәртибен билгеләүгә, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү тәртибен билгеләүгә; торак урын милекчесе хокукларын бозуны бетерүгә; сатып алу һәм милек хокукын туктату юлы белән торак урынны яисә җир өлешен тартып алуга бәйле;

яңа ачылган сәбәпләр нигезендә торактан чыгару турында шәһәр суды карарын яңадан карау хакындагы гаризаны карауга бәйле;

түләтү өчен гомуми мөлкәттә бурычлының өлешен бүлүгә бәйле;

ата-ана хокукларын чикләүгә (чикләүне бетерүгә), мәхрүм итүгә (торгызуга) алиментлар түләтүгә бәйле;

сирәк очрый торган (орфан) авырулар белән интегүче затларны дарулар белән тәэмин итү өлешендә баланың сәламәтлек саклауга хокукын яклауга;

уллыкка (кызлыкка) алу турында эшләрне карауга бәйле;

сыйфатсыз медицина ярдәме аркасында, шул исәптән үле бала табуга бәйле мораль зыян өчен түләүгә;

сыйфатсыз медицина ярдәме аркасында килгән зыянны компенсацияләү, күмү, искә алу ашлары уздыру чыгымнарын түләү рәвешендә;

нигезсез баеган өчен түләтүгә;

балигъ булмаган баланы опекага алынудан баш тартуны законсыз дип тануга;

балигъ булмаганнарга карата килгән мораль зыянны компенсацияләүгә (мәгариф учреждениесендә сәламәтлеккә зыян китермичә балаларның үзара сугышуларына бәйле).

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елда суд практикасындагы яңалыгы түбәндәгеләр турында таләпләрне (гаризаларны) карауга бәйле:

сыйфатсыз медицина ярдәме аркасында килгән мораль һәм әхлакый зыянны түләтү;

балигъ булмаган баланы опекага алынудан баш тартуны законсыз дип тану;

балигъ булмаганнарга карата килгән мораль зыянны компенсацияләү (мәгариф учреждениесендә сәламәтлеккә зыян китермичә балаларның үзара сугышуларына бәйле);

уллыкка (кызлыкка) алу.

Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан судларда граждан эшләрен карауга бәйле карарлар аның фикерен исәпкә алып чыгарылды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне 2016 елда җәлеп итү практикасының артуы республика судларының балаларга бәйле эшләрне

бала мәнфәгатьләрендә законлы һәм гадел хәл итәргә омтылулары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең судта катнашу мөмкинлекләрен үстерү юлы белән аның хокук саклау эшчәнлегендә катнашуын арттыру зарурлыгын аңлауны күрсәтә.

Татарстан Республикасы Конституция суды инициативасы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне конституциячел суд эшләренә җәлеп итү практикасы дәвам итте. Мәсәлән, узган чорда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 51 статьясы тәртибендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан түбәндәге эшләр буенча бәяләмә бирү өчен ике тапкыр җәлеп ителде:

«Татарстан Республикасында мәктәп автобусларын нәтиҗәле файдалану чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 3 августындагы 400 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турындагы нигезләмәнең 3 пунктының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 3 августындагы 615 номерлы карары белән расланган Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәнең 2.3 һәм 2.5 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2006 елның 8 ноябрендәге 2346 номерлы карары белән расланган «Казан шәһәре территориясендә гражданнарга торак биналарны хосусый милек буларак тапшыру (хосусыйлаштыру) барышында документлар рәсмиләштерү тәртибе турында» инструкциягә 2 нче кушымтадагы алтынчы абзацның һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 28 июнендәге 4310 номерлы карары белән расланган Торак биналарны гражданнарга хосусый милек буларак тапшыру (хосусыйлаштыру) килешүләрен рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының II бүлегендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына куелган таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктындагы уникенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча.

Әлеге суд органының мондый инициативасы карарлар чыгарылганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил фикеренчә, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү принцибын исәпкә алу зарурлыгыннан караганда күрсәтелгән суд тәжрибәсен законлы нигездә беркетү өчен нигез булып тора. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәбез.

Татарстан Республикасы Конституция судына, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 2 өлешенә һәм 81 статьясына үзгәрешләр кертү юлы белән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган барлык эшләр буенча үз фикерен әйтеп чыгыш ясау өчен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында катнашу, хокукын бирү;

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 81 статьясына тиешле үзгәрешләр кертү юлы белән Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының Конституциягә туры килүен тикшерү турында мөрәҗәгать итү хокукын бирү мәсьәләсен карауны тәкъдим итәбез.

1.5. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасында бала мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм хокукларын яклау механизмын камилләштерүгә ярдәм итү эшчәнлегенең төп юнәлешләре

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының балалар мәнфәгатьләрендә эшчәнлеген камилләштерү максатында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасында бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау турында **еллык доклад тәкъдим ителә**, аны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында балаларның хәлен яхшырту буенча чаралар күрелә. Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә доклад Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

2016 елның 7 мартында «2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» доклад Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка тапшырылды. Рәсми очрашу кысаларында Президентка 2015 елда Татарстан Республикасында балалар хокукларын гамәлгә ашыру буенча төп проблемалы мәсьәләләр турында һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында хәбәр ителде.

2016 елның 11 мартында «2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм



законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында» доклад Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында тыңланды. Фикер алышулар нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, муниципаль район башлыкларына докладтагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чаралары күрергә, шулай ук балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау чаралары комплексын эшләргә тәкъдим итте.

Бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре буенча аерым тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына кертү хокукыннан файдаланып, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка түбәндәге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итте:

ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру эшчәнлеген камилләштерү, Татарстан Республикасында «Видеопаспорт» проектын гамәлгә ашыру юлы белән;

балаларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан балаларны яклап, Республика форумы үткәрүгә ярдәм итү;

гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларның белем бирү учреждениеләренә бару һәм кайтулары буенча транспорт белән тәэмин ителеш хокукын гамәлгә ашыру;

балалар һәм яшьләр арасында «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» дигән видеороликлар буенча өченче республика конкурсын үткәрүгә ярдәм итү;

Татарстан балаларын – Пермь төрбия колониясендә тәрбияләнүчеләрне тотуда уңайлы шартлар тудыруга финанс ярдәме күрсәтү.

Башка контроль-күзәтчелек органнары белән конструктив хезмәттәшлек бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү механизмын камилләштерүгә ярдәм итә. 2012 елдан бирле мондый хезмәттәшлек Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән, 2015 елдан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты белән гамәлгә ашырыла.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә федераль күзәтчелек органы –

Элемтә, мәгълүмат- технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Татарстан Республикасы идарәсе белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде.



2016 елның 27 октябрендә әлеге Килешү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина белән күзәтчелек буенча Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе Б.Н.Разинов тарафыннан имзаланды.

Бала хокукларын яклауда нәтиҗәле эшчәнлеккә ирешүдә тиешле механизмнар эшләү максатларында бала хокукларын яклауның территориаль федераль дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итте. Аларның эшчәнлеген тикшерү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкаләтенә керми, хезмәттәшлек килешүләр нигезендә алып барыла.

2012 елдан бирле мондый килешүләр түбәндәгеләр белән эшчәнлек Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе, Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Җәза үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертизаның баш бюросы» федераль казна учреждениесе белән эшләр алып барыла.

Бала хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында 2016 елда шундый ук килешүләр коммерциячел булмаган оешмалар белән төзелде.



19 октябрьдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән азат ителгән балигъ булмаганнарны тернәкләндерү һәм яраклаштыру, шул исәптән аларга хокукый, консультатив, социаль һәм психологик ярдәм, һөнәр сайлауда һәм хезмәткә урнаштыруда ярдәм мәсьәләләре буенча «Социаль реабилитация һәм адаптация үзәге» коммерциячел булмаган автоном оешма белән үзара хезмәттәшлек итү хакында килешү имзаланды.

• 22 декабрьдә мәгариф, тәрбия, балалар хокукларын, балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләрен яклау өлкәсендә балигъ булмаганнарга



һәм аларның ата-аналарына психологик-педагогик һәм социаль-педагогик мәсьәләләр буенча «Параллель» Татарстан Республикасы мәктәп психологлары ассоциациясе» коммерциячел булмаган партнерлыгы белән үзара хезмәттәшлек итү хакында килешү имзаланды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ***даими ведомствоара, координацион, киңәшү органнары, эшче төркемнәр, комиссияләр эшендә катнашуы*** эшчәнлегенең төп өлешен тәшкил итә. 2016 ел башына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балалар мәнфәгатьләренә кагылышлы 13 төрле республика комиссиясендә һәм эшче төркемдә әгъза булып тора.

2016 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләр составына керде:

Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия;

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлеге координация советы;

Татарстан Республикасы бала алган гаиләләрдән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе, аның максаты – бала алган гаиләләрдән балаларны кире кайтару очракларының сәбәпләрен анализлау, кире кайтаруга этәрә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар дәүләт учреждениеләренә кире кайтарылган очракта хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү;

Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең иҗтимагый советы, ул җинаятькә каршы суд эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарын үтәү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча чаралар күрүдә катнашуга иҗтимагый, һөнәри һәм башка берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итү максатында төзелгән иде;

«Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе каршындагы Татарстан Республикасы буенча иҗтимагый совет, ул инвалид гражданнарның һәм инвалидларның җәмәгать берләшмәләренең иҗтимагый әһәмиятле мәнфәгатьләренә медик-социаль экспертиза үткәрү, килештерү һәм исәпкә алу, буенча дәүләт хезмәтләреннән файдалануга бәйсез бәяләү, шулай ук хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты мәсьәләләре буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау, гражданнар белән эшләгәндә этика принципларын саклау һәм деонтология максатында төзелгән иде.

Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауда нәтиҗәле эшчәнлеккә ирешү Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән конструктив хезмәттәшлектән башка мөмкин булмауны исәпкә алып, 2015 елдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә координацион ведомствоара киңәшмәләр оештыру һәм үткәрү практикасы кертелде. 2016 елда шушы уңайдан даими эш итүче координацион орган – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршында Координацион комитет төзелде (алга таба – Координацион комитет).

Координацион комитет – бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен югары дәрәҗәдә үтәү бурычларын хәл иткәндә башкарма хакимиятнең кызыксынучы органнарының эшен тиешенчә тәэмин итә торган консультатив-киңәш органы. Координацион комитет утырышларында системага кагылышлы да, хосусый да, шул исәптән балалар хокукларын катлаулы һәм резонанслы бозу очраклары да каралды.

Координацион комитетның төп бурычлары дәүләт хакимияте органнары, бирле үзидарә органнары, вазыйфаи затларның балигъ булмаган бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү эшчәнлеген координацияләү; балигъ булмаган балаларның авыр тормыш хәлләреннән чыгуында ашыгыч, перспектив, системалы карарлар эшләү һәм кабул итүдән гыйбарәт.




Координацион комитет составына аерым өлкәләрдә балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы тармак ведомстволары, хокук саклау органнары, Иҗтимагый палата вәкилләре керә.

2016 ел дәвамында Координацион комитетның 12 утырышы булды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы әлеге эшче органның эшчәнлеге Татарстан Республикасында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүдә яңа механизм булды.

2016 елда республика муниципаль районнарына (шәһәр округларына) чыгып эшләү практикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшенең тагын бер яңа рәвеше булды.







Районнарга эш визиты кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

Әлеге муниципалитетта балаларның актуаль мәсьәләләрен тикшерү өчен район җитәкчелеге (башлыгы) белән очраша;

гражданнарны урында кабул итә;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе эшендә катнаша;

балалар учреждениеләрен тикшерә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эш визиты җирле массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртыла.

Балалар белән шул рәвешле эшләү республиканың аерым районында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга ярдәм итә. Эш визитлары республика территорияләрендә балалар хәлен яхшыртуның эшлекле механизмы буларак танылды. 2016 елда республика муниципаль районнарының ярты сына диярлек эш визитлары оештырылды (21 муниципаль район һәм шәһәр округы): Апас, Әгерҗе, Актаныш, Аксубай, Алексеевск, Әтнә, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Кайбыч, Мамадыш, Менделеевск, Яңа Чишмә, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Спас, Теләче, Чирмешән муниципаль районы һәм Чаллы шәһәре.

2017 елда бу эшчәнлек расланган план нигезендә дәвам иттереләчәк.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре институты тагын да үсте.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең иҗтимагый башлангычларда эшләүче ярдәмчеләре булу хокукы «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясында урын алган. Беренче җәмәгать ярдәмчеләре 2015 елда барлыкка килде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2015 елның 19 ноябрендәге 20-О номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре турында нигезләмә расланды. 2016 ел ахырына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карары белән 17 җәмәгать ярдәмчесе билгеләнде, шуның 15 Татарстан Республикасы муниципаль районыннан: Алабуга, Чүпрәле, Менделеевск, Буа, Арча, Тәтеш, Яңа Чишмә, Бөгелмә, Алексеевск, Кайбыч, Зеленодольск, Теләче, Кама Тамагы, Чистай, Балтач районнарыннан.

Моннан тыш, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 55 ярдәмчесен берләштергән балалар җәмәгать ярдәмчесе институты оештырылды. Ул «Балалар җәмәгать ярдәмчесе» проектының «Татарстан Республикасы балалар оешмасы советы» АҖ белән берлектә барлыкка килде.





Балалар җәмәгать берләшмәләренең хокук саклау эшчәнлеге республиканың барлык муниципаль районнарында һәм шәһәрләрендә оештырылды. Белем бирү бурычларын гамәлгә ашырудан тыш, балалар үз хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы фикерләрне дә җиткерүчеләр булдылар, күп төрле чараларда катнаштылар, хокук саклау эшчәнлегенең реаль субъектлары булдылар.

2017 елга Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә перспектив бурычларның берсе – җәмәгать ярдәмчеләре институтларын торгызу һәм үстерү.

Кайбер ***республика проектларын*** гамәлгә ашыру буенча балалар мәнфәгатьләрен яклау эшләре механизмы камилләштерелде.

Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү, шул исәптән Татарстан Республикасында 2011 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тәкъдиме белән башланып киткән «Баланың ВИДЕОПАСПОРТЫ» проектын гамәлгә ашыру гомумроссия мәгълүмат-эзләү системасы кысаларында дәвам итте.

Проект ятим бала турында максималь тулы, дөрес мәгълүматны үз эченә алган һәр бала турындагы 40 минутлы фильм рәвешендә балаларның видеопаспортларын булдырудан гыйбарәт, ул бала алуга кандидат ата-аналарга бала белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, «ВИДЕОПАСПОРТ» проекты гаиләгә балаларны урнаштыру эшендә федераль мәгълүмат ресурсыннан файдалануны күз алдында тота, бу ата-анага кандидатларның һәм балаларның бер-берсен табу мөмкинлекләрен киңәйтә: WWW.VIDEOPASPORT.RU Интернет сайтында видеопаспортларны урнаштыру, «Пока все дома» программасының «Сезнең балагыз булачак» рубрикасында ятим балалар турында сюжетлар ясау һәм күрсәтү мөмкинлекләре.

Алты ел эчендә балаларның барлыгы 364 видеопаспорты ясалды (2011 елда – 32 видеопаспорт, 2012 елда – 31 видеопаспорт, 2013 елда – 43 видеопаспорт, 2014 елда – 56, 2015 елда – 94, 2016 елда – 108). 2017 елның 1 гыйнварына шулардан 241 бала үз гаиләләрен тапты, 1 бала дәүләт учреждениесе бинасыннан китәргә әзерләнә.

Проектның иң зур казанышы проблемалы төркем булып торучы зур гаиләләрдән булган (3 бала һәм аннан да күбрәк) балалар, өлкәнрәк

яшьтәге балалар (9-14 яшь), инвалид балалар һәм сәламәтлек ягыннан проблемалары булган балалар гаиләле булды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил башлангычы һәм Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән 2015 елда башланган һәм аның кушуы буенча 2016 елда да дәвам итә торган ***«Аек акыл» пилот проекты*** социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән .

Гаилә өч Гаилә өчен куркыныч һәм авыр тормыш вәзгыятенең төп сәбәпчесе булган, хәтта баланы ата-анадан тартып алуга, баланы тораксыз калдыруга китерә торган халәттән – ата-ананы алкогольгә бәйлелектән котылуга нәтиҗәле ярдәм итү шуларның берсе буларак каралырга тиеш. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, республикада алкогольгә бәйле гражданнарга медицина ярдәме күрсәтү буенча аерым система булдырылды. Шулай да, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына муниципаль органнардан – гаилә һәм балалар проблемаларын профилактикалау субъектларыннан килгән мөрәҗәгатьләр әлеге эшнең нәтиҗәлелеген арттыру турында уйланырга мәҗбүр итә.

Шуңа бәйле рәвештә 2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы Милли фәнни наркология үзәге һәм «Югары икътисад мәктәбе» ФИУ катнашында «Аек башлангыч» наркологик медицина ярдәмен камилләштерү өлкәсендә дәүләти-хосусый партнерлык программасы чараларын кайбер Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашыру тәжрибәсе карауга алынды. Шулай да, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына муниципаль органнардан – гаилә һәм балалар проблемаларын профилактикалау субъектларыннан килгән мөрәҗәгатьләр әлеге эшнең нәтиҗәлелеген арттыру турында уйланырга мәҗбүр итә.

Шуңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы Милли фәнни наркология үзәге һәм «Югары икътисад мәктәбе» ФИУ катнашында «Аек башлангыч» наркологик медицина ярдәмен камилләштерү өлкәсендә дәүләти-хосусый партнерлык программасы чараларын кайбер Россия Федерациясе субъектларында гамәлгә ашыру тәжрибәсе карауга алынды. Программада алкогольгә бәйлелек белән чирләүчене 6 айлык терапия курсына җәлеп итү, 14 психотерапия сеансы һәм «Налтрексон пролонг инъекцияләре» препараты ярдәмендә 6 инъекция ясау каралган. Россия Федерациясе субъектының катнашуы пациентларның аерым төркемнәре өчен дару белән тәэмин итүне оештыруга өстәмә дару препаратлары бүлеп бирүне күздә тота. Айлык курс буенча 1 пациентны дәвалау суммасы 120 000 сумны тәшкил итә.

«Аек башлангыч» пилот проектын гамәлгә ашыру нигезендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме

белән балалар мәнфәгатьләрендә социаль юнәлешле алым сайланды: гражданнарның аерым төркемнәрен дәвалау турында карар кылынды: алар – балигъ булмаган балалары булган, ата-ана хокукыннан мәхрүм булу куркынычы янаган хатын-кызлар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасы белән берлектә гамәлгә ашырыла торган **«Балалар җәмәгать кабул итүе»** республика проекты бала хокукларын яклау механизмнарын камилләштерүгә ярдәм итүдә яңа эшчәнлек рәвеше булды.



Бу башлангычны Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов хуплады, аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 28 июлендәге 1646-р номерлы күрсәтмә нигезендә республикада проектны гамәлгә ашыруга 5 400 000 сум акча бүлеп бирелде. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең 19.08.2015 № 14-15 карары белән социаль ятимлекне профилактикалау субъектларының үзара эшчәнлек регламенты расланды: Татарстан Республикасында республика наркология хезмәтенең, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссияләренең һәм югарыда аталган хосусый партнерның үзара эшчәнлеге регламенты кысаларында гамәлгә ашырыла башлады, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил координация ролен башкара.

Пилот программасы 2015 елның сентябрендә старт алды һәм 2016 елның апрелендә төгәлләнде. Пилот программаның нәтиҗәләре көткәннән дә артык булды:

аңа республиканың 5 муниципаль берәмлегеннән 45 хатын-кыз керде. 36 кеше тулы дәвалану курсы үтте (барлык катнашучыларның 80%), бу 98 балага «ятимлек» статусыннан котылып, үз гаиләсендә яшәп калырга мөмкинлек бирде.

Проектның уңышлы гамәлгә ашырылуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов аны 2017 елда да дәвам иттерү турында карар кылды, аны дәвам итү өчен 5 800 000 сум акча бүлеп бирелде. Проектның икенче этабында 8 муниципаль районнан (шәһәр округыннан) 42 хатын һәм 3 ир кеше катнашты:

Казаннан – 13 кеше, Чаллы –7 кеше, Кукмара районыннан – 8 кеше, Арча районыннан – 5 кеше, Балтач районыннан – 4 кеше, Түбән Кама районыннан – 3 кеше , Саба һәм Бөгелмә районнарыннан 1 әр кеше. 1 кат-

нашучы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме белән, якыннары хәбәр иткәннән соң катнашты. 2016 елгы проектта – Казан һәм Кукмара районыннан 3 гаилә пары катнашты. Икенче этапны гамәлгә ашыру төгәлләнгәннән соң 2017 елның язында аңа нәтиҗә ясалачак.

2016 ел Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасы белән берлектә гамәлгә ашырыла торган **«Балалар җәмәгать кабул итүе»** республика проекты бала хокукларын яклау механизмнарын камилләштерүгә ярдәм итүдә яңа эшчәнлек рәвеше елы булды. Проект Татарстан Республикасы балаларын хокукый агартуга, балаларда актив тормыш һәм гражданлык позициясен булдыруга, аларда позитив мораль-этик һәм әхлакый кыйммәтләрен тәрбияләүгә, яшь гражданнарны үзләре тормышына кагылышлы карарлар кабул ителгәндә катнашырга җәлеп итүгә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга ярдәм итүгә юнәлдерелә. 6 – 10 сыйныфларда укучы балалар өчен конкурс оештырылды. Хәзерге вакытта «Балалар җәмәгать кабул итүе» оешмасыннан 53 әгъза Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ярдәмчесенә әверелде.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, «Балалар җәмәгать кабул итүе» проекты беренче чиратта анда катнашучы балалар өчен укыту проекты булып тора. Аның төп тәшкилияте – балалар хокукларын яклау тематикасы белән катнашучыларны таныштыруга юнәлдерелгән профильле смена-лар кысаларында гамәлгә ашырыла торган укыту программасы, аңа хокукый мастер-класслар, тренинглар, эшлекле, интеллектуаль һәм мәдәни-танып белү уеннары, төрле министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре белән очрашулар керә.

Моннан тыш, хокук сагында торучылар яшьләр социаль челтәрләрендә актив эш алып баралар: балаларга бәйле вакыйгалар турында белеп, алар хакында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хәбәр итәләр.

Шуның белән бергә, алар балаларга кагылышлы яңа проектлар өчен күп төрле идеяләр тәкъдим итәләр. Узган елгы кызыклы идеяларның кайберләре: «Сак бул», «Имин селфи», «Дөнья китабы», «Хокукый квест». Өстәвенә, балалар арасыннан булган җәмәгать ярдәмчеләре, балалар фикерен туплауда үзенчәлекле мониторинг булып торалар, шул рәвешле муниципаль берәмлекләрдә яшәүче балаларның мәнфәгатьләрен чагылдыралар.

Проект Татарстан Республикасы балаларын хокукый агартуга, балаларда актив тормыш һәм гражданлык позициясен булдыруга, аларда позитив мораль-этик һәм әхлакый кыйммәтләрен тәрбияләү, яшь гражданнарны үзләре тормышына кагылышлы карарлар кабул ителгәндә катнашырга җәлеп итү, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә

яшәүче бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга ярдәм итүгә юнәлдерелә, алар төрле министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, вәкилләре белән очрашуларда катнашалар.

2016 елның 29 февраленнән 3 мартына кадәр «Балалар җәмәгать кабул итүе»нең икенче укыту сменасы булып узды. Анда республиканың һәр районыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашты.

Смена кысаларында балалар Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булдылар, анда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А.Ратникова белән очраштылар;







Татарстан Республикасы Югары судында булу кысаларында Югары суд рәисе И.И. Гыйләҗев һәм җинаять эшләре буенча аның урынбасары М.В.Беляев белән очраштылар;



Татарстан Республикасы Конституция судында булып, Татарстан Конституция суды Аппараты җитәкчесе А.Л.Васин белән очраштылар;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсендә булып, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары Ә.С. Әхмәтшин, процессуаль контроль бүлеге җитәкчесе М.В.Мәхмүтов, кадрлар бүлеге мөдире Ф.К.Вәлиева белән очраштылар;







Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил Аппаратында булдылар, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил С.Х.Сабурская белән очраштылар;



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән эш тәртибендә очраштылар;



Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түләүсез юридик ярдәм күрсәтү секторы мөдире Н.Н.Фәрхуллина белән очраштылар.

2016 елның ноябрендә «Ялкын» балалар савыктыру лагеры базасында «Балалар җәмәгать кабул итүе»нең өченче укыту сменасы булып узды. Смена кысаларында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы В.Н.Демидов, Татарстан Республикасы прокуратурасының балигъ булмаганнар эшләре һәм яшьләр турында законнарның үтәлешенә күзәтчелек итүче бүлек башлыгы А.Ф.Хөсәенов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.А.Владимирова, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсендә аеруча мөһим эшләрне ачу идарәсе җитәкчесе урынбасары И.Г.Сыраев белән очраштылар.







Смена вакытында балалар өчен эшлекле уен форматында мастер-класс үткәрелде, ул конфликтларны бетерү белүгә, балаларның һәм кешенең хокукларын белүгә юнәлдерелгән квест-уеннардан гыйбарәт булды. Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре «түгәрәк өстәл, үткәрделәр», проектның үсеш

перспективалары турында фикер алыштылар. Һәр катнашучы проектны үстерү турында үз фикерен әйтте.



2016 елның 24 гыйнварында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы махсус дәүләт стипендиатлары, федераль, округ яшьләр форумнарында катнашучылар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы белән «Волга» яшьләр үзәгендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең яшь ярдәмчеләре проект кысаларында беренче уңышларын тәкъдим иттеләр.

2016 елның апрелендә П.А.Астаховның Татарстан Республикасына рәсми визиты барышында «Балалар җәмәгать кабул итүе» республика проекты Россия Федерациясе Президенты каршында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.А.Астаховка күрсәтелделәр.







«Сәләт» яшьләр үзәге базасында Россия Федерациясе Президенты каршында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.А.Астахов Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ярдәмчеләре – «Балалар җәмәгать кабул итүе» белән очрашты.

Балалык мәсьәләләренең аерым проблемаларына багышланган ачык чаралар үткәрелү республикада балалар хәленә уңай йогынтының бер мисалы булып тора.

1 июньдә Халыкара балаларны яклау көнендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе катнашында 2016 елның 30 маенда Казан шәһәрендә Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан яклау буенча республика форумы үткәрелде.



Форумның максаты – Татарстан Республикасында балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүче тискәре мәгълүматтан яклау системасы булдыру турында фикер алышу

Оештыруда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы хатын-кызларының

«Мәрхәмәт-Милосердие» төркеме, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы, В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП) катнашты.

Форумның пленар утырышында Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Республикасы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисе В.Г. Шәйхразиев, Татарстан Республикасы буенча Баш федераль инспектор Р.З.Тимержанов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге рәисе Р.А.Ратникова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт-Милосердие» төркеме җитәкчесе Т.П.Ларионова, Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Л.Р.Фазлыева катнаштылар.



Форум кысаларында балаларның мәгълүмати иминлегенең актуаль мәсьәләләре каралды, заманча реаль һәм потенциаль хәтәрләр, массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясе, басма продукция, төрле чыганаклардагы аудиовизуаль продукция, шулай ук тамаша чаралары аша, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет», мобиль радиотелефон элемтәсе аша таратыла торган мәгълүмат агымының балалар өчен тискәре йогынтысы турында фикер алышу оештырылды.

Форумда ике төп дискуссия тармагы эшләде.

Аның беренчесе «Интернет» челтәрендә имин мәгълүмат киңлеген булдыру темасына багышланды. Фикер алышу модераторлары: Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина һәм Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге җитәкчесе Т.С.Камалетдинова булды.

Икенче панель дискуссиясе заманча реаль һәм потенциаль хәтәрләр, массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясе, басма продукция, төрле чыганаклардагы аудиовизуаль продукциядә позитив контент һәм зыянсыз мохит булдыруга багышланды. Фикер алышу модераторлары: Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге рәисе Р.А.Ратникова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.А.Владимирова, һәм «События» интернет-порталы һәм РБК-Татарстан баш мөхәррире К.Р.Шлыков булды.

Форум эшендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы прокуратурасы һәм башка хокук саклау органнары, федерал күзәтчелек органнары (Роскомнадзор, Роспотребнадзор) җитәкчеләре һәм вәкилләре, мәгълүмат продукциясе әйләнеше өлкәсендә эшләүче вазыйфаи һәм юридик затлар, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә белгечләр, Идел буе федераль округындагы субъектлардан килгән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре рәисләре, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, балалар һәм ата-аналар җәмәгатьчелеге вәкилләре – барлыгы 350гә якын кеше катнашты. Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасының барлык районнарыннан һәм шәһәрләреннән килгән 53 балалар җәмәгать ярдәмчесе форумның иң төп катнашучылары булды, алар әлеге катлаулы проблема буенча үз фикерләрен җиткерделәр.





Форумда баланың зыянсыз мәгълүмат мохитенә хокукын тәэмин итүнең хокукый аспектларын, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хакимият, хокук саклау органнары, балалар өлкәсендә эшләүче оешмаларның балаларның сәламәтлегенә һәм (яисә) физик, психик, рухи, әхлакый үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан саклау буенча вәкаләтләрен һәм компетенцияләрен яктыртуга зур әһәмият бирелде.



Форумда катнашучылар балаларның сәламәтлегенә һәм (яисә) физик, психик, рухи, әхлакый үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан саклау эшенең Татарстан Республикасында аерым бер системасы булуны билгеләп үттеләр; дәүләт, иҗтимагый, хокук саклау, хәйрия оешмаларының, бизнес җәмәгатьчелекнең, төрле иҗат берләшмәләренең, педагогларның, ата-аналарның балалар проблемаларын хәл итү, шул исәптән мәгълүмат иминлеге өлкәсендә дә яклау юнәлешендә инициативаларның актив хуплануын күрсәттеләр. Позитив мәгълүмат киңлеге булдыру, балаларны һәм ата-аналарны медиакуркынычсызлык нигезләренә өйрәтү, балаларны интернет бәйлелектән һәм башка бәйлелекләрдән профилактикалау,

карала торган мәсьәләләрдә җәмәгатьчелекнең һәм коммерциячел булмаган оешмаларның роле буенча тәкъдимнәр эшләүгә басым ясалды.

2016 елның 18 апрелендә Казан шәһәрендә В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты (ИЭУП) базасында узган *«Детство без насилия» дигән республика форумы балалар проблемаларына багышланган тагын бер актуаль вакыйга булды.*



Форумны оештыручылар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитеты, Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге, В.Г.Тимирясов ис. (ИЭУП) Казан инновация университеты булды.

Чараның максаты – балаларга карата көч куллану проблемасына җәмәгатьчелекнең игътибарын арттыру һәм аны хәл итүгә профессиональ даирәләрне җәлеп итү.

Форумның пленар утырышында Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Г.Л.Удачина доклад белән чыгыш ясады.

Республика форумының эше алга таба өч мәйданчыкта дәвам итте:

педагог-психологлар өчен профессиональ мәйданчыкта, ул белгечләргә тәжрибә уртаклашу, ашыгыч ярдәм алымнарын һәм зыян күргән балаларга ярдәм итү технологияләрен үзләштерү урыны булды;

ата-аналар һәм шушы юнәлештә белем алырга теләүче балалар, яшүсмерләр өчен тематик мәйдан булды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үткәрә торган чараларны һәм проектларны гамәлгә ашыру даими һәм системалы рәвештә 2017 елда да дәвам иттереләчәк.


1.6. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар мәнфәгатендә Россия регионнары белән хезмәттәшлегенең һәм халыкара хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балачакны яклау буенча Россия һәм дәүләт яки хөкүмәтнеке булмаган халыкара институтлар белән хезмәттәшлеген дәвам итте.

2010 елдан башлап Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясенең барлык регионнарындагы диярлек бүгенге көндәге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрне берләштереп торучы Россия Федерациясе субъектларындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр ассоциациясендә (алга таба – Ассоциация) әгъза булып тора.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил *Ассоциация составындагы* эшчәнлеге кысаларында Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм Ассоциация тарафыннан оештырыла торган еллык бөтенроссия чараларында катнашып килә.

2016 елның 16 – 17 маенда Ростов-на-Дону шәһәрендә ***Россия Федерациясе субъектларындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең XIII Бөтенроссия*** съезды узды.



Съезд темасына «Балигъ булмаган пациентларның хокукларын яклау: бурычлары, проблемалары һәм аларны хәл итү перспективалары» мәсьәләсе чыгарылган иде. Съездда балаларның сәламәтлеген саклау, шул исәптән яшәүгә һәм сәламәтлек саклануга, арзан һәм сыйфатлы медицина ярдәменә балаларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру өлкәсендә Россия дәүләт сәясәтенең мөһим проблемалары турында фикер алышынды. Медицина тернәкләндерүенә балалар хокукларын гамәлгә ашыру буенча регионнар тәҗрибәсе өйрәнелде; балигъ булмаган пациентларның сәламәтлеген саклау һәм бозылган хокукларын торгызу өлкәсендә балаларның хокукларын яклау проблемалары һәм соматик, психик һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм башлангыч чорында ачыклау өлкәсендә балаларның хокукларын яклау, туклану сыйфатын тәэмин итү һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру мәсьәләләре каралды; мәктәпкәчә белем бирү, гомуми һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында медицина ярдәме күрсәтү проблемалары, шулай ук сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалидлыклары булган балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм аларны дарулар белән тәэмин итү, балигъ булмаган пациентларның паллиатив ярдәмгә хокукларын яклау проблемалары өйрәнелде.

Съезд барышында Татарстан Республикасы исеменнән Анжела Вавилова исемендәге Фонд Идарәсе рәисе, «Балалар хосписы» коммерциягә карамаган хосусый медицина учреждениесе Идарәсе рәисе В.В.Вавилов балигъ булмаган пациентларга паллиатив ярдәм күрсәтүнең уникаль тәҗрибәсен күрсәтте.

Съезд кысаларында түбәндәге мәсьәләләр турында фикер алышу мәйданнары эшләде:

балаларның файдалану мөмкинлеге булган, бушлай һәм сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтелүгә, дарулар белән тәэмин ителүгә һәм медицина тернәкләндерүенә хокукларын гамәлгә ашыруның регионнар тәҗрибәсе;

сәламәтлек саклау өлкәсендә балаларның хокукларын хокукый, шул исәптән судта, яклау һәм балигъ булмаган пациентларның бозылган хокукларын торгызу проблемалары;

соматик, психик һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм башлангыч чорында ачыклау өлкәсендә балаларның хокукларын яклау, туклану сыйфатын тәэмин итү һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру;

балигъ булмаган пациентларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлекне (шул исәптән мәгълүмат алмашу өлешендә) оештыру;

балаларның психик сәламәтлеген саклау һәм психиатрия стационарларындагы балигъ булмаган пациентларның хокукларын яклау проблемалары;

балаларның сәламәтлеген саклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу һәм ата-аналарның хокукларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру проблемалары (шул исәптән балалар иммунопрофилактикасы вакытында һәм аларга медицина ярдәме күрсәтелгәндә);

мәктәпкәчә белем бирү, гомуми һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында медицина ярдәме күрсәтү проблемалары;

ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларның (сукбай балаларның, балигъ булмаган хокук бозучыларның, мигрантлар гаиләсеннән булган балаларның һ.б.ш.) сәламәтлек саклауга хокукларын яклау;

сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалидлыклары булган балаларга медицина һәм тернәкләндерү ярдәме күрсәтү һәм аларны дарулар белән тәэмин итү проблемалары;

балигъ булмаган пациентларның паллиатив ярдәмгә хокукларын яклау проблемалары.



2016 елның 28 – 29 ноябрендә Мәскәү шәһәрендә «Россиядә бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтының эшчәнлеген камилләштерү: бурычлар һәм перспективалар» дигән темага Россия Федерациясе субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең бөтенроссия киңәшмәсе булды.

Киңәшмәдә Россиядә бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институтын үстерүнең, бу институтның федераль һәм региональ дәрәҗәдәге эшчәнлеген гаиләне, ана һәм ата булуны, балачакны саклау өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру ашыруның төп стратегик юнәлешләре буенча координацияләүнең, балалар һәм балигъ булмаган балалары булган гаиләләрнең мәнфәгатьләрендә башка дәүләт институтлары

һәм гражданлык җәмгыяте институтлары белән нәтиҗәле багланышларын төзүнең иң мөһим мәсьәләләре турында фикер алышынды.



Киңәшмәнең пленар утырышында федераль округлар буенча регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эш тәжрибәләре тәкъдим ителде. Идел буе федераль округында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеге турындагы доклад белән, Идел буе федераль округында Вәкаләтле вәкилләрнең координация советы рәисе буларак, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина чыгыш ясады.

Киңәшмә кысаларында Стратегик сессияләр үтте, аларда түбәндәге мәсьәләләр каралды:

бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең опека һәм попечительлек органнары һәм башка дәүләт органнары, иҗтимагый берләшмәләр белән социаль сукбайлыкны кисәтү мәсьәләләре һәм авыр тормыш хәлендә калган гаиләләр белән эшләү буенча хезмәттәшлеге;

балигъ булмаганнар һәм балалы аналар арасында үз-үзләренә кул салуны профилактикалау, суицидлар ясауны пропагандалау фактларын булдырмау мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек;

югалган балаларны эзләү һәм аларга төрле яктан ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлеккә ирешү.



Стратегик сессияләрнең берсендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина модератор булды.

Оештырыла торган конференцияләр, форумнар, семинарлар, киңәшмәләр һәм «түгәрәк өстәл»ләр кысаларында аралашу тәжрибә алмашуда һәм хезмәттәшлек коруда мөһим.

2016 елның 7 – 8 сентябрендә Калуга шәһәрендә ***«Балалар! Россия! Киләчәк!» II Бөтенроссия балалар форумы*** булды, ул Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.А.Астахов ярдәме белән үтте.







Әлеге форумның үзенчәлеге шунда булды ки, анда регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр белән берәүттән Россия Федерациясенең һәр субъектыннан балалар катнашты. Татарстан Республикасыннан делегациядә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән бергә балалар иҗтимагый хәрәкәтләренең җәмәгать ярдәмчеләре һәм активистлары булган балалар да бар иде.





Төп идея – мөһим дәүләт карарларын кабул итү процессында балаларның фикерләрен исәпкә алу мөмкинлекләрен һәм механизмнарын табу. Шуңа күрә яшь катнашучылар арасында – региональ вәкаләтле вәкилләр каршындагы балалар советларыннан актив яшьләр һәм иҗтимагый балалар хәрәкәтләре вәкилләре.



Форумның пленар утырышында федераль округларда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең координация советлары һәр федераль округның «визит карточкасы»н күрсәтте. Федераль округ командалары тәкъдим иткән презентацияләрнең һәркайсы округ территориясенең үзенчәлеген, балалар мәнфәгатьләрендә Илкүләм стратегик гамәлләрне тормышка ашыруны күздә тотып, аның мәдәнияте, тарихы, рухи мирасы һәм хәзерге кыйммәтләре аша тасвирлады.






Форумның дискуссия мәйданнарында вәкаләтле вәкилләр белгеч хезмәттәшләре белән бергә балаларның хокукларын саклау һәм яклауның төрле проблемалары турында фикер алыштылар:

«Россия балалары сугышка, террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы»;

«Ватан тарихы – милли мәдәният һәм гражданлык башлангычы»;

«2020 еллар буыны»: рухи-әхлакый кыйммәтләр, тормыш планнары һәм перспективалар»;

«Чикләрсез дөнья: сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар безнең белән»;

«Безнең талантлар һәм сәләтләр – Россия үсешенең нигезләре»;

«Балалар үзидарәсе: тәҗрибә, бурычлар һәм перспективалар»;

«Балалар һәм яшүсмерләр өчен куркынычсыз мәгълүмати мохит»;

«Биегрәк, ераграк, көчлерәк: сәламәт яшәү рәвеше һәм безнең тормышта спорт»;

«Без – волонтерлык хәрәкәтендә актив катнашучылар».



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил форум кысаларында Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Бурычка тугрылык өчен» ведомство бүләге белән бүләкләнде.

2016 елның 21 мартында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина федераль бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан оештырылган «түгәрәк өстәл»дә катнашты. **«Яңа туган баланың яшәргә һәм сәламәтлеген сакларга хокукын яклау: проблемалар, бурычлар һәм аларны хәл итү тәҗрибәсе»** темасына багышланган чара Мәскәү шәһәрендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасында узды.



«Түгәрәк өстәл» кысаларында түбәндәге проблемалар һәм мәсьәләләр каралды:

гаиләнең начар хәлдә калуын профилактикалау, шул исәптән аны башлангыч чорында ук ачыклауны һәм социаль яктан начар хәлдә калган балалы гаиләләрне тернәкләндерүнең нәтиҗәле технологияләрен кертеп;

социаль яктан начар хәлдә калган балалы гаиләләрне башлангыч чорында ук ачыклау системасын ведомствоара оештыру һәм алар белән комплексы эшләү;

баланың үз гаиләсендә тәрбияләнүе өчен шартлар тудыру һәм балалардан баш тартуны кисәтү;

социаль сукбайлыкны профилактикалау.

«Түгәрәк өстәл»дә катнашучыларга фикер алышу өчен тәкъдим ителгән мәсьәләләрнең берсе Россия Федерациясе территориясендә «беби-бокс»лар куюның һәм алардан файдалануның хокукый булуы, криминология, социаль һәм әхлак-этика ягыннан нигезләнгән булуы турында иде.



2016 елның 19 – 20 июлендә Калининград өлкәсендә ***«Социаль сукбайлыкны профилактикалау максатларында исереклеккә, токсикоманиягә һәм наркоманиягә каршы көрәштә ведомствоара хезмәттәшлек» Бөтенроссия конференциясе булды.***

Чараны Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының Баш психиатор-нарколог белгече һәм Калининград өлкәсе Губернаторы оештырды.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачина конференция эше кысаларында Татарстан Республикасында социаль сукбайлыкны профилактикалауга юнәлдерелгән «Аеклык ноктасы» пилот проектын гамәлгә ашыру тәжрибәсе белән таныштырды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган бөтен россия күләмендә үткәрелә торган берничә акциядә катнашты. Шулай, 2016 елның 27 октябреннән алып 30 октябренә кадәр республиканың барлык мәктәпләрендә дә «Интернет» челтәрендә бердәм иминлек дәресе үтте.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре, кайбер гомуми белем бирү мәктәпләренең педагогик хезмәткәрләре өчен оештырылган «Баланың куркынычсыз мәгълүмат мохитенә хокукын тәэмин итү мәсьәләләре» темасына багышланган «түгәрәк өстәлләр»дә баш спикерлар булып, әлеге чараларда турыдан-туры катнаштылар.

Билгеле бер балаларга ярдәм күрсәткәндә ***бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең үзара хезмәттәшлеге*** аеруча мөһим. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә еш кына башка регионнарда балалар юлыга торган катлаулы тормыш хәлләрен хәл итү үзәгендә булырга туры килә.

Шулай, Самара өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.В.Козлова мөрәҗәгате буенча А., Т. исемле балигъ булмаган балаларның тормышлары урнаштырылды; Хабаровск краенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Л.Жукова гозере буенча К. исемле балигъ булмаганның яшәүгә һәм сәламәт булуга хокукы тәэмин ителде; Свердловск өлкәсендә

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил И.Р.Мороков мөрәҗәгате буенча җинаять эшен тикшерүдә ярдәм күрсәтелде; ата-ана каравыннан мәхрүм калган Т. исемле балигъ булмаганның тормышын урнаштыру мәсьәләсе Архангельск өлкәсе Губернаторы каршындагы бал О.Л.Смирнова мөрәҗәгатеннән соң хәл ителде; Пермь краенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.В.Миков үтенече буенча А. исемле балигъ булмаганга Россия Федерациясе гражданы паспортын бирү мәсьәләсен хәл итүдә ярдәм күрсәтелде; Томск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.Е.Эфтимович гозырнамәсе буенча М. исемле балигъ булмаганның тормышын урнаштыру мәсьәләсе бала мәнфәгатьләрендә хәл ителде.

2016 ел дәвамында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, үз чиратында, булышлык күрсәтүне сорап, балигъ булмаган балаларга алиментлар түләттерүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча Башкортостан Республикасы (М.М.Скоробогатова), Марий Эл Республикасы (Е.П.Бурдо), Мәскәү шәһәре (Е.А.Бунимович) балалар хокукларын яклаучыларына; балигъ булмаган балаларның тормышларын урнаштыруда ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча Архангельск өлкәсендә (О.Л.Смирнова), Адыгей Республикасында (А.Б.Игнашин), Ульяновск өлкәсендә (Л.А.Хижняк), Ямал-Ненец автоном округында (В.В.Орешкин), Саратов өлкәсендә (Т.Н.Загородная) бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр исеменә; атаның балалары белән аралашуга хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Марий Эл Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Е.П.Бурдо һәм Түбән Новгород өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил М.В.Ушакова исеменә; күпбалалы М. гаиләсенә түләүсез нигездә җир кишәрлеге бүлеп бирү мәсьәләсе буенча Әстерхан өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил А.А.Курмаева исеменә; Я. исемле балигъ булмаган кыз балага психологик ярдәм күрсәтү үтенече белән Новосибирск өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Л.М.Зябрева исеменә мөрәҗәгать итте.

Берсүзсез, бала хокукларын яклауның аерым мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән һәм регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр арасында докладлар һәм башка материаллар алмашу, гадәттәгечә, регионара хезмәттәшлекнең актив формасы булып кала.

Шулай, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне өйрәнде һәм анализлады:

федераль бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил соратуы буенча 3 проблемалы теманы һәм 6 төрле мәгълүмати белешмәне;

региональ вәкаләтле вәкилләр соратуы буенча 7 проблемалы теманы.

Регионара хезмәттәшлекнең мөһим өлешен регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең округ *координация советларында* үзара багланышлар коруы тәшкил итә. 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Идел буе федераль округы югарылыгындагы үз эшчәнлеген Идел буе федераль округында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация Советы Рәисе буларак башкарды.

2016 елга төп бурычлардан түбәндәгеләр билгеләнгән иде:

балаларның хокукларын нәтиҗәле яклау буенча Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектларындагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең уртак эшчәнлегенең төп юнәлешләрен эшләү;

бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институтына ярдәм итү һәм аларны үстерү өчен каралган чаралар күрү;

балачак хокукларын яклау өлкәсендә эшләүнең нәтиҗәле тәжрибәләрен алмашу;

Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектларында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итү торышына анализ.

Идел буе федераль округында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр хезмәттәшлеге һәм үзара багланышлары, гадәттәгечә, Координация советының план буенча һәм планнан тыш үткәрелә торган утырышлары кысаларында да, шулай ук округ эчендә уртак чаралар һәм проектлар оештыру форматында да алып барылды.



Идел буе федераль округында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координация советы эшчәнлеге кысаларында 2016 елның 27 маенда Түбән Новгород шәһәрендә ***«Алкогольгә бәйлелекне профилактикалауның һәм аннан терелтүнең заманча алымнары» дигән «түгәрәк өстәл»*** булды, аның эшендә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гаиләнең начар хәлдә калуын профилактикалау тәжрибәсе турындагы доклад белән катнашты.

29 – 30 майда Казан шәһәрендә Идел буе федераль округында регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр: Башкортостан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил М.М.Скоробогатова, Киров өлкәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Шабардин, Чуаш Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил В.В.Рафинов катнашында берничә чара узды

Координация советының күчмә утырышы Татарстан Республикасында «Балалар хосписы» эшчәнлеге тәжрибәсен өйрәнүгә багышлан-



ды. Тәҗрибә алмашу кысаларында хосписта вәкаләтле вәкилләр белән бергә Россия Федерациясенең берничә субъектының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча региональ комиссияләрнең рәисләре һәм җаваплы секретарьлары булып китте.

Моның белән бергә региональ хезмәттәшләр Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең региональ дәрәҗәдә эшләү тәҗрибәсе белән таныша, балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча Татарстан Республикасы тәҗрибәсен, балаларны яклау өлкәсендә региональ инициативаларны, регионда бала хокукларын яклауның законнар белән җайга салынуын, балалар мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә ведомствоара хезмәттәшлек системасын өйрәнә алдылар.



Моннан тыш, регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр 30 майда Казанда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы буенча үткәрелгән Балаларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан балаларны яклауны тәэмин итү республика форумында катнаштылар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Россия күләмендәге хезмәттәшлеген оештыру тәҗрибәсе ***уртак тикшерүләр*** уздыру вакытында дәвам итте.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тикшерү-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру компетенциясе Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан учреждениеләр белән чикләнә. Моны истә тотып, Татарстан балаларының хокуклары һәм мәнфәгатьләре тиешенчә тәэмин ителү-ителмәүгә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерүләр үткәрү легитим булмый һәм асылда әлеге учреждениеләргә барып кайту дәрәҗәсендә генә уза. Әлеге эшнең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан учреждениеләрне әлеге субъектларның бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләре белән бергә үткәрү тәҗрибәсе дәвам иттерелде.

Шулай, «Пермь крае буенча Россия ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесенә Татарстан Республикасын-



нан килгән тәрбияләнүчеләр белән ике күңелсез вакыйга булганнан соң, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачина Пермь краенда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.В.Миков белән бергә 15 мартта күрсәтелгән колониягә барды һәм Татарстан Республикасыннан килгән балалар белән шәхси очраштылар.



Моннан тыш, Пермь краена эш визиты кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачина мәктәпләрдәге дуслык хезмәтләренең «Ачыктан-ачык сөйләшү» форумында һәм «Авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрдән зыян күргән балаларны тернәкләндерү» семинарында катнашты.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырылган ***округ күләмендә үткәрелә торган берничә акциядә*** катнашты. Шулай, 2016 елның 1 сентябрендә Идел буе федераль округының Россия Федерациясе субъектлары мәгариф оешмаларында «Минем булачак һөнәрем» акциясе үткәрелде.

2016 елның апрелендә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.А.Астахов Татарстан Республикасына ***эш визиты*** ясады.



24 апрельдә Татарстан Республикасына, иң беренче чиратта, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.А.Астаховны Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов патронаты һәм Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе эгидасы астында үткәрелә торган «Созвездие- Йолдызлык – 2016» XVI Эстрада сәнгатенең ачык телевизион республика яшьләр фестивале йомгаклау гала-концертына мөхтәрәм кунак буларак рәсми чакырылган иде. Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил П.А.Астахов фестивальнең җиңүчеләрен котлады һәм фестивальне оештыручыларга махсус бүләкләр тапшырды.







Моннан тыш, П.А.Астахов эш визиты кысаларында «Иннополис лицее» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенә барып кайтты һәм лицей китапханәсенә биш мең китап бүләк итте. Мондый бүләк бүләк ясауның максаты – яхшы сүзне яратканн һәм аның кыйммәтен белгән кешеләрне, иҗади шәхесләрне, китап битләрендәге серләргә төшенмичә туктый алмаган кызыксынучыларны берләштерү, рухи һәм гыйлем шатлыгын, яңа белемнәр бүләк итү. Педагоглар коллективы Лицейда белем алучылар белән берлектә П.А.Астаховка лицейның физика-математика дисциплиналары (информатика, математика, физика) өлкәсендә гадәттән тыш сәләтләре булган талантлы балаларны укытуга һәм тәрбияләүгә юнәлдерелгән уку-укыту программаларын, информатиканы һәм мәгълүмат-коммуникация технологияләрен актив өйрәнгәндә һәм кулланганда укучыларның индивидуаль, иҗади һәм тикшеренү сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән берничә проектны тәкъдим итте.



Павел Астахов шулай ук «Сәләт» яшьләр үзәге белән танышты һәм «Балалар тарафыннан җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсе» проектында катнашучы балалар - Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы балалар җәмәгать ярдәмчеләре белән очрашты. Очрашу барышында яшьләр «Сак бул», «Куркынычсыз селфи», «Тынычлык китабы» һәм «Хокук квесты» дигән үз проектларын күрсәттеләр.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән һәм Россия Федерациясенең башка субъектларындагы хезмәттәшләре белән үзара багланышларын алга таба да үстерергә һәм ныгытырга уйлый.

Моның белән бергә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты 2016 ел дәвамында *гомумроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге башка чараларда да* катнаштылар.



13 – 17 майда ***VIII Ретт синдромы буенча Дөнья конгрессы*** узды. Ретт синдромы буенча Дөнья конгрессы дүрт елга бер тапкыр үткәрелә. Киләсе җыен 2020 елда Глазго шәһәрендә (Шотландия) узачак. Конгресс сирәк авырулар проблемасына иҗтимагый органнарның һәм дәүләт органнарының игътибарын юнәлтүне максат итә.



20 майда «Балаларга һәм яшүсмерләргә туберкулезга каршы ярдәмнең мөһим мәсьәләләре» дигән ***чит илләр катнашында регионара фәнни-гамәли конференция*** булды. Конференциядә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече – балалар фтизиаторы, медицина фәннәре докторы, профессор В.А.Аксенов, Идел буе федераль округының барлык регионнарыннан һәм Төньяк-Көнбатыш, Приморье, Урал федераль округларыннан, Пермь краеннан, Саха Якутия, Кырым, Беларусь һәм Казахстан республикаларыннан баш балалар фтизиаторлары белгечләре катнашты. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачина «Баланың сәламәтлек саклауга хокукын яклау» темасына доклад белән чыгыш ясады.



16 – 17 июньдә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкиле, Аппарат бүлеге башлыгы Э.Р.Сафина ***Балалар урлауның гражданлык-хокукый аспектлары турында 1980 ел Гаага Конвенциясен һәм Ата-аналарның җаваплылыгына һәм балаларны яклау чараларына кагылышлы юрисдикция, кулланыла торган хокук, тану, мәҗбүри үтәү һәм хезмәттәшлек турында 1996 ел Гаага Конвенциясен гамәлгә ашыру буенча бөтенроссия фәнни-методик семинар*** эшендә катнашты. Семинар барышында баланы законсыз күчереп йөртү яки бикләп тоту; баланы кире кайтару механизмнары; Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә баланы кире кайтарудан баш тарту өчен нигезләр; Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә баланы кире кайтару турында таләпләрне канәгатьләндерү өчен нигезләр; 1980 ел Конвенциясе буенча эшләрне карауның процессуаль үзенчәлекләре һәм балаларны чит илләрдән урлауның башка гражданлык-хокукый аспектлары мәсьәләләре каралды. Семинарда катнашучылар төп төшенчәләр һәм

конвенция белән хокукый җайга салу корылган концепцияләр һәм аларга аңлатмалар белән, шулай ук Конвенцияне практикада куллганда барлыкка килә торган иң катлаулы очраклар белән таныштылар.

2017 елда балалар мәнфәгатендә Россия эчендәге регионара һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендәге төп юнәлешләренең берсе булып калачак.

1.7. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый агарту эшчәнлегенең төп юнәлешләре

Халыкны хокукый агарту һәм балаларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен саклау зарурлыгы турында халыкка аң-белем һәм тәрбия бирү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бурычларының берсе булып тора.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хокукый агарту эшчәнлегендә төрле эш алымнарыннан файдалана: балалар белән турыдан-туры очрашулар, балалар һәм ата-аналар, төрле эшчәнлек башкаручы белгечләр алдында конференцияләрдә, семинарларда һәм «түгәрәк өстәл»ләрдә чыгыш ясау, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү. Бу эшчәнлек бала хокуклары турында гыйлемнәрне арттыруга юнәлдерелгән белем бирү, оештыру, мәгълүмат тарату юнәлешендәге чараларны дәүләт органнары, граждан җәмгыятенең төрле структуралары катнашында оештыруны үз эченә ала.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә балаларны хокукый агартуга өстенлек бирелә. Ул балигъ булмаган гражданнарның законнар белән гарантияләнгән хокуклары турында гына түгел, үз хокукларын яклау, бозылган хокукларны торгызу хакында консультатив ярдәм күрсәтүдән дә гыйбарәт. Мәгълүмати-хокукый агарту балаларда хокукый өлкәдә ышаныч һәм мөстәкыйльлек хисе тәрбияли, шуның белән аларның хокукый активлыгын арттыра, ә ул исә кешенең ихтыярый, аңлы, инициативалы, социаль һәм әхлакый, җаваплы мөнәсәбәтен күздә тота. Шуның белән бергә, граждан белеме алуның һәм кеше хокукларына өйрәтүнең әһәмияте балаларны иҗтимагый тормышта катнашырга җәлеп итүдә һәм аларда гражданлык хисе тәрбияләүдә чагыла.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең агарту эшчәнлеге балалар аудиториясенә дә, балалар өлкәсендә эшләүче белгечләргә, ата-аналар һәм, гомумән, киң җәмәгатьчелеккә кагыла. Бу өлкәдә эшнең нәтиҗәлелегенә омтылганда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил традицион рәвештә хокукый агартуның төрле формаларыннан файдалана: балалар һәм гаиләләр белән очрашу, конференцияләрдә, семинар-

ларда, түгәрәк өстәлләрдә катнашу, массакүләм мәгълүмат чаралары йогынтысы ярдәмендә позитив иҗтимагый фикер һәм хокукый белемнәр формалаштыру. Шуның белән бергә, бу эш бала хокуклары турында белем таратырга һәм гавами хакимият органнары, граждан җәмгыятенең төрле структуралары белән үткәрелә торган белем бирү, оештыру һәм мәгълүмат характерындагы чараларга бәйле.

Республика балаларын *мәгълүмати-хокукый агарту* һичшиксез беренче урында тора, аның нигезендә балигъ булмаган гражданнарга законнар белән гарантияләнгән хокуклар турында белгәннәрне тирәнәйтү генә түгел, аларны яклау һәм бозылганнарын торгызу механизмнары турында да хәбәрдар итү. Ул балаларда хокукый өлкәдә ышаныч һәм мөстәкыйльлек тәрбияли, аның хокукый активлыгын кызыксындыра. аңа үзен ирекле, аңлап һәм социаль, әхлакый җаваплы тотарга мөмкинлек бирә. Шуның белән бергә, граждан белеменең һәм кеше хокукларына өйрәтүнең әһәмияте балаларны иҗтимагый тормышка җәлеп итүдән, аларда гражданлык хисе тәрбияләүдән гыйбарәт.

Яшь гражданнарны хокукый агарту эшчәнлегендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үзенең эшен гадәти булмаган, кызыклы, инновацион һәм заманча, балалар күзлегеннән чыгып оештыра.

2016 ел дәвамында **«Балалар җәмәгать кабул итүе»** укыту проектын гамәлгә ашыру балаларда һәм яшүсмерләрдә актив граждан позициясен формалаштыруның яңа алымы булды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасы белән берлектә гамәлгә ашырыла торган **«Балалар җәмәгать кабул итүе»** республика проекты бала хокукларын яклау механизмнарын камилләштерүгә ярдәм итүдә яңа эшчәнлек рәвеше булды. Проект Татарстан Республикасы балаларын хокукый агартуга, балаларда актив тормыш һәм гражданлык позициясен булдыруга, аларда позитив мораль-этик һәм әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүгә, яшь гражданнарны үз тормышларына кагылышлы мәсьәләләргә җәлеп итүгә, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүче балаларның һәм яшьләрнең хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга һәм яклауга ярдәм итүгә юнәлдерелде.

Республика гомуми белем бирү оешмаларында 6 – 10 сыйныфларда укучы балалар өчен конкурс оештырылды. Хәзерге вакытта республика буенча «Балалар җәмәгать кабул итүе» оешмасыннан 53 әгъза Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ярдәмчесенә әверелде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар арасыннан беренче җәмәгать ярдәмчеләре булды.

«Балалар җәмәгать кабул итүе» проекты беренче чиратта анда катна-

шучы балалар өчен укыту проекты булып тора. Аның төп тәшкилияте – балалар хокукларын яклау тематикасы белән катнашучыларны таныштыруга юнәлдерелгән профильле сменалар кысаларында гамәлгә ашырыла торган укыту программасы, аңа хокукый мастер-класслар, тренинглар, эшлекле, интеллектуаль һәм мәдәни-танып белү уеннары, төрле министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре белән очрашулар керә.

2016 ел дәвамында 2 профильле укыту сменасы оештырылды.






2016 елның 29 февраленнән 3 мартына кадәр «Балалар җәмәгать кабул итүе»нең закон чыгару органы белән танышу сменасы булып узды. Анда республиканың һәр районыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашты.

Смена кысаларында балалар Татарстан Республикасы Дәүләт Советында булдылар, анда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А.Ратникова, Татарстан Республикасы Югары судында булу кысаларында Югары суд рәисе И.И. Гыйләҗев һәм җинаять эшләре буенча аның урынбасары М.В.Беляев, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил С.Х.Сабурская, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү комитеты җитәкчесе урынбасары Ә.С. Әхмәтшин, процессуаль контроль бүлеге җитәкчесе М.В.Мәхмүтов белән очраштылар. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түләүсез юридик ярдәм күрсәтү секторы мөдире Н.Н.Фәрхуллина һәм Татарстан Республикасы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре И.Х.Гарифуллина белән очраштылар.






2016 елның ноябрендә «Ялкын» балалар савыктыру лагеры базасында «Балалар җәмәгать кабул итүе»нең өченче укыту сменасы булып узды. Смена кысаларында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы В.Н.Демидов, Татар-

стан Республикасы прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турында законнарның үтәлешенә күзәтчелек итүче бүлек башлыгы А.Ф.Хөсәенов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.А. Владимирова, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү комитетында аеруча мөһим эшләрне ачу идарәсе җитәкчесе урынбасары И.Г. Сыраев белән очраштылар. Смена вакытында балалар өчен эшлекле уен форматында мастер-класс үткәрелде, ул конфликтларны бетерү белүгә, балаларның һәм кешенең хокукларын белүгә юнәлдерелгән квест-уеннардан гыйбарәт булды. Моннан тыш, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бала ярдәмчеләре «түгәрәк өстәл, үткәрделәр», проектның үсеш перспективалары турында фикер алыштылар. Һәр катнашучы проектны үстерү турында үз фикерен әйтте.



2016 елның 21 декабрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең иң актив җәмәгать ярдәмчеләре Екатерина Павельева, Тимерхан Шәйхетдинов, Полина Сухоносова, Камилла Кадыйрова бүләк рәвешендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына барып кайттылар. Татарстаннан килгән балалар өчен Россия парламентының түбәнге палатасы буенча экскурсия оештырылды, аның барышында активистлар Дәүләт Думасында сәяси партияләр фракцияләре кабинетларында булдылар, Россиянең әйдәүче партияләреннән сайланган кайбер депутатлар һәм аерым җитәкчеләр белән очраштылар, иң мөһиме Дума утырышында катнаштылар.

Проектны гамәлгә ашыру банда катнашучы балаларны ел саен ротацияләүне күздә тота, ә бу исә шул рәвешле хокукый яктан гыйлем туплаган укучыларның санын тагын да арттырырга мөмкинлек бирә.

Шуның белән бергә, «Балалар җәмәгать кабул итүе» проекты хокукый агартуның инновацион формасы буларак, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил җәмәгать ярдәмчеләренең иң төп бурычларыннан берсе үз муниципалитетында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге агарту эшчәнлеге аерым бер төбәктә генә түгел, бөтен республика буенча да балаларга хокукый белем бирүне тәэмин итәчәк.

Балаларның хокукый белемнәрен һәм аңнарын арттыру максатларында балаларны төрле ачык чараларга аларның ***хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы проблемалы мәсьәләләргә җәлеп итү мөһим.***



Мондый практика 2016 елда башланды, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе катнашында 2016 елның 30 маенда Казан шәһәрендә Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан яклау буенча республика форумы үткәрелде. (Форум эше турында Докладның күбрәк 1,5 бүлегендә язылды).







Форумның максаты Татарстан Республикасында балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүче тискәре мәгълүматтан яклау системасы булдыру турында фикер алышыну булды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Зеленодольск муниципаль районы буенча җәмәгать ярдәмчесе Тимерхан Шәйхетдинов форумда доклад белән чыгыш ясады, мәгълүмат иминлеге, аны тәэмин итү юллары турында үз фикерләрен җиткерде.

Балалар һәм өлкәннәр арасында популяр һәм уңышлы хокукый агарту форматларының берсе, һичшиксез, балаларның иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук бала шәхесенең граждани, хокукый формалашуын үстерүгә юнәлдерелгән конкурс чаралары оештыру һәм үткәрүдән гыйбарәт.

2016 елның сентябреннән ноябренә кадәр республикада чираттагы өченче, *«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» дигән мәгълүмати–социаль видеоролик республика конкурсы* (алга таба – III Конкурс) үткәрелде. Бу конкурс 2014 елдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәмендә һәм әлеге органнар тарафыннан гамәлгә куелган иде. Конкурсны шулай ук Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» региональ иҗтимагый оешмасы оештыра.

Конкурсның максатлары түбәндәгеләр: балалар һәм өлкәннәр җәмәгатьчелеген, дәүләт һәм муниципаль органнарны, оешмаларны


республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү мәсьәләләренә җәлеп итү, балалар хокукларын популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне мәгълүмати-хокукый агарту, аларның социаль –хокукый активлыгын кызыксындыру, хокукый гыйлемне һәм хокукый культураны үстерү, шулай ук үсеп килүче буында иҗади сәләтләрне үстерү.

Балалар һәм яшьләр арасында конкурсның популярлыгы елдан-ел арта: беренче Конкурска (2014 елда) республиканың 33 район һәм шәһәреннән 160 видеоролик алынган булса, икенче Конкурста (2015 ел) жюри карамагына республиканың 38 район һәм шәһәреннән 318 ролик керде. 2016 елда Конкурска Татарстан Республикасының барлык районнарыннан 419 конкурс эше алынды. Бу эшләрне төзүдә 2 меңнән артык кеше катнашты. Иң актив катнашучылар Казан шәһәреннән 40 видеоролик булды, Әлмәт районыннан 36 видеоролик, Чаллыдан 23 эш, Нурлат районыннан 21 ролик алынды. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, быел авторлар үз роликларын «Интернет»челтәрендә дә урнаштырдылар һәм аларны 15,5 меңнән артык тамашачы карады.

III Конкурсның жюри составына Г.Л.Удачина – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил – жюри рәисе, Ф.С.Гыймалдинов – ФГУП ВГТРК филиалы «Татарстан» ДТРК директоры, жюри рәисе урынбасары, Ф.Г.Хөснетдинов – Татарстан Республикасы Конституция суды рәисе, С.Х.Сабурская – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, А.С. Әхмәтшин – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү комитеты җитәкчесе урынбасары, В.Н. Демидов – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарә башлыгы, А.Ф. Хөсәенов – Татарстан Республикасы прокуратурасының бүлек башлыгы, Д.А.Туманов – «Созвездие-Йолдызлык» фестиваленең генераль продюсеры, А.Ф.Вәлиева – «Ак Барс Созидание» Хәйрия фонды директоры, Т.В.Забегина – Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Р.А.Сәхәбетдинова – «Яңа гасыр» ТРК «Балалар, яшьләр тапшыруы» иҗат берләшмәсе директоры, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре.







III Конкурсның җиңүчеләре булып күбрәк балл җыйган 10 конкурс эше авторы:

1. Мөбарәкшин Рамил Рәшит улы, Казан, «Бер минут – бик үк аз түгел» видеоролигы;

2. Макарова Лилия Геннадиевна, Зәй муниципаль районы, «Балаларны ташлама» видеоролигы;

3. Әхмәтҗанова Айзана Илдус улы, Ютазы муниципаль районы «Урыссу гимназиясе» МБОУ 3 сыйныф укучысы;

4. Тюрин Данил Денисович, Болотнов Павел Сергеевич, Казан шәһәре Вахитов районының аерым предметларны тирәнтен өйрәнә торган «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ «Глобус» Балалар мәктәп видеостудиясе укучылары, Нуретдинова Фирүзә Дамир кызы, педагог-оештыручы, Булатова Наталья Сергеевна, проект җитәкчесе, «38 статья. Хәрби хәрәкәтләр һәм сугышлар чорында балаларның саклануга хокукы»; видеоролигы;

5. Әхмәтҗанов Илдан Илдус улы, Ютазы муниципаль районы 2 нче Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 сыйныф укучысы, «Хокуклар дөньясында бала» видеоролигы өчен;

6. Александров Роман Андреевич, Астафьев Олег Валерьевич, Баратолиева Лола Сиявушовна, Воробьев Руслан Олегович, Галимов Даниил Эдуард улы, Горячкина Алина Евгеньевна, Медведева Радмила Магомедовна, Турица Анжелика Олеговна, Хафизова Эльвиа Рамил кызы, Эргашев Әмир Бәхтияр улы, Яшина Валерия Денисовна, Әлмәт муниципаль районы «Спартак» яшүсмерләр клубы каршындагы «Ассорти» театраль-музыкаль студиясе укучылары;

7. Шаһиев Әдип Эмил улы, 3 «А» сыйныфы укучысы, Шаһиева Рузалина Раушан кызы, Әлмәт муниципаль районы «1 нче Түбән Мактама урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ башлангыч сыйныф укытучысы, «Саклану, азатлык һәм тормыш» видеоролигы;

8. Әхмәтҗанов Адель Рамил улы, «В» сыйныфы укучысы, Карабанов Александр Валерьевич, Советлар Союзы Герое Ханжин Павел Семенович» исемендәге 1 нче Тәтеш урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ укытучысы, «Хокуклар дөньясында бала» видеоролигы өчен;

9. Сәлахетдинова Ләйсан Илсур кызы, Хәбирова Ольга Рөстәмовна, Алабуга 9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе «Демократик республика» Балалар иҗтимагый оешмасы вәкилләре, «Хокуклар дөньясында бала» видеоролигы өчен;

10. Гарифуллин Инсаф Рамил улы, Арча муниципаль районы «Иске Чүриле урта гомуми белем бирү мәктәбе», МБОУ 11 сыйныф укучысы, «Тиран түгел, тәрбияче бул» видеоролигы өчен.



Тамашачыларга иң ошаган катнашучы социаль челтәрләрдә урнаштырылган видеороликларга карата бирелгән тавышлар саны буенча билгеләнде. 2016 елда әлеге номинациядә Казан шәһәренең Мәскәү районындагы «34 нче урта гомуми белем татар-рус мәктәбе» МБОУ «ТНВ» (Творцы Нового Века) Балалар иҗтимагый оешмасы әгъзалары, «Буратинога ияреп» ролигы.

III Конкурска йомгак ясау тантанасы Бөтендөнья балаларны яклау көнендә – 2016 елның 18 ноябрендә булды. III Конкурс җиңүчеләрен һәм катнашучыларын бүләкләү тантанасы Казан дәүләт яшь тамашачы театры залында үткәрелде, бөтен республикадан 250 дән артык бала чакыртып китерелде.

Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм 20 000 (егерме мең) күләмендә премия тапшырылды. Моннан тыш, җиңүчеләр арасына кермәгән балаларга жюри әгъзалары инициативасы белән кызыксындыру бүләкләре һәм рәхмәт хатлары бирелде.

III Конкурста икенче этапка узган һәр балага, ә бу 218 эшнең авторы, конкурста катнашу турында таныклык тапшырылды.







Конкурста җиңүчеләрне бүләкләүдә катнаштылар: Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе В.Г. Шәйхразиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Т.П.Ларионова, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х.Сабурская, Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.А.Зарипова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынба-

сары А.Г. Исаева, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитеты әгъзасы К.А.Владимирова, Татарстан Республикасы Премьер-министрының җәмәгать берләшмәләре буенча киңәшчесе А.С. Кондратьев, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы А.А. Хамматова, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы, конкурсның жюри әгъзасы В.Н. Демидов, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, конкурсның жюри әгъзасы Т.В. Забегина, Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасары Г.С.Галимов, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Әхмәтшин, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары А.М. Каюмов, Татарстан Республикасы Юстиция министрының беренче урынбасары Р.М. Заһидуллин, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимов, Татарстан Республикасы Яшьләр һәм спорт министрлыгы урынбасары Р.М.Гарифуллин, ФГУП ВГТРК филиалы «Татарстан» ДТРК директоры, жюри рәисе урынбасары Ф.С.Гыймалдинов, «Созвездие-Йолдызлык» сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү республика үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе директоры Д.А. Туманов, «АК БАРС ЯҢАРЫШ» хәйрия фонды директоры А.Ф. Вәлиева, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы И.Х.Гарифуллина.









Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар җәмәгатьчелеге белән очрашуы хокукый агартуның популяр алымы булып кала.




2016 елның 29 сентябреннән 3 октябренә кадәр Татарстан Республикасы яшь гражданнарының *VI нчы* форумы кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән берлектә «Балаларны һәм яшьләрне хокукый яклау» секциясе эше оештырылды. Анда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларны хокукый яклауның актуаль мәсьәләләре белән таныштырды, ә Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан килгән балалар оешмалары активистлары, лидерлары һәм җитәкчеләре әлеге өлкәдә үз тәкъдимнәре һәм проектлары белән уртаклаштылар. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларның һәм яшьләрнең хокукый грамоталылыгын арттыруга, инклюзив белем бирү системасын үстерүгә юнәлдерелгән проектларның актуальлеген билгеләп үтте, аларны гамәлгә ашыруда нәтиҗәлелекне арттыру буенча тәкъдимнәр бирелде. Хокукый секциядә каралган идеяләр һәм проектлар Форумның йомгаклау секциясендә чагылыш тапты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гамәлгә ашыруга алынды.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Павел Астаховның һәм Татарстан Республикасы Президентының йөкләмәләрен үтәү йөзеннән «Минем беренче һөнәрем» дигән дәрес булды.

Белем бирү оешмаларын тәмамлаган укучылар өчен һөнәри һәм шәхси үсешнең әһәмиятен исәпкә алып, тәнкыйди фикерләү, актив тормыш позициясе, хокукый һәм коммуникатив культураның югары булуы, инициативлылык, нәтиҗәгә юнәлдерелгән үз эшчәнлеген планлаштыра белү, бер команда булып эшли, үз фикереңне җиткерә һәм дәлилли белү, «Минем киләчәктәге һөнәрем» дәресе кысаларында үткәрелгән мастер-класслар түбәндәге күнекмәләрне булдыруга юнәлдерелгән:

тормышта һәм укуда приоритетларны һәм аларга ирешү юлларын билгеләү;

коммуникацияләрне ачыклау һәм төрле вакытларда алардан файдалану;

карарлар кабул итү процедуралары, идарә итү һәм социаль җаваплылык этикалары, шулай ук гамәли иҗатның төрле юнәлешләре буенча мастер-класслар үткәрү.

Бердәм дәрес көнен әзерләү һәм үткәрү өчен уңышка ирешкән һәм абруй казанган һөнәр ияләре, республиканың халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре белгечләре, төрле оешмалардан вәкилләр, һөнәри берләшмә вәкилләре, «Яшь һөнәрчеләр» (WORLDSKILLS RUSSIA) региональ чемпионаты җиңүчеләре һәм призерлары җәлеп ителде.


Кибериминлек дәрәҗәсен арттыру, «Интернет» челтәрендә балалар иминлеге проблемасына ата-аналар һәм педагогларның игътибарын җәлеп итү, укучыларның цифрлы техниканы өйрәнүләрен үстерү максатында Бала хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил «Интернет» челтәрендә Бердәм куркынычсызлык дәресен үткәрүгә кушылды. Бердәм дәрес республика мәктәпләрендә 2016 елның 27-30 октябрендә узды. 2016 елда Россия Федерациясе бердәм дәресе Россия Мәгариф министрлыгы, Россия Коммуникация һәм элемтә министрлыгы, Интернетны үстерү институты, федераль һәм региональ хакимият органнары, шулай ук интернет-тармагы вәкилләренең актив ярдәме белән өченче тапкыр үткәрелде.

Балаларның зарарсыз мәгълүматка хокукын тәэмин итү мәсьәләләренең актуальлеген исәпкә алып, муниципаль хакимият органнары, хокук саклау органнары вәкаләтләрен һәм компетенцияләрен истә тотып, балалар өлкәсендә эшләүче оешмаларның балаларны аларның сәламәтлегенә һәм физик, психик, рухи, әхлакый үсешенә, балалар белән һәм балалар мәнфәгатьләрендә эшләүче белгечләрнең профессиональ компетенцияләре дәрәҗәсен арттыруга Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил муниципаль берәмлек башлыкларына Бердәм дәрес үткәрү инициативасын хуплау үтенече белән һәм җирле үзидарә органнары, Эчке эшләр министрлыгы һәм республика прокуратурасының территориаль органнары, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең территориаль бүлекчәләре, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (Роспотребнадзор) җитәкчеләрен, район предприятиеләре һәм оешмаларының профильле белгечләрен, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар җәмәгать ярдәмчеләрен укучылар, аларның ата-аналары һәм педагоглары алдында тиешле эшчәнлек кысаларында «Интернет» челтәрендә балаларның куркынычсызлыгы мәсьәләсе буенча спикер буларак катнашуга җәлеп итү максатында мөрәҗәгатьләр җибәрде.

Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Бердәм дәресне киңрәк яктырту максатында чарага массакүләм мәгълүмат чаралары җәлеп ителде, тематик мәгълүмат башкарма комитетлар, проектта катнашуга җәлеп ителгән мәгариф һәм башка төрле оешмаларның сайтларында урнаштырылды.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Казан шәһәренең өч белем бирү оешмасында педагоглар өчен «Зарарсыз мәгълүмат мохитенә бала хокукын тәэмин итү мәсьәләләре» дигән темага «түгәрәк өстәл» үткәрделәр.





Бердәм дәрес республиканың 1324 мәктәбендә (барлык мәктәпнең 98,9%) булды, укучыларның 72%ы, ата-аналарның 46%ы танышты, 982 мәктәптә тематик стендлар яңартылды.

Чараны үткәрүдә һәм оештыруда Казан, Чаллы шәһәрләре, Актаныш, Азнакай, Әгерҗе, Буа, Бөгелмә, Кукмара, Зәй Тукай, Саба, Балык Бистәсе, Түбән кама, Ютазы муниципаль районнары актив булды.



Балаларга консультатив ярдәм күрсәтү һәм аларның хокукый белемнәрен арттыру максатында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2016 елда урыннарга чыгып республиканың төрле балалар учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне **кабул итүен** дәвам итте. Балаларны кабул итү вакытында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аларның хокуклары һәм бурычлары белән гомуми танышуны да, аларны борчый торган хокукый һәм гомумкешелек характерындагы проблемаларны да күздә тота. Моннан тыш, балалар үзләрен борчыган мәсьәләләр буенча шәхсән һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән конфиденциаль аралашу тәртибендә консультация һәм төрле аңлатмалар алу мөмкинлегенә ия. Ел дәвамында мондый чаралар «Н.А. Галләмов исемендәге республика махсус мәктәбе» ГКСУВОУ, «Россиянең Пермь крае буенча ГУФСИНның Пермь тәрбия колониясе» ФКУда оештырылды.





Балаларны хокукый агартуда **Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның Аппараты**

хезмәткәрләренең гавами һәм җәмгыяви төрле форматларда (форумнарда, «түгәрәк өстәлләрдә» һ.б.) балалар белән турыдан-туры очрашуы зур роль уйный.

Мәсәлән, 2016 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре 100 дән артык чарада катнаштылар, шуларның кайберләре:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы хатын-кыз депутатларының «Мәрхәмәт- Милосердие» берләшмәсе чараларында катнашу;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты оештырган «Аутистик спектры бозылган балаларны иртәрәк ачыклау, социаль яраклаштыру һәм аларга инклюзив белем бирү өлкәсендә ведомствоара эшчәнлек мәсьәләләре» дигән темага «түгәрәк өстәл» эшендә катнашу (18.04.2016);

«Тыныч балачак» республика форумында балаларга каршы көч куллануны булдырмау проблемалары турында доклад белән чыгыш ясады (18.04.2016);

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына инвалид балаларны техник реабилитацияләү чаралары, протез-ортопедия әйберләре, шифаханә-курорт дәвасы белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау буенча Россия Федерациясе социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлеге идарәчесе Р.Р.Гайзатуллин катнашында узган киңәшмәдә катнашты;

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләренең тәрбиягә бала алган ата-аналар форумнарында катнашуы;

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләренең видеоконференция режимында Татарстан Республикасы муниципаль районнары опека һәм попечительлек органнары белгечләре уздыра торган республика киңәшмәләрендә катнашуы;

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләренең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм булган балалар оешмаларының мониторингы: йомгаклар һәм бурычлар» темасына түгәрәк өстәлдә катнашуы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карарының үтәлеше буенча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы үткәрде (26.10.2016);

Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән һәм ЮНЕСКО кысаларында уза торган «Созвездие-Йолдызлык» XVI яшьләр телевизион эстрада сәнгатенең зоналар буенча сайлап алу һәм финалга чыгу этабында жюри составында эшләү;

Татарстан Республикасы яшь гражданнарының VI форумы чараларында катнашу (29.09.2016 – 3.10.2016);

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләренең гомуми белем бирү оешмаларында укучылар, һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында «Намуслы яшәргә кирәк» дигән коррупциягә каршы юнәлештәге ижади эшләргә республика конкурсының эксперт советы эшендә катнашуы (12.10.2016 – 13.10. 2016) һәм башкалар.

Балалар омбудсменының балалар хокукларын һәм балалы гаиләләр хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә эшләүче белгечләрнең профессиональ ***компетенцияләрен арттыру*** буенча квалификация күтәрү курсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, педагог кадрлар, социаль өлкә, яшьләр сәясәте хезмәткәрләре өчен, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең рәисләре, җаваплы секретарьлары, белгечләре, прокуратура хезмәткәрләре өчен семинарлар үткәреп; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең киңәйтелгән күчмә утырышларын оештыру аша башкарыла.





Бала хокукларын тәэмин итүдәге актуаль мәсьләләр буенча 2016 елда **гавами акцияләр** үткәрү практикасы дәвам итте. Аларның эшчәнлеге массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртылды.

2016 елның 8 августында балигъ булмаганнарның хокук бозуларын һәм аларга карата кылынган җинаятьләрне кисәтү, балаларны һәм аларның ата-аналарын хокукый агарту максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Казан шәһәренең муниципаль комиссияләре белән берлектә «Татарстан Республикасында балалар сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян килүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (комендант сәгате турында) таләпләренең балалар һәм аларның ата-аналары тарафыннан үтәлешен контрольдә тоту буенча ведомствоара рейдлар үткәрде.

Ведомствоара рейд мәйданчыклары:

1. «Казан» гаилә үзәге (Казан, Сибгать Хәким урамы, 4 нче йорт);

2. «Кырлай» мәдәният һәм ял паркы (Казан, Гривканың бер ягы, 1а йорт);

3. Җәяүле Бауман урамы (Казан);

4. Җиңү паркы һәм «Парк Хаус» сәүдә – күңел ачу үзәге территориясе (Казан, Хөсәен Ямашев проспекты, 46 нчы йорт).



Рейд үткәрү буенча эшче төркем составына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җаваплы секретаре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы И.Х. Гарифуллина, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Казан шәһәренең муниципаль комиссияләре рәисләре һәм әгъзалары, балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләре вәкилләре, опека һәм попечительлек органнары вәкилләре катнашты.

Мондый акциянең төп максаты балаларның, ата-аналарның һәм киң җәмәгатьчелекнең балалар мәнфәгатьләрен яклау буенча законнарда билгеләнгән саклау һәм чикләү чараларын белү һәм үтәү зарурлыгына игътибар итү.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшенең һәм аның аппараты хезмәткәрләренең гражданнарны кабул итү барышында консультатив эше халыкны хокукый агартуның мөһим алымы булып тора. Гражданнарның язма һәм телдән шикаятьләрен карау кысаларында гамәлдәге законнарның нормаларын аңлату, хокук бозуларның асылын, аларны хәл итү юлларын күрсәтү нигезендә дәлилләнгән эш алып барыла.

Күпсанлы ***интернет-аудиторияне хокукый агарту активлыгына ярдәм итү максатында*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан рәсми сайт алып барыла. Сайтта федераль һәм региональ законнардагы яңалыклар турында оператив мәгълүмат бирә. «Сорау-җавап» рубрикасы алып барыла. 2016 елда сайтка керү 61 990не тәшкил итте, 2015 елга караганда 41%ка артыграк (2015 елда – 43 928).

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү өчен Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүне халык арасында популярлаштыру максатларында, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт учреждениеләренең, ял итү үзәкләренең мәгълүмат стендларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аңа мөрәҗәгать итү алымнары турында мәгълүмат урнаштырыла.




Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү өчен Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүне халык арасында популярлаштыру максатларында, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт учреждениеләренең, ял итү үзәкләренең мәгълүмат стендларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аңа мөрәҗәгать итү алымнары турында мәгълүмат урнаштырыла.

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендә хокукый белем бирүнең һәм дөньяга карашның дөрес формалашуын тәэмин итүнең иң көчле чыганакларының берсе – ***массакүләм мәгълүмат чаралары***. Хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән массакүләм мәгълүмат чараларының үзара эшчәнлеге тагын да активлашты. Бу шул исәптән ***массакүләм мәгълүмат чараларының*** балалар тематикасына тулаем һәм балалар хокук яклаучысы хезмәте эшчәнлеген өлешчә игътибарын арттыруга бәйле.

Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***массакүләм мәгълүмат чаралары*** вәкилләре белән 110 очрашу үткәрде (2015 елда – 34 очрашу).

21 очракта тематик брифинглар, матбугат конференцияләре, туры эфир , онлайн-конференцияләр оештырылды.



31 тапкыр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил телевизион тапшыруда һәм интервьюда катнашты, 3 тапкыр – радиоэфир кунагы булды. 14 матбугат басмасында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә карата зур интервьюлар урнаштырылды.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балалар мәнфәгатьләрендә уңышлы эшләгән өчен массакүләм мәгълүмат чараларына рәхмәт белдерә һәм җәмәгатьчелеккә җиткерүнең перспектив мөмкинлекләреннән берсе буларак алга таба хезмәттәшлекне бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең төрле мәсьәләләр буенча хокукый позициясен үстерүдә күрә.

2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАР ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ

БҮЛЕК 2


2.1. 2016 елда Татарстан Республикасында төп демографик тенденцияләр

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы белешмәләре буенча 2016 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында халык саны 3 868,7 мең кешене тәшкил итте.

2011 елдан алып республикада халыкның табигый артуы күзәтелә. 2016 ел йомгаклары буенча ул 10 959 кеше яисә 1000 кешегә (+)2,8 тәшкил итте, бу 2015 елның шул күрсәткечләренә караганда 1000 кешегә (+)2,7 артык һәм соңгы еллардагы иң югары күрсәткеч булып тора. Шул ук вакытта, Татарстан күрсәткече Россия Федерациясе буенча уртача күрсәткечтән югары (+) 0,0) һәм Идел буе федераль округы буенча уртача күрсәткечтән яхшырак (-) 0,7).

16 диаграмма


2009 – 2016 елларда Татарстан Республикасы халкының табигый артуы (кимүе)



Республикада туу күрсәткече югары булып кала бирә. 2016 елда 55 853 бала туды.

17 диаграмма

2009–2016 елларда Татарстан Республикасында туу динамикасы




Республикада 2015 елга кадәр балалар тууның артуы күзәтелгән иде, 2016 елда бу күрсәткеч 1,8 процентка кимеде һәм 1 000 кешегә 14,4 тәшкил итте. Узган ел республикада, 2015 ел белән чагыштырганда, 1 046 бала кимрәк туды. Шулай да бу Россия Федерациясе (12,9) һәм Идел буе федераль округы (12,9) буенча гомуми күрсәткечтән зуррак. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе белешмәләр буенча, туу турындагы таныклыкларның иң күбесе Казанда (20,2), Чаллыда (16), Тукай (16,1), Әлмәт (15,5), Түбән Кама (14,1), Алабуга (13,5) муниципаль районнарында тапшырылган.

Туучылар санына бала табу яшендәге хатын-кызларның сәламәтлеге торышы аеруча йогынты ясый. Соңгы 10 елда аларның саны кими, бу узган гасырның 90 нчы елларында балалар тууның кинәт кимеп китүе белән аңлатыла. Бу чорда туган балалар хәзер үзләре ата-ана булып җитешә, шунлыктан киләсе елларда балалар тууның кимүе көтелә.

Әлеге фактор йогынтысында беренче бала туу күрсәткече дә кимеде: 2007 елда барлык туган балаларның 55,8 % гаиләдә беренче бала булса, 2016 елда туган балаларның бары тик 40 проценты гына беренче бала булып туды. Республикада туучыларның артуы икенче һәм өченче балалар тууга бәйле рәвештә арта. Туучылар структурасында икенче һәм аннан соң туган балаларның саны, узган ел белән чагыштырганда, 1,5 процентка артты.

18 диаграмма


2016 елда беренче һәм аннан соң туган балалар өлеше



Соңгы елларда абортлар кими барса да, аларның гомуми саны шактый күп булуы борчу тудыра. 2016 елда ул туучыларның 33 процентын тәшкил итте.

19 диаграмма


2009 – 2016 елларда Татарстан Республикасында туучылар һәм абортлар саны (мең кеше)



2016 ел йомгаклары буенча республикада халыкның гомуми үлем күрсәткече кимеде. 2016 елда 44 894 кеше үлде, 2015 ел (46 483 кеше) белән чагыштырганда, 1000 кешегә 11,6 тәшкил итә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, бу 2009 елдан бирле иң яхшы һәм Россия Федерациясе (12,9) һәм Идел буе федераль округы (13,6) буенча уртача иң түбән күрсәткеч.

20 диаграмма


2009–2016елларда Татарстан Республикасында үлем динамикасы (кеше)



2016 ел йомгаклары буенча, бала тапкан аналар үлеме, 2015 ел белән чагыштырганда (8,8), 18,2 %ка кимеде һәм 100 000 исән туган балага 7,2, яисә, 4 очракны тәшкил итте. Бала тапкан аналар үлеме Казан шәһәрендә, Апас, Минзәлә муниципаль районнарында (берәр очрак) теркәлде һәм бер очрак билгеле яшәү урыны булмаган гражданкага бәйле булды.

21 диаграмма


2009 – 2016 елларда Татарстан Республикасында бала тапкан аналар үлеме динамикасы (кеше)



2016 елда Татарстан Республикасында туу һәм үлем дәрәҗәләре, гомумроссия күрсәткечләре белән чагыштырып, 22 диаграммада күрсәтелде.

22 диаграмма


2009 – 2016 елларда Татарстан Республикасында үлүчеләр һәм туучылар



Республикада балалар саны 2017 ел башына 795 959 кешене, яисә гомуми халыкның 20,6 процентын тәшкил итте. Соңгы еллардагы статистика мәгълүматларын анализлау күрсәткәнчә, 2010 елдан башлап балалар саны арта бара. Шулай ук балалар артуның уңай динамикасы да күзәтелә.

23 диаграмма

2009–2016 елларда балалар санының гомуми һәм яшьләре буенча динамикасы




Кече яшьтәге балалар саны (13 яшькә кадәр (13 яшьне дә кертеп) 647 403 кеше, яшүсмерләр (14 – 17 яшьлекләр (14 – 17 яшьне дә кертеп) – 148 556 кеше.

Балалар санын анализлау күрсәткәнчә, 2016 елда мәктәп яшендәге (7 – 17 яшь) балалар саны 420 544 кешедән 427 591 кешегә кадәр, ягъни 7 047 кешегә арткан.

Мәктәпкәчә яшьтәге (0 – 6 яшьлекләр) балалар саны арту тенденциясе сакланып кала. 2017 ел башына республикада 368 368 мәктәпкәчә яшьтәге бала исәпләнә. Шул ук вакытта, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны арту динамикасы кими бара. 2014 елда, 2013 ел белән чагыштырганда, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны 18 745 кешегә, 2015 елда, 2014 ел белән чагыштырганда, 15 370 кешегә арткан булса, 2016 елда ул, 2015 ел белән чагыштырганда, 11 663 кешегә артты.

24 диаграмма

2012 – 2016 елларда мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балалар саны динамикасы




Республикада халык үлеме күрсәткеченең кимүе фонында 2014 елдан алып ***балалар үлеменең*** дә кимүе күзәтелә. 2016 елда 473 бала үлде,

бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 40 балага кимрәк. Бу – соңгы 7 елда иң түбән күрсәткеч.

25 диаграмма

2009–2016 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме динамикасы



Гаилә кору һәм аерылышулар балалар мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла торган һәм күп очракта шуңа бәйле процесслар булып тора.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсе белешмәләре буенча, 2016 елда 25 778 никах теркәлгән, бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 4 794 (15,7 %) кимрәк. Аерылышулар саны 13 450 очракны тәшкил итте. Әлеге күрсәткеч узган ел дәрәҗәсендә калды.

26 диаграмма

2009 – 2016 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән никахлар һәм аерылышулар динамикасы



Теркәлгән никахлар һәм аерылышулар чагыштырмасы 2016 елда үзгәрмәде диярлек: теркәлгән 1000 никахка 522 аерылышу (2012 елда – 466, 2013 елда – 467, 2014 елда – 464, 2015 елда – 440) туры килде.

Хисапта китерелгән төп демографик күрсәткечләр Татарстан Республикасында балалар һәм балалы гаиләләр хәлен бәяләүдә җитди белешмә булып тора.

2.2. 2016 елда Татарстан Республикасында балаларның хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән төп гамәлләр һәм чаралар

Соңгы биш елда Татарстан Республикасында балалар учреждениеләре (балалар бакчалары, гомуми белем бирү мәктәпләре, балалар савыктыру лагерьлары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, спорт объектлары һәм мәйданнары, яшүсмерләр клублары, авыл клублары) челтәрләрен үстерүгә (төзү, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү) юнәлдерелгән уннан артык программа гамәлгә ашырыла, алар системалы һәм даими рәвештә башкарыла һәм барлык дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән финанслана.

2016 елда Татарстан республикасында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен иң яхшы тәэмин итүгә юнәлдерелгән мөһим гамәлләр, карарлар кабул ителде һәм чаралар үткәрелде.

Балалар сәламәтлеген саклау өлкәсендә амбулатор шартларда медицина- санитария ярдәмен оештыруны һәм балаларга махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүдән һәркемнең файдалана алу мөмкинлеген камилләштерү максатларында гамәлләр кылына.

2012 елдан башлап республикада беренчел звено медицина учреждениеләре челтәрен, шул исәптән авыл җирендә үстерүне һәм нығытуны максат итеп куйган чаралар үткәрелә.

2016 елда түбәндәгеләр кулланылышка тапшырылды:

61 модульле фельдшер-акушер пункты;

4 табиб амбулаториясе;

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең перинаталь үзәге;

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 3 нче дәвалау корпусында паллиатив ярдәм бүлеге;

«Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Г» блогы;

«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең акушерлык-гинекология корпусы;

«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном учреждениесенең балалар стационары;

Казан шәһәре «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең бала табу бүлеге;

Түбән Кама шәһәре «Бала табу үзәге булган балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 нче поликлиникасы һәм йогышлы авырулар бүлеге.

Татарстан Республикасында 3 яшькә кадәрге балаларны махсус сөт продуктлары белән түләүсез тәэмин итү буенча «Бәләкәч – Малыш» республика максатчан программасы гамәлгә ашырыла. Тармак максатчан программасын тормышка ашыруга 2016 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 430,6 млн. сум акча бүлеп бирелде, ул 3 яшькә кадәрге 40 936 баланы тукландыруны тәэмин итүгә тотылачак.

Республикада ***мәгариф өлкәсендә*** күрелә торган чаралар, беренче чиратта, республика мәгариф оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән берничә программаны гамәлгә ашыру белән характерлана.

2011 елдан алып республикада мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә өстәмә урыннар булдыру буенча президент программасы гамәлгә ашырыла, ул мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында чиратны бетерүгә һәм балалар бакчаларында урыннарга кытлык проблемасын хәл итүгә юнәлдерелгән. 2013 – 2016 елларда республикада 162 яңа балалар бакчасы төзелде, балалар бакчаларында 28 725 урын булдырылды, әлеге максатлар өчен 13 386,78 млн. сум акча тотылды. 2016 елда әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында 700 урынлы 4 яңа мәктәпкәчә мәгариф оешмасы сафка басты.



2016 елда төзелешне финанслауның гомуми күләме 451,6 млн. сум тәшкил итте. Шул ук вакытта, яңа балалар бакчалары төзү белән бергә, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен капиталь ремонтлау (реконструкцияләү) программасы да гамәлгә ашырыла. 2013 – 2016 елларда 1 717,52 млн. сумга 118 балалар бакчасы ремонтланды, шуларның 53е 2016 елда башкарылды. 2016 елда капиталь ремонт үткәрү өчен бирелгән акчаның гомуми күләме 624,6 млн.сум тәшкил итте.

Үткәрелгән чаралар республикада өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балаларны балалар бакчасында урыннар белән тәэмин итү буенча өстенлекле бурычны тулысынча диярлек хәл итәргә мөмкинлек бирде, 2016 елда өч яшьтән өлкәнрәк балаларны мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә урын белән тәэмин итү 2015 ел дәрәҗәсендә калды һәм 96 % тәшкил итте.

2012 елдан алып республикада гомуми белем бирү мәктәпләрен капиталь ремонтлау буенча республика программасы гамәлгә ашырыла. Әлеге программа кысаларында 2016 елда 95 мәгариф оешмасы, шул исәптән 15 махсус (коррекцияле) мәктәп капиталь ремонтланды. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен капиталь ремонтлау программасын финанслау күләме 2016 елда 1 899,76 млн. сум тәшкил итте.



2013 елдан алып 25 яңа гомуми белем бирү мәктәбе төзелде һәм кулланылышка тапшырылды, әлеге максатлар өчен 5 040,75 млн. сум акча тотылды, шуларның өчесе (2 392,75 млн.сумга) 2016 елда сафка басты.

Моннан тыш, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга гомуми белем бирү мәктәпләренә керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен 2012 елдан башлап республиканың гомуми белем бирү учреждениеләре биналарында уңайлы мохит булдыру эше башланды. 2013 – 2016 елларда 269, шул исәптән 30 махсус (коррекцияле) мәктәптә җайлаштыру чаралары үткәрелде. 2016 елда 5 гомуми белем бирү оешмасында, шул исәптән 2 махсус (коррекцияле) мәктәптә аз хәрәкәтләнүчән балалар төркемнәре өчен махсус объектлар барлыкка килде. Бу гамәлләр өчен 2013 елдан башлап 437,58 млн. сум акча тотылды.

Татарстан Республикасында төрле ведомстволарга карый торган 440 өстәмә белем бирү оешмасы эшли, аларда 321,7 мең бала шөгыльләнә, бу гомуми санның 82,7 % ын тәшкил итә. 2016 елда балаларга өстәмә белем бирү буенча дәүләтнеке булмаган 10 оешма (6 – спорт мәктәбе, 3 – әдәбият-сәнгать юнәлешендә, «Кванториум» балалар технопаркы) эшләде, аларда 3 611 кеше шөгыльләнде

1 нче таблица

Балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары, аларда шөгыльләнүче балалар саны

Ведомство исеме	Балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары саны	Аларда белем алучылар саны, кеше
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы	**155**	**193 120**
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы	**105**	**38 307**
Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча һәм спорт министрлыгы	**170**	**86 615**
Дәүләтнеке булмаган балаларга өстәмә белем бирү оешмалары челтәре	**10**	**3 611**
Барлыгы	**440**	**321 653**



Татарстан Республикасында беренче балалар технопаркы «Кванториум» моделе «ИТ-парк» югары технологияләр технопаркы» ДАУ һәм «КАМАЗ» ГАҖ катнашында автоном коммерциясез оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла. Проектны уңышлы башкаруга ирешү максатларында «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциясез оешмасы эшчәнлеге 2016 елда Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән 10,4 млн. сум, «КАМАЗ» ГАҖ исәбеннән 9,3 млн. сум күләмендә финансланды. Агымдагы елда «Кванториум» ДжуниорСкиллз ярышларының беренче чемпионнарын әзерләде инде.

2016 елда Татарстан Республикасында өстәмә белем бирүне үстерүгә федераль бюджеттан 74,4 млн.сум җәлеп ителде.

Татарстан Республикасында ***балаларның ялы һәм аларны савыктыру*** өчен кирәкле һәм тиешле шартларны тудыруга җитди игътибар бирелә.

2014 елда Татарстан Республикасында балалар өчен шәһәр яны стационар савыктыру учреждениеләрен капиталь ремонтлау һәм төзү буенча өчьеллык программа эшли башлады. 2014 – 2016 елларда әлеге программа буенча 36 шәһәр яны лагерена гомуми суммасы 382,5 млн. сумга ремонт ясалды. 2016 елда 12 лагерьда 100 млн. сумлык ремонт эшләре башкарылды.



Моннан тыш, 2016 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән өстәмә акчалар исәбеннән Чүпрәле муниципаль районының «Чайка» балалар савыктыру лагере төзелде һәм кулланылышка тапшырылды.

Шулай итеп, программаны гамәлгә ашыру барышында өч ел дәвамында 36 лагерьга капиталь ремонт ясалды, бу республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге лагерьларның гомуми санының 36 %ын тәшкил итә, ремонт ясалган лагерьлар 4 000 гә күбрәк балага хезмәт күрсәтә алды.

2016 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен финанслау күләме 1 727,1 млн. сум тәшкил итте, шуларның 1 346,5 млн. сумы Татарстан Республикасы бюджетыннан. Бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 114,4 млн. сумга артыграк.



2016 елгы савыктыру кампаниясендә 218 719 кеше, шул исәптән 19 030 авыр тормыш хәлендә калган бала ял итте, бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 2 034 кә күбрәк; 6 011 кеше Кара диңгез буенда ял итте (2015 елда – 5 731 кеше). Ял итү программасы социаль юнәлешле булуын дәвам итте: 54 706 бала түләүсез ял итү мөмкинлеге алды.

Хроник авырулардан интеккән балаларны дәвалауны оештыру максатыннан, балаларга шифаханә юлламалары алуга 2016 елда 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге 4 290 балага Татарстан Республикасы балалары ялын, аларны савыктыруны оештыру программасы буенча 141,2 млн. сум акча бүлеп бирелде.

Үсеп килүче буынның сәламәтлеген саклау йөзеннән республикада ***спорт объектлары челтәре*** инфраструктурасын үстерү, һичшиксез, өстенлекле бурыч булып тора.

Бүгенге көндә республикада 10 588 спорт объекты бар. Республиканың һәр районында эре спорт корылмасы (күпфункцияле спорт сарае, боз сарае, йөзү бассейны) эшли.

Хисап бирелә торган 2016 елда Татарстан Республикасында 517 спорт корылмасы кулланылышка тапшырылды, шул исәптән:

18 спорт залы, гомуми мәйданы 9 084 кв.метр, (Ютазы, Нурлат, Яңа Чишмә, Буа муниципаль районнарында, Чаллы, Казан шәһәрләрендә);


25 физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен төзелгән янкормалар, гомуми мәйданы 2 196 кв.метр (Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Кукмара, Балык Бистәсе, Саба, Баулы муниципаль районнарында, Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә);

7 йөзү бассейны, гомуми мәйданы 4 248 кв.метр, шул исәптән 32 ябык йөзү бассейны, Казан, Чаллы шәһәрләрендә һәм Әлки муниципаль районында;


1 футбол кыры, Биектау муниципаль районында.

27 диаграмма

ДЮСШ һәм СДЮСШОР саны



ДЮСШ һәм СДЮСШОРда шөгыльләнүче балалар саны



Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм муниципаль районнарының торак пунктларында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов ярдәме белән универсаль спорт мәйданчыкларын төзү буенча масштаблы проект гамәлгә ашырыла. Универсаль спорт мәйданчыклары баскетбол, волейбол, футбол, шулай ук турникта һәм урам тренажерларында физик культуры һәм спорт белән шөгыльләнү өчен яссы корылмалар рәвешендә төзелә. Спорт мәйданчыклары спорт мәктәпләре белән бергә гомуми белем бирү учреждениеләре мәнфәгатьләрен дә исәпкә алып, дәресләрне сыйфатлы итәргә мөмкинлек бирәчәк. Балалар өчен махсус шәһәрчекләр булдыру күз алдында тотыла.

2013 – 2016 елларда республиканың 45 муниципаль берәмлегендә гомуми суммасы 1 417,0 мең сумлык 671 күпфункцияле спорт мәйданчыклары төзелде. Узган ел гомуми суммасы 418,9 мең сумлык 188 күпфункцияле спорт мәйданчыгы файдалануга тапшырылды.

Республикада балалар һәм яшьләр өчен ял итү учреждениеләре челтәрен киңәйтүгә зур игътибар бирелә.

2015 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау программасы хупланды. Программаны гамәлгә ашыруның ике елында 55 яшүсмер клубына 200 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды, шуларның 27 се – 2016 елда. Программаны гамәлгә ашыру балаларның һәм яшүсмерләрнең яшәү урынына якын урнашкан учреждениеләр челтәрен үстерергә, аларның ялын оештыру өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирә.

Балаларның һәм яшүсмерләрнең культуралы ял итүен оештыруда, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүдә мәдәни, ял итү учреждениеләренең роле бик зур. Авыл халкының, шул исәптән авыл балаларының ялын оештыру һәм аларга иҗади мөмкинлекләр өчен заманча шартлар тудыру максатында, Татарстан Республикасында 2012 елдан авыл клубларын капиталь ремонтлау программасы эшләп килә. 2016 елда республикада гомуми суммасы 287,43 млн. сумлык 5 объект сафка басты, әлеге эшләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланды. Моннан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гомуми суммасы 337,44 млн. сумлык 43 мәдәният объекты төзекләндерелде.



Балаларга әдәбият-сәнгать юнәлешендә өстәмә белем бирүче өч учреждение капиталь ремонтланды. Яңа Чишмә муниципаль районында Балалар сәнгать мәктәбе өчен яңа бина төзелде.

Бала хокукларын тәэмин итүгә турыдантуры яисә якынча гына йогынты ясый тор-

ган гомуми характеристиканы күз алдына китергәндә, 2016 елда республикада балаларның һәм балалы гаиләләрнең ***торак мәсьәләсен*** хәл итүгә ярдәм чараларына тукталып китәргә кирәк.

Күпбалалы гаиләләргә торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез бирү (тапшыру) күздә тотылган федераль һәм региональ закон нормалары Татарстан Республикасында уңышлы хәл ителә. 2016 елның ахырына дәүләт ярдәменең әлеге чарасына хокукы булган һәм бу хакта мөрәҗәгать иткән 39 238 күпбалалы гаиләнең

69 %ы, ягъни 27 067 гаилә мондый хокукларыннан файдаланып, өлешле гомуми милеккә җир кишәрлекләре алдылар.

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итүне финанслауның гомуми күләме кимегәнлектән, әлеге йөкләмәне үтәү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 2016 елда шактый артты. Мәсәлән, 2015 елда гомуми финанслау күләме 356,4 млн. сум булса, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары 269,8 млн. сум иде, ә 2016 елда гомуми финанслау күләме 339,2 млн.сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары 288,7 млн.сум тәшкил итте.

2016 елда күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәме чараларын региональ финанслау күләме артты. Узган ел биш һәм аннан күбрәк баласы булган 42 күпбалалы гаиләгә торак субсидиясе түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 137,1 млн.сум (2015 елда – 128,1 млн.сум) акча бүлеп бирелде.

Гражданнарга торак мәсьәләсен социаль ипотека программасында катнашу юлы белән хәл итү мөмкинлеге бирә торган республика программасы кысаларында, балалары булган гаиләләргә ярдәм итү чарасы буларак 200 000 сум күләмендә акчалата компенсация бирү дәвам итте. Бу компенсация программада катнаша торган гаиләдә туган, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алынган һәр бала өчен бирелә. 2016 елда 5 706 гаиләгә компенсация бирелде, әлеге ярдәм чараларын финанслауның гомуми күләме 1 134,6 млн. сум тәшкил итте (2015 елда – 1 125,0 млн. сум, 2014 елда – 800,0 млн.сум).

Социаль ярдәм чараларының гамәлгә кергән системасы өлешендә 2016 ел дәвамында пособиеләр һәм түләүләр сакланып калды һәм, инфляция үсеше темпларын исәпкә алып, индексацияләнде. Узган ел республика бюджетының балаларга һәм балалы гаиләләргә гамәлдәге законнарда каралган социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә чыгымнары артты һәм 6 273,7 млн.сум (2015 елда – 5 965,9 млн. сум) тәшкил итте.

2.3. 2016 елда халыкара, федераль һәм республика законнарындагы бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсенә караган яңалыкларга күзәтү

Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру торышына гомуми бәя бирү өчен күрсәтелгән өлкәне хокукый җайга сала торган законнардагы үзгәрешләргә анализ ясарга кирәк.

2016 елда балаларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы ***халыкара хокук*** өлкәсендә Россия Федерациясе өчен зур яңалыклар булмады.

Илкүләм хокук системасында 2016 елда кабул ителгән һәм бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган түбәндәге иң мөһим ***федераль законнарны һәм закон актларын*** билгеләп үтәргә кирәк.

«Россия Федерациясе административ суд эше кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 28 июнендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә балигъ булмаган балаларның яисә хокукка сәләтсез дип танылган затларның законлы вәкилләре аларга медицина ярдәме алудан баш тарткан очракта медицина оешмаларының дәгъва белдерүен карау тәртибе җайга салынды.

Кертелгән үзгәрешләр нигезендә судлар, физик затларга һәм оешмаларга карата аерым административ хакимлек итү таләпләрен гамәлгә ашырганда, кеше һәм граждан хокукларын һәм иреклəрен, оешмалар хокукларын үтәүгә карата мәҗбүри суд контролен гамәлгә ашыруга бәйле административ эшләрне, шул исәптән балигъ булмаган баланың яисә суд тәртибендә хокукка сәләтсез дип танылган затның законлы вәкиле аның гомерен саклап калу өчен кирәкле медицина ярдәменнән баш тарткан очракта, бу балигъ булмаган баланың яисә хокукка сәләтсез дип танылган затның ихтыяҗларын яклау турында административ эшләрне карый һәм хәл итә алалар.

Балигъ булмаган баланың яисә суд тәртибендә хокукка сәләтсез дип танылган затның законлы вәкиле аның гомерен саклап калу өчен кирәкле медицина ярдәменнән баш тарткан очракта, бу балигъ булмаган баланың яисә хокукка сәләтсез дип танылган затның ихтыяҗларын яклау турында административ дәгъва гаризасы судка мондый дәгъва белән мөрәҗәгать итүче медицина оешмасы урнашкан урын буенча бирелә.

Мондый административ дәгъва гаризасы буенча административ эш суд тарафыннан эшләүгә кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә карала, ә медицина оешмасы кичекмәстән медицина ярдәме күрсәтү турында белдергән очракта – административ дәгъва гаризасы кергән көнне үк карала. Суд әлеге эшне караганда үзенә карата медицина ярдәмен күрсәтү турындагы мәсьәлә хәл ителә торган затны, әгәр бу аның сәламәтлегенә

зыян китермәсә, шулай ук башка кызыксынган затларны чакырырга хокуклы. Суд, пациент гомерен саклап калу максатларында медицина ярдәмен күрсәтү өчен нигезләр бар дип таныган очракта, административ дәгъва гаризасын канәгатьләндерү турында карар кабул итә. Таләпләрнең нигезсез булуы ачыкланса, суд тарафыннан административ дәгъва гаризасы канәгатьләндерүдән баш тартыла. Административ дәгъва гаризасын канәгатьләндерү турындагы суд карары балигъ булмаган балага яисә хокукка сәләтсез дип танылган затка медицина ярдәме күрсәтү өчен нигез булып тора. Суд административ дәгъва гаризасын канәгатьләндерү турындагы карарны кичекмәстән үтәүне таләп итәргә мөмкин, бу хакта карарның резолюция өлешендә күрсәтелә. Бу очракта судның дәлилләнгән карарын рәсмиләштергәнче үк административ дәгъва белдерүчегә суд карарының резолюция өлешенең танылганкүчермәсе бирелергә мөмкин.

2016 елның 3 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында», «Коммерциясез оешмалар турында», «Автоном учреждениеләр турында», «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында», «Россия Федерациясендә мәгариф турында» федераль законнарга үзгәрешләр кертелде. Аерым алганда, баланы әнисе яисә башка законлы вәкилләре иминләштерелгән медицина иминияте оешмасында иминләштерү мөмкинлеге бала тууны дәүләт теркәвенә алган көннән соң 30 көнгә кадәр озайтылды. Әлеге срок узганнан соң һәм бала балигъ булу яшенә җиткәнче йә тулы күләмдә хокукка ия булганчы мәҗбүри медицина иминләштерүе баланың атасы яисә анасы, йә башка законлы вәкиле сайлаган медицина иминияте оешмасында гамәлгә ашырыла. Әлеге Федераль законда шулай ук «диспансеризация» һәм «диспансер күзәтүе» төшенчәләре төгәлләштерелә һәм укучыларга (укырга кергән вакытта да, уку йортында да) медицина тикшеренүе уздыру тәртибе үзгәрелә.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 3 июлендәге 313-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә укучыларның сәламәтлеген саклау нормалары үзгәртелде. Белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда мәгариф оешмалары укучыларның сәламәтлеген саклауны тикшереп торуны тәэмин итәргә тиеш. Әлеге федераль закон нигезләмәләре буенча укучыларның сәламәтлеген саклау кысаларында педагогика хезмәткәрләрен беренче ярдәм күнекмәләренә өйрәтү дә керә.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 3 июлендәге 359-ФЗ номерлы Федераль законда ятим балаларга белемгә хокукның социаль ярдәм күрсәтү кысаларында бирелә торган өстәмә гарантияләре төгәлләштерелә. Аерым алганда,

ятим балаларга эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча региональ яисә җирле бюджетлар исәбеннән һөнәри әзерлек программалары узу хокукы бирелә, әлеге әзерлекне узу чорында аларга тулысынча дәүләт тәэминаты тәэмин ителә. Шулай ук дәүләт социаль стипендиясе уку чорында ата-анасының икесен дә яисә берсен генә югалткан 18 яшьтән 23 яшькә кадәр булган студентларга да түләнә.

«Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексына җинаять җаваплылыгыннан азат итү нигезләрен һәм тәртибен камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 3 июлендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон белән Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына административ хокук бозулар турында яңа норма өстәлде. Әлеге норма нигезендә, ата-ана балигъ булмаган баласын яисә унсигез яшькә җиткән хезмәткә сәләтсез баласын карап тоткан өчен, суд карарын яисә нотариаль таныкланган килешүне бозып, бу хакта тикшерү эше башланган көннән алып 2 ай дәвамында җитди сәбәпсез акча түләмәсә һәм бу гамәл өчен җинаять җаваплылыгы каралмаган булса, 150 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләүне яисә 10 тәүлектән 15 тәүлеккә кадәр административ кулга алуны, мәҗбүри эшләтү йә административ кулга алу кулланыла алмый торган затларга 20 меңгә якын административ штраф салу күздә тотыла.

2016 елның 19 декабрендәге 444-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ана (гаилә) капиталын индексацияләү хакында «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль закон нормаларының гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварына кадәр тукталды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең түбәндәге актлары балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган норматив хокукый актлар арасында яңалык булып тора.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге 380 номерлы карары белән Инвалид балаларның социаль адаптациясе һәм җәмгыятьтә интеграциясе өчен каралган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу чыгымнарын компенсацияләү юлы белән мондый товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга ана (гаилә) капиталы акчасын (акчаның бер өлешен) тоту кагыйдәләре расланды.

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 5 августындагы 796 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 2 июнендәге 491 номерлы карары белән элек хөкем ителгән затларның педагогика эшчәнлегенә һәм балигъ булмаганнар катнаша торган башка эшчәнлеккә катнашу мөмкинлеге ту-

рында регионнардагы балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләр тарафыннан карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – 1 нче кагыйдә) төгәлләштерелде. Аерым алганда, комиссия элек хөкем ителгән затларга карата, шулай ук кечкенә һәм уртача авырлыктагы, шул исәптән тыныч лыкка һәм кешелеккә каршы кылынган җинаять җаваплылыгы реабилитацияләнми торган нигезләр буенча туктатылган затларга карата карарлар кабул итә. Комиссия карар кабул иткәндә, 1 нче кагыйдәдә санап кителгәннәрдән тыш, мөрәҗәгать итүче балигъ булмаганнарның гомере, сәламәтлеге һәм әхлагы өчен куркыныч тудыруны ачыкларга мөмкинлек бирә торган башка хәлләр дә исәпкә алына.

«Күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру чаралары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары белән күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидлар өчен җайлаштыру шартларын тәэмин итү кагыйдәләре (алга таба – 2 нче кагыйдәләр) расланды.

2 нче кагыйдәләр инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр били торган һәм аларның даими яшәү урыны буларак файдаланыла торган Россия Федерациясе торак фонды, Россия Федерациясе субъектларының торак фонды, муниципаль торак фонды, хосусый торак фонды составына керүче торак урыннарга (алга таба – инвалидларның торак урыннары), шулай ук әлеге торак урыннар урнашкан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә (алга таба – инвалид яши торган күпфатирлы йорт) карата кулланылачак. 2 нче кагыйдәләр буенча, инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне тикшерү федераль, региональ һәм муниципаль ведомствоара комиссияләр тарафыннан федераль, региональ, муниципаль яисә хосусый торак фонды составына керә торган йортларда башкарыла. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, инвалидның торак урынын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтнең инвалид өчен җайлаштырылу дәрәҗәсен ачыклау максатыннан, тикшерү акты төзелә, бу актта, инвалидның ихтыяҗларын истә тотып һәм гомуми мөлкәтнең инвалид өчен җайлаштырылган булуын тәэмин итү максатларында инвалидның торак урынын һәм гомуми мөлкәтне җайлаштыру өчен техник мөмкинлекләрнең булуы (булмавы) турында бәяләмә бирелә. Инвалидның торак урынын һәм (яисә) инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне бу йортта (йортның бер өлешендә) булган конструкцияләрне үзгәртмичә генә җайлаштыру мөмкин булмаган очракта, комиссия күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) реконструкцияләүнең яисә капиталь ремонтлауның икътисадый яктан максатка ярашлы булуын тикшерү турында карар кабул итә. Мондый тикшерүне үткәрү тәртибе Россия Федерациясе Төзелеш ми-

нистрлыгы тарафыннан билгеләнә. Карарда шулай ук инвалидның торак урынын һәм күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне инвалид өчен җайлаштыру таләпләре, торак урынын инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру таләпләре дә расланды.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 8 декабрендәге 2622-р номерлы күрсәтмәсе белән 2017 елга инвалид балалар өчен махсуслаштырылган дәвалы туклану продуктларының исемлеге расланды. Яңа исемлеккә 69 позиция кертелде (2016 елда – 54 позиция), аерым алганда, «Нутриген», «Афенилак», «MD мил ФКУ», «П-АМ» коры катнашмалары, коры порошоклары һәм башкалар.

Балалар мәсьәләләрен җайга сала торган тармак федераль норматив хокукый актлар арасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы документлары аеруча зур әһәмияткә ия. Алар арасында түбәндәгеләр бар:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2016 елның 5 маендагы 279н номерлы приказы белән Россия Федерациясе территориясендә медицина оешмаларында (шифаханә-курорт оешмаларында) һәм медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка оешмаларда өлкәннәргә һәм балаларга шифаханә-курорт дәвалавын оештыру һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләре (алга таба – 3 нче кагыйдәләр) расланды. Әлеге кагыйдәләрдә каралганча, шифаханә-курорт дәвалавы авыруларны профилактикалау, савыктыру максатларында организмның саклау-яраклашу реакциясен активлаштыруга; организмның җәрәхәтләр, операцияләр һәм хроник авырулар аркасында бозылган функцияләрен торгызуга һәм (яисә) компенсацияләүгә, ремиссия чорын озайтуга, авыруның көчәюен тоткарлауга һәм, медицина реабилитациясенең бер этабы буларак, инвалидлык алуны кисәтүгә юнәлдерелгән. Шифаханә-курорт дәвалавы этаплылык, даимилек һәм беренчел медик-санитар ярдәм, махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмалары арасында дәвамлылык принципларына таяна. Шифаханә-курорт дәвалавы төрле табибларның: белгеч табибларның, диетологларның, физиотерапевтларның, дәвалау физкультурасы табибларының һәм башка табибларның; урта медицина персоналының; югары һәм урта медицина белеме булмаган башка белгечләрнең (инструктор-методистлар, башка белгечләр) үзара эшчәнлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла. 3 нче кагыйдәләрдә медицина оешмасына шифаханә-курорт дәвалавы өчен кабул ителгәндә нигез булып торучы документларның исемлеге бирелә. Моннан тыш, балалар өчен шифаханә, шул исәптән ата-аналары белән бергәләп дәвалану өчен булган (туберкулез авыруы шифаханәләреннән тыш) шифаханәләр эшчәнлегенең тәртибе төгәлләштерелә.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2016 елның 5 маендагы 281н номерлы боерыгы белән балаларны шифаханә-курорт дәвалавы өчен медицина күрсәтмәләре исемлеге расланды.

«Савыктыру һәм оешкан ял чорында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтүнең Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2012 елның 16 апрелендәге 363н номерлы боерыгы белән расланган тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2016 елның 13 маендагы 295н номерлы боерыгы нигезендә балаларны ял итү һәм савыктыру оешмаларына җибәрүгә каршы килә торган исемлеккә үзгәрешләр кертелде. Күрсәтелгән учреждениеләргә медицина ягыннан түбәндәге каршылыклар булмаган балалар җибәрелергә тиеш:

кискенләшкән чорда һәм кискенләшер алдыннан соматик авырулар, кискенләшү чорында һәм декомпенсация чорында хроник авырулар;

изоляция чоры беткәнче йогышлы һәм паразит авырулар, шул исәптән күз, тире зарарлануы, инфестацияләр (бетләү, корчаңгы);

«эчәк инфекциясе бактерияләре булу, дифтерия авыруы» диагнозы куелганнар;

кахексия.

Боерык белән шулай ук түбәндәгеләр билгеләнгән:

дәвалаучы табиб билгеләгән дәвалану режимын (диета, медицинада кулланыла торган дарулар һәм махсуслаштырылган дәвалы туклану продуктлары кабул итү) үтәргә мәҗбүр булган балалар үзләре өчен шартлар тудырылган, шул исәптән педиатр табиб, дарулар һәм махсуслаштырылган дәвалы туклану продуктларын саклау өчен шартлар булган учреждениеләргә генә җибәрелә;

физик, психик, интеллектуаль яисә сенсор җитешсезлекләре аркасында чит кеше ярдәменә һәм (яисә) индивидуаль ярдәмгә мохтаҗ балалар, законлы вәкилләре яисә озатып баручы затның билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә кәгазе һәм сәламәтлеге торышы турында медицина белешмәсе булган башка затлар озатуында булуы өчен шартлар тудырылган учреждениеләргә җибәрелә;

инвалид балаларның чит кеше ярдәменә һәм (яисә) индивидуаль ярдәмгә мохтаҗ булуы инвалидның тормыш итү эшчәнлеге төп категорияләрен индивидуаль реабилитация программасында күрсәтелгән чикләүләр нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасының законнарына килгәндә, 2016 елда балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган түбәндәге иң мөһим норматив хокукый актлар кабул ителде.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 7 маендагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан

*РеспубликасыЗаконы белән Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертелде. Аерым алганда әлеге үзгәрешләр нигезендә г*аилә законнары гаилә хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау тәртибен, никахлашуның, аны туктатуның һәм дөрес түгел дип тануның шартларын һәм тәртибен билгели, гаилә әгъзалары: ир белән хатын, ата-ана һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынучылар) арасында, ә гаилә законнарында каралган очракларда һәм чикләрдә башка туганнар һәм бүтән затлар арасында мөлкәти булмаган һәм мөлкәти булган шәхси мөнәсәбәтләрне җайга сала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау тәртибен, аларны гаиләгә урнаштыру, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларга вакытлыча урнаштыру рәвешләрен һәм тәртибен билгели. Бу законда шулай ук ата-ана хокуклары суд тарафыннан чикләнгән атасына йә анасына бала белән аралашу, әгәр балага зарарлы йогынты ясалмаса, рөхсәт ителергә мөмкинлеге каралган. Атасының йә анасының бала белән аралашуы опека һәм попечительлек органы ризалыгы белән йә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителмәгән яисә ата-ана хокуклары чикләнмәгән атасы йә анасы, опекун (попечитель), баланы тәрбиягә алган ата-ана яисә бала тора торган оешма администрациясе ризалыгы белән рөхсәт ителә.

«2017 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә һәркемгә мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын раслау турында» 2016 елның 29 сентябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында, аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган гомуми белем бирү оешмаларында, гимназияләрдә, лицейларда, интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларында, аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган интернат-мәктәпләрдә, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен җайлаштырылган белем бирү программалары буенча эшләүче интернат-гимназияләрдә, интернат-лицейларда, гомуми белем бирү оешмаларында, «кадет мәктәбе», «кадет интернат-мәктәбе» махсуслашкан исем алган гомуми белем бирү оешмаларында, озак вакыт дәваланырга мәҗбүр булган балалар өчен шифаханәләрдәге белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары; гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программаларын һәм гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары; көндезге һәм читтән торып уку бүлеге булган гомуми белем бирү оеш-

маларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары һәм һөнәри белем бирү оешмаларында төп һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары расланды.

«2017 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алу хокукларын гамәлгә ашыру дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2016 елның 29 сентябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән мәктәпкәчә гомуми белем бирү оешмаларында, компенсацияләү төрендәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гадәти төркемнәрендә, катнаш төрдәге һәм гомуми үсеш төренә керә торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, балаларның үсеш үзәкләрендә, катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының коррекция төркемнәрендә һәм компенсацияләү төрендәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының коррекция төркемнәрендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга, шулай ук азкомплектлы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары билгеләнде.

2016 елның 3 октябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән *«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында»* Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертелде. Әлеге үзгәрешләр буенча балигъ булмаганнар белем бирү оешмаларына кергән вакытта һәм шунда уку чорында медицина тикшерүе үтүе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләреннән төшереп калдырылды.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 12 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән уку чорында ата-анасының берсен яисә икесен дә югалткан затлар өчен дәүләт гарантияләре кертелде.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагыла торган түбәндәге мөһим норматив хокукый актлары кабул ителде.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2016 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары белән Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органна-

ры карамагындагы белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнашу өчен юллама бирү тәртибе (алга таба – Тәртибе) расланды. Тәртиптә каралганча, ата-аналары, уллыкка-кызлыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) нигезләнгән сәбәпләр (шул исәптән эш урыны, даими керем чыганагы булмау, яшәү өчен яраклы торак урыны булмау, озак дәвалау таләп иткән госпитальләштерү, авыру һ.б.) аркасында балигъ булмаганнарга карата үз вазыйфаларын үти алмаган гаиләләрдән булган балалар (алга таба – балигъ булмаган бала) вакытлыча ятим балалар өчен оешмага урнаштырыла ала. Балигъ булмаган баланы ятим балалар оешмасына вакытлыча урнаштыру вакыты дүрт айдан күбрәк була алмый (балигъ булмаган баланың ата-аналары, уллыкка-кызлыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) озак дәвалануга бәйле стационар дәвалануда булган очраклардан тыш) һәм опека һәм попечительлек органы карары буенча бер мәртәбә, күп дигәндә, ике айга озайтыла ала. Тәртиптә шулай ук ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар һәм законлы вәкилләре булган балалар күзәтчелеккә алына торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагында булган белем бирү оешмаларына, медицина оешмаларына, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмаларына вакытлыча урнашу өчен юллама бирү тәртибе дә раслана.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 30 декабрендәге 1059 номерлы карары белән Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатының стандарты расланды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 31 мартындагы 184 номерлы карары белән «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасына (алга таба – дәүләт программасы) үзгәрешләр кертелде. *Дәүләт программасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының* «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карары белән расланган иде. Кабул ителгән 184 номерлы карар нигезендә әлеге дәүләт программасына «2016 – 2018 елларга Татарстан балалары» ярдәмче программасын кертү күздә тотыла.

«Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карары нигезендә Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру нигезләмәсе, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан

Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга субсидияләр бирү кагыйдәләре, Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә расланды. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру нигезләмәсе буенча яшьләрнең һәм балаларның ялын оештыру рәвешләре, ял кампаниясендә катнашучылар, балаларның һәм яшьләрнең ял сменаларын оештыручылар, финанслау чыганаклары һәм ата-аналар түләвенең күләме билгеләнгән. Әлеге карар нигезендә «Балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 14 апрелендәге 243 номерлы карары һәм әлеге тармакка карый торган кайбер башка карарлар үз көчен югалткан дип танылды.

«2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасына (алга таба – Программа) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 15 апрелендәге 225 номерлы карары белән үзгәрешләр кертелде. Программаны финанслауның гомуми күләме 171 416 922,215 мең сумнан 171 436 444,744 мең сумга кадәр артты. Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр тулыландырылды. Аерым алганда, 10 яшьтән 18 яшькә кадәр булган, инвалид балалар өчен махсуслаштырылган 5 оешмада тәрбияләнүче, тормыш-көнкүреш эшчәнлеге нык бозылган инвалид балаларны көнкүрештә үз-үзләренә хезмәт күрсәтүгә һәм көчләреннән килгән кадәр эшләргә өйрәтү һәм әзерләү буенча 2016 елда – 210 кеше, 2017 елда – 215 кеше; инвалид балалар өчен махсуслаштырылган 5 оешмада тәрбияләнүче, тормыш-көнкүреш эшчәнлеге нык бозылган инвалид балаларны көнкүрештә үз-үзләренә хезмәт күрсәтүгә һәм көчләреннән килгән кадәр эшләргә өйрәтү һәм әзерләү үткән инвалид балаларның шундый балалар өчен махсуслаштырылган 5 оешмада тәрбияләнүче инвалид балаларга карата чагыштырма күләме 2016 елда – 27 % ка , 2017 елда – 28 %ка кадәр җитәргә тиеш, шулай ук инвалид балалар өчен махсуслаштырылган 5 оешмада тәрбияләнгән, мөстәкыйль яшәүче инвалид балаларга 18 яшь тулган ел дәвамында социаль ярдәм күрсәтү 2016 елда – 39 кешене, 2017 елда – 43 кешене тәшкил итәчәк. Шулай ук Дәүләт программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары, шулай ук аны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү яңа редакциядә бәян ителде. Ярдәмче программалар исемлегенә 2016 – 2017 елларга Татарстан Республикасында тормыш-көнкүреш

эшчәнлекләре нык бозылган балаларны комплексы әзерләү һәм социаль адаптацияләү буенча ведомствоара программа кертелде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 7 октябрендәге 724 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 28 февралендәге 127 номерлы карары белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлегенә (алга таба – Исемлек) һәм Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тәртибенә (алга таба – Тәртип) үзгәрешләр кертелде. Аерым алганда, әлеге карар белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлеге һәм Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары республика исемлегенә кертелгән инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тәртибе нигезендә инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары 2016 елның 1 сентябренә кадәр инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү буенча исәпкә куелган инвалидларга бирелә. Тәртипнең элеккеге редакциясендә вакытны чикләү юк иде. Шулай ук Тәртипнең яңа редакциясендә техник чара бирелү турындагы шартнамәне вакытыннан алда туктату шартлары да билгеләнде. Моңа түбәндәгеләр керә: Шартнамә Россия Федерациясе Граждан кодексында, бүтән федераль законнарда яки шартнамәдә каралган нигезләр буенча вакытыннан алда өзелә, шул исәптән: инвалид тәкъдиме белән; Комплексы үзәк боерыгы белән төзелгән комиссия бәяләмәсе раслаган алга таба файдаланып булмау хәленә килгән техник чараны төзәтү яки алыштыру зарурлыгы барлыкка килгән очракта. Әлеге зарурлык Комплексы үзәк боерыгы белән төзелгән комиссия тарафыннан раслана. Алда телгә алынган Исемлектән «нагрузка бирә торган дәвалау костюмы» сүзләре төшереп калдырылды.

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру һәм алардан килгән зыянны киметү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 27 декабрендәге 1011 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына укучы балаларның муниципаль берәмлек, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе чикләреннән чыгуын оештырганда гамәлдәге законнар нормаларын катгый үтәү бурычы йөкләнде. Әлеге карар нигезендә шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына яшьләр оешма-

ларын һәм берләшмәләрен юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча эшкә, шул исәптән пропаганда чаралары һәм махсус акцияләр, семинарлар үткәрүгә җәлеп итү, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә мәгариф оешмаларын балигъ булмаганнарга юлларда үз-үзен имин тоту кагыйдәләре өйрәтүне тикшерү, мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны гомуми белем бирү оешмаларында белем алуга әзерләү кысаларында беренче сыйныф укучыларын яктылыкны кире кайтара торган элементлар белән тәэмин итү йөкләнде; Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә гомуми белем бирү оешмаларында «Безопасность на дорогах ради безопасности жизни» темасына тормыш-көнкүреш иминлеге дәресен оештыру йөкләнде;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына «Татарстан Республикасында «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә пассажирлар, шул исәптән балалар йөртүне гамәлгә ашыра торган автобусларны мониторинглау һәм диспетчерлаштыру бердәм системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 25 маендагы 352 карарына мәктәп автобуслары белән элемтә булмаган очракта гамәлләр алгоритмын билгеләү, региональ дәрәҗәдәге массакүләм чаралар үткәрү урыннарына балалар төркемнәрен оешкан төстә алып барганда иминлекне тәэмин итү буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү һәм гамәлләрне координацияләү буенча үзгәрешләр кертү йөкләнде.

Социаль ярдәм чаралары бирү мәсьәләләренә кагыла торган норматив хокукый актлар арасында түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк.

«2017 елга айлык түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 21 сентябрендәге 664 номерлы карары белән 2017 елның 1 гыйнварыннан айлык түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү коэффициенты 1,049 күләмендә, шулай ук айлык түләүләрнең һәм түләүләрнең башка төрләренең күләме билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 октябрендәге 747 номерлы карары белән 2017 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирә торган дәүләт мәгариф оешмаларында төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яки атасын йә анасын югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре

буенча түләүләр күләмнәре расланды. 2017 елда белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие 694 сум булачак; белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие – 59 337 сум; уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие – 2 482 сумнан 6 424 сумга кадәр; өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие – 25 289 сум; 2017 елның 1 сентябреннән белем алучылар өчен билгеләнгән стипендия күләменнән артык айлык стипендия – 856 сум; тукланыга айлык пособие – 6 094 сумнан 7 023 сумга кадәр билгеләнде.

Балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган аерым мәсьәләләрне җайга салучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының берсе буларак, «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карарын билгеләп үтәргә кирәк. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законының хроник авыруларның авыр төрләреннән интеккән инвалидларга һәм хроник авыруларның авыр төрләреннән интеккән инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү күздә тотыла торган 8.2 статьясын тормышка ашыру максатларында, әлеге карар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибе расланды.

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 19 августындагы 576 номерлы карары нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исемлегенә социаль ипотека системасы буенча исәпкә куелган гаиләләр 200 мең сумлык дәүләт ярдәменә (торак урын бәясен түләүгә җибәрелә торган) хокукларын гамәлгә ашырганда баланың алына торган торак урынга гомуми өлешле милек хокукы барлыкка килә.


2.4. 2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә ясалган анализга нигезләнеп, Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләргә мониторинг

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендә проблемалы мәсьәләләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына 2016 елда кергән граждан мөрәҗәгатьләренең гомуми санныннан (1 767 мәсьәлә буенча 1 729 мөрәҗәгать), мөрәҗәгатьләр тематикасы буенча баланың тормышка, гаиләгә һәм белемгә хокуклары бозылуга шикаять белдергән мөрәҗәгатьләр алдынгы урыннарны алып тора.

28 диаграмма

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы



Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге тематикалар берничә ел рәттән иң проблемалы булып кала бирә.

29 диаграмма

2011 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы



2016 елда шикаятьләрнең саны барлык темалар буенча да артты.

2 нче таблица

2015 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең динамикасы

Мөрәҗәгатьләр тематикасы	2015 ел	2016 ел	Үзгәрешләр динамикасы	
			гомуми	чагыш., %
Барлыгы	1664	1767	103	+6,2%
Торакка хокук	374	431	57	+15,2
Гаиләгә һәм гаилә мөнәсәбәтләренә хокук	452	423	-29	-6,4
Белем алуга хокук	288	370	82	+28,5%
Социаль тәэминатка хокук	85	171	86	+101,2%
Лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук	150	157	7	+4,7%
Яшәүгә хокук һәм сәламәтлек саклау хезмәтләренә хокук	85	114	29	+34,1%
Көч кулланудан яклануга хокук	137	76	-61	-44,5%
Гражданлыкка хокук	31	25	-6	-19,4%
Фикер, әхлак һәм дин иреген хокук	7	0	-7	-100,0%

2016 елда балаларның торакка хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре мөрәҗәгатьләр арасында беренче урынны алып торды. Әлеге тематика буенча шикаятьләрнең тотрыклы рәвештә арта баруы бу өлкәдә балаларның хокукларын яклауның катлаулы һәм актуаль булуын раслый. Бу тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 431 мөрәҗәгать керде, бу гомуми мөрәҗәгатьләрнең 24,4 %ын тәшкил итте (2015 елда – 22,5%). Бу – әлеге тематика буенча 2011 елдан бирле иң зур сан.

30 диаграмма

2016 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы



2015 – 2016 елларда балигъ булмаганнарның торак хокукларын яклау мәсьәләсе буенча кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре структурасына чагыштырма анализ ясап карасак, соңгы елларда бер үк төрле мәсьәләләрнең актуаль булып калуы күренә.

3 нче таблица

2015 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә торак мәсьәләсе буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең динамика

Мөрәҗәгатьнең тематикасы	2015 ел	2016 ел	Үзгәрешләр динамикасы	
			гомуми, бер.	чагыш., %
Барлыгы	374	431	57	+15,2%
Мәсьәләне суд хәл итәчәк	98	122	24	+24,5%
Гаиләнең торак шартларын яхшырту тәртибе	83	97	14	+17%
Ата-анасы аерылышуга бәйле рәвештә баланы теркәүдән төшерү, торактан чыгару	44	43	-1	-2,3%
Кредит йөкләмәләре буенча бурычларга бәйле рәвештә баланы торактан чыгару, теркәүдән төшерү	21	42	21	+100,0%
Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү	34	41	7	+20,6%
Күпбалалы гаиләләрне һәм инвалиды булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү	48	37	-11	-22,9%
Балалы гаиләләрне авария хәлендәге торактан чыгару	18	13	-5	-27,8%
Әлеге тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр	28	36	8	28,6%

Гражданнар үз мөрәҗәгатьләрендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелганда, торак исәбеннән төшергәндә, социаль найм буенча торак бирелгәндә, җимерек һәм авария хәлендәге торактан күчергәндә, күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин иткәндә, инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин иткәндә хокуклары бозылу һәм торак алу өчен чиратта озак торулары турында хәбәр итәләр.

28 % мөрәҗәгатьләрдә гражданнар үзләренең торак проблемаларын суд тәртибендә карау буенча консультацияләр үткәрүне һәм аңлатмалар бирүне үтенеп мөрәҗәгать итә, яисә аларның торак проблемасын хәл итү республиканың суд органнарына тапшырылган. Әлеге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр (122), 2015 ел белән чагыштырганда, 24,5 %ка артты.

Балалы гаиләләрнең яшәү шартларын яхшырту турында консультацияләр һәм аңлатмалар бирүне сорап язылган мөрәҗәгатьләрнең саны 17 %ка артты.

Балигъ булмаганнарның хокукларына кагыла торган мөрәҗәгатьләрнең һәр унынчысы (43) балаларны били торган торак урыннан чыгаруга, ата-ананың аерылышуы нәтиҗәсендә балигъ булмаганнарны теркәүдән төшерүгә яисә торак милекчесенең алмашуына бәйле килеп чыккан. Тагын 10 % мөрәҗәгатьләрдә сүз коммерциячел ипотека төзелеше программасы буенча алынган торактан, кредитны үз вакытында түләү мөмкинлеге булмаганлыктан, чыгарылу мәсьәләләренә бәйле.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының күпбалалы гаиләләрне һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча гамәл кылуына (кылмавына) кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең саны, 2015 ел белән чагыштырганда, 22,9 %ка кимеде.

Шул ук вакытта, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исемлегендә торучы ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокуклары бозылуга бәйле мөрәҗәгатьләр саны 21%ка артты.

2016 ел дәвамында гражданнарның авария хәлендәге торактан чыгарылу тәртибе актуальлеген саклап калды.

Балаларның гаиләгә һәм гаилә мөнәсәбәтләренә хокукларын яклау мәсьәләләре шулай ук кергән мөрәҗәгатьләр арасында алдынгы урыннарда тора. Аларның саны, 2015 ел белән чагыштырганда, бераз гына ким булуга карамастан, бу тема әһәмиятле булып кала бирә.

4 нче таблица

2015 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гаилә мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы

Мөрәҗәгатьләрнең тематикасы	2015 ел	2016 ел	Үзгәрешләр динамикасы	
			гомуми, бер.	чагыш., %
Барлыгы	452	423	-29	-6,4%
Ата-ананың аерым яшәве (аерылышуы), кайсының да булса вафат булуы очрагында балалар тәрбияләү	291	174	-117	-40,2%
Ятим балаларны башка гаиләгә тапшыру	24	75	51	+212,5%
Гаиләнең начар яшәве турында хәбәр алыну	85	73	-12	-14,1%

Балаларны законсыз рәвештә алып китү һәм җибәрмәү	22	39	7	+77,3%
Ата-ана хокукларын кире кайтару	3	20	17	+566,7%
Ата-ана хокукыннан мәхрүм итү мәсьәләсен башлап җибәрү	11	15	4	+36,4%
Әлеге тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр	16	27	11	+68,8%

Гаиләдә тәрбия мәсьәләләренә, ата-ана бурычларын билгеләү, ата-ана хокукларының чикләрен билгеләү, балигъ булмаганнарның һәм башка туганнарының гаилә мөнәсәбәтләренә хокуклары, авыр хәлдәге гаиләдә тәрбияләнүче балалар һәм ятим балалар хокукларын гамәлгә ашыру темаларына 423 мөрәҗәгать алынды, бу гомуми санның 24 %ын тәшкил итте.

31диаграмма

2016 елда гаилә мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы



2015 елдагы кебек үк, әлеге категория мөрәҗәгатьләренең төп өлешен ата-анасы аерылышканнан соң баланың яшәү урынын ачыклауга бәйле бәхәсле вәзгыять китереп чыгарган, баланың аерым яшәүче атасы яисә анасы белән, башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү, бала белән аралашуга киртәләрне юкка чыгару турындагы мөрәҗәгатьләр алып тора. Гаилә эчендәге мондый бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүдә булышуны сорап 2016 елда 174 кеше мөрәҗәгать итте (бу – әлеге тематика буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең 41,1 %ы). 2015 елда мондый мөрәҗәгатьләр 291 булган иде. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре, нигездә, башка гражданнарның – бала гаиләсенең (элеккеге гаиләсенең) башка әгъзалары гамәлләренә багышланган иде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә баланың яшәү урынын билгеләү өлешендә гаиләдә килеп туган низагны хәл итүдә консультация бирүне сорап язган мөрәҗәгатьләр саны (17 очрак – тематика буенча булган мөрәҗәгатьләрнең 4 %ы) ике тапкыр артты. Төркия, Франция, Австрия, Германия, Греция, Испания, Малайзия гражданнары белән закон-

лы никахта торучы гражданнардан яисә аларның якын туганнарыннан баланы Россия Федерациясенә кире кайтару процедурасына кагылышлы сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләр артты.

Гаиләләрдәге социаль хәлнең начар булуы, гражданнарның ата-ана бурычларын намус белән башкармаулары, шул исәптән балаларга карата рәхимсезлек кылулары турында хәбәр ителгән мөрәҗәгатьләрнең саны хисап чорында 14,1 %ка кимеде. 2016 елда барлыгы шундый 73 мөрәҗәгать керде, тикшерү чаралары уздырганнан соң шуларның 15 %ы (11 мөрәҗәгать) расланмады. Моннан тыш, 2016 елда чит гражданнарның, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнарның фикеренчә, законсыз рәвештә балаларын бирмәүләренә яки балаларын гаиләдән тартып алуларына шикаять белдерелгән 39 (әлеге тематика буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең 9,2 %ы) мөрәҗәгать керде.

Шул ук вакытта түбәндәге фактлар игътибар итүне таләп итә:

ата-ана хокукын кире кайтаруны сорап мөрәҗәгать итүче гражданнар җиде тапкыр артты (2016 елда - 20 мөрәҗәгать, 2015 елда – 3);

балаларны опекага, уллыкка (кызлыкка) алу мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең саны өч тапкырга артты (2016 елда - 75 мөрәҗәгать, 2015 елда – 24);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү мәсьәләсен башлап җибәрүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны өчтән бергә артты (36,4 %)(2016 елда – 15, 2015 елда – 11).

Баланың белем алуга хокукы бозылуга кагылышлы мөрәҗәгатьләр хисап чорында да гомуми саннары буенча өченче урында тора. 2016 елда шундый 370 мөрәҗәгать каралды, бу гомуми санның 21 %ын тәшкил итә. Шул ук вакытта, 2015 ел белән чагыштырганда, арту 28,5 %ны тәшкил итте. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең саны елдан-ел арта бара. Мәсәлән, 2011 ел белән чагыштырганда, мөрәҗәгатьләр саны алты тапкыр, 2016 ел белән чагыштырганда, ике тапкыр артты.

5 нче таблица

2015 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә белем алуга хокук мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы

Мөрәҗәгатьнең тематикасы	2015 ел	2016 ел	Үзгәрешләр динамикасы	
			Гомуми, берәмлек	чагышт., %
Барлыгы	288	370	82	+28,5%
Уку-укыту процессында катнашучылар арасында конфликтлар	83	99	16	+19,3%

Белем бирү оешмаларында укыту-тәрбияләү процессын оештыру, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты	48	90	42	+87,5%
Мәктәпкәчә мәгариф оешмала-рында урыннар бирү	48	63	15	+31,3%
Укучыны гомуми белем бирү оешмаларына кабул итү яисә башкасына күчерү	30	52	22	+73,3%
Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү	24	30	6	+25,0%
Укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә транспорт хезмәте күрсәтү	13	14	1	+7,7%
Белем бирү оешмаларында ту-клануны оештыру	17	12	-5	-29,4%
Белем бирү оешмаларын бетерү, үзгәртеп кору	25	10	-15	-60,0%

Әлеге тематика буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең 90 %ка якыны 5 нче таблицада күрсәтелгән беренче биш мәсьәләгә кагылышлы булды.

32 диаграмма

2016 елда белем алуга хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы



Шуны әйтеп үтәргә кирәк, балаларның белем алуга хокукларына кагылышлы мөрәҗәгатьләр арасында икенче ел рәттән беренче урында белем бирү процессында катнашучылар арасында туган каршылыклы очракларга караган мөрәҗәгатьләр тора. Аларның 27 %ы (99 шикаять)

белем бирү процессында катнашучылар арасында килеп туган низагларны хәл иткәндә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең, шул исәптән педагогларның һәм администрациянең гамәлләренә (гамәл кылмауларына), укучыларны мәгариф оешмаларына кабул итү яисә күчерү мәсьәләләренә багышланган иде.

2016 елда белем бирү оешмаларында укыту-тәрбияләү процессын оештыру, белем бирү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты мәсьәләләре буенча гражданнар шикаятьләренә бәйле мөрәҗәгатьләр, 2015 ел белән чагыштырганда, артты (2016 елда – 90 мөрәҗәгать, 2015 елда – 48).

Балаларны мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына алу мәсьәләсе буенча килгән мөрәҗәгатьләр, шулай ук, алдынгы урыннарның берсен алып тора. Бу тематикага баланы бер балалар бакчасыннан икенчесенә күчергәндә килеп туган каршылыкларга багышланган мөрәҗәгатьләр дә керә, 2016 елда шундый 63 шикаять алынды, бу аларның гомуми санының 17 %ын тәшкил итә. Әлеге вәзгыять, республика тарафыннан әлеге мәсьәләне хәл итү буенча күрелә торган җитди чараларга карамастан, балалар бакчаларына чират булу проблемасының сакланып калуын раслый.

Балаларны гомуми белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яисә укучыларны башка гомуми белем бирү оешмаларына күчергәндә баланың белем алуга хокукын тәэмин итү 2016 елда да актуаль булды. Әлеге мәсьәләләр буенча шикаятьләр 52 мөрәҗәгатьтән, яисә белем алуга хокукларның тәэмин ителешенә кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең 14 %ыннан гыйбарәт булды. Балаларны белем бирү оешмаларына кабул итүгә багышланган мөрәҗәгатьләр саны, 2015 ел белән чагыштырганда, 73,3%ка артты. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең 9 сыйныфны тәмамлаган укучыларны 10 сыйныфка алудан баш тартуына бәйле мөрәҗәгатьләрнең артуы аеруча игътибарны җәлеп итә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына шундый 14 мөрәҗәгать керде һәм 11 очракта мәсьәлә уңай хәл ителде, балалар гомуми белем бирү оешмасының 10 сыйныфына кабул ителделәр. Калган өч факт буенча балигъ булмаганнарны башка мәктәпләрнең 10 сыйныфларына урнаштыруга ярдәм ителде.

30 мөрәҗәгатьтә гражданнар сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укытуны тиешенчә оештырмауга шикаять белдерделәр, мондый шикаятьләр саны, алдагы ел белән чагыштырганда, 25 %ка артты.

Белем бирү мәсьәләләренә кагылышлы мөрәҗәгатьләр арасында 2016 елда балаларны уку урынына кадәр алып килү (14 мөрәҗәгать), белем бирү оешмаларында балаларны тукландыру (12 мөрәҗәгать) һәм белем бирү оешмаларын бетерү яисә үзгәртеп кору белән килешмәү буенча шикаятьләр керү дәвам итте.

Балаларның белем алуга хокукларын яклау мәсьәләләре буенча кергән 64 (18 %) шикаять буенча мәсьәлә уңай хәл ителде, 31 очракта (8,5 %) төрле чаралар күрелде – белем бирү оешмасын гамәлгә куючы адресына балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында бәяләмә җибәрелде, 27 мөрәҗәгать (7,5 %) тикшерү чаралары вакытында расланмады, калган мөрәҗәгатьләр буенча (66 %) гамәлдәге законнар нормаларын аңлату буенча киңәшләр бирелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына кергән граждан мөрәҗәгатьләрен мониторинглау анализыннан чыгып караганда, 2016 елда балаларның хокукларын яклау өлкәсендә иң кискен торган мәсьәләләрнең берсе булып ***социаль тәэминатка хокукны*** гамәлгә ашыру проблемалары тора. Узган ел йомгаклары буенча әлеге тематикага караган 171 мөрәҗәгать каралды, бу ел буенча алынган мөрәҗәгатьләрнең 10 %ын тәшкил итә. Бу күрсәткеч 2015 елдагы шундый үк саннарга караганда ике тапкыр зуррак.

Мөрәҗәгатьләрнең күбесе (104 мөрәҗәгать, яисә әлеге тематика буенча алынган мөрәҗәгатьләрнең 63 %ы) төрле социаль түләүләр алу тәртибе мәсьәләләренә багышланган иде.

Күпбалалы гаиләләргә һәм тәрбиягә бала алган гаиләләргә ташламалы юлламалар алу мәсьәләләренә 23 мөрәҗәгать (әлеге юнәлеш буенча кергән сорауларның гомуми санының 13,5 %ы), балаларга инвалидлык бирү мәсьәләләренә багышланган 17 мөрәҗәгать (әлеге юнәлеш буенча кергән сорауларның гомуми санының 10% ы) багышланды.

Балаларның азмобильле төркемнәре өчен уңайлы социаль инфраструктура булдыру проблемалары 3 мөрәҗәгатьтә чагылыш тапты.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең заманча техник чаралары белән тәэмин итү мәсьәләсе аеруча кискен булып кала бирә. 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына инвалид балалар өчен уңайлы социаль инфраструктура булдыру, шифаханә-курорт шартларында дәвалану һәм тернәкләндерү белән зарури һәм җитәрлек күләмдә тәэмин итүгә шикаятьләр бирелде.

Балаларның ***лаеклы тормыш дәрәҗәсенә*** хокукларын тәэмин итү проблемасы традиция буенча бишенче урында тора. Элеккечә үк шикаятьләрнең төп субъектлары – үз балаларына яшәү һәм тәрбия өчен кирәкле матди шартлар тудыру буенча ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәгән ата-аналар, икенче төрле әйткәндә, бу мөрәҗәгатьләр алимент йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәүгә багышланган. 2016 елда шундый сорау белән 157 граждан мөрәҗәгать итте, бу – ел буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 9 %ы. Мондый сораулар белән ел саен мөрәҗәгать итүче гражданнарның саны соңгы елларда стабиль булып

кала. Бу ата-аналарның алимент йөкләмәләрен үтәмәү проблемасының актуальлеге саклануын күрсәтә.

Балаларның сәламәтлек саклауга хокукларын яклау мәсьәләләре буенча язылган мөрәҗәгатьләрнең саны елдан-ел арта бару динамикасы тотрыклы рәвештә сакланып кала. Әлеге мәсьәләләр, 2016 ел йомгаклары буенча, алтынчы урында тора һәм 114 мөрәҗәгатьне, яисә мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 6,5 % ын тәшкил итә. Бу, 2015 елга караганда, 29 мөрәҗәгатькә артыграк. Медицина юнәлешендәге мөрәҗәгатьләр, нигездә, ташламалы дарулар белән тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру, аңардан файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфаты мәсьәләләренә багышланды.

Баланы барлык төр көч кулланулардан һәм рәхимсезлекләрдән яклауны сораган гражданнар мөрәҗәгатьләре саны буенча бишенче урыннан җиденче урынга күчте. 2016 елда әлеге мәсьәлә буенча 76, бу узган елга караганда ике тапкыр кимрәк, мөрәҗәгать керде (2015 елда – 137 мөрәҗәгать), алар мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 4,4 % тәшкил итте. Мөрәҗәгатьләрнең күбесендә баланы көчләү һәм аңа карата рәхимсезлек кылу гамәлләренең гаиләдә булу (гаиләдәге көчләүләр) фактлары турында хәбәр ителү аерым борчу уята. Моның белән бергә, тикшерү органнарына карата да шикаятьләр белдерелә, аларда, аерым алганда, җинаять эшләрен кузгатудан, гариза бирүче фикеренчә, нигезсез баш тартулар һәм процессуаль карарлар кабул итү яки процессуаль гамәлләр башкару сроклары бозылу турында сүз алып барыла.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең тематикалары буенча иң соңгы урында паспорт алганда, теркәү исәбенә басканда, ***гражданлыкны билгеләгәндә*** балигъ булмаганнарның гражданлык хокуклары бозылу турындагы мөрәҗәгатьләр тора. Хисап чоры дәвамында әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм сорап 25 кеше мөрәҗәгать итте. Күп очракта проблемалар ата-аналарның билгеләнгән гражданлык статусы булмау аркасында яки балаларны ата-ана каравыннан алу очракларына бәйле барлыкка килгән.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән **гражданнар категорияләре буенча** алганда, 2016 елда балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан 1 148 (66,4%) мөрәҗәгать (2015 елда – 1 093 мөрәҗәгать, 65,7%) керде.

Балаларның туганнарыннан 231 мөрәҗәгать (13,4 %) (2015 елда – 190 мөрәҗәгать, 11,5 %) алынды. Мөрәҗәгатьләрдә, нигездә, ата-аналарның үз вазыйфаларын намуссыз башкаруларына, балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм аларның хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының гамәл кылмауларына, туганнары белән аралашуда бала хокуклары бозылуга зарланганнар.

Опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-аналар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә 93 мөрәҗәгать юллаганнар, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 5,4 % (2015 елда – 63 мөрәҗәгать, 3,8 %) тәшкил итә. Аларда күтәрелгән төп темалар опека һәм попечительлек, аларның тәрбиясендәге балаларның торак хокуклары үтәлү-үтәлмәү өлкәсенә карый.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2016 елда балалар омбудсменына балигъ булмаганнарның үзләреннән 46 (2,7 %) мөрәҗәгать алынды, бу – 2015 ел дәрәҗәсендә.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән 20 мөрәҗәгать керде, шуларның 30 %ы хезмәттәшлек, үзара эшчәнлек һәм балаларга ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча.

6 нчы таблица

2016 – 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнар категорияләре

Граждан категорияләре	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	
	Саны, кеше	Саны, кеше	Саны, кеше	Саны, кеше	%
Ата-аналар	801	847	1093	1148	66,4
Башка туганнар	150	139	190	231	13,4
Опекуннар һәм попечительләр	56	49	63	93	5,4
Балигъ булмаганнар	49	14	49	46	2,7
Ятим балалар һәм ата-ана карамыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар	38	24	31	24	1,4
Иҗтимагый оешмалар вәкилләре	45	20	54	20	1,2
Балалар учреждениеләре җитәкчеләре, хезмәткәрләре	14	14	12	27	1,6
Башка затлар (чит гражданнар, күршеләр һ.б)	102	124	172	140	8,1

Мөрәҗәгатьләрнең географиясе буенча караганда, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гариза бирүчеләрнең иң зур өлешен, узган еллардагы кебек үк, Татарстан Республикасында яшәүчеләр алып тора. Алар тарафыннан 1 701 мөрәҗәгать, яисә барлык мөрәҗәгатьләрнең 98,4 %ы) җибәрелгән.


Республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча карасак, элеккечә, мөрәҗәгатьләрнең иң күп саны – 895 мөрәҗәгать – Казан шәһәре халкыннан алынды (мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 52 % яки һәр икенче мөрәҗәгать). Гариза бирүчеләрнең гомуми санының чыгып караганда, казанлылардан кергән гаризалар, 2015 ел белән чагыш-

тырсак, 10 % ка артты (2015 елда – 808 мөрәҗәгать). Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрдән 134 мөрәҗәгать алынды, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынан 7,8 % тәшкил итә һәм, 2015 ел белән чагыштырганда, 12,6 %ка артык.

Республиканың муниципаль районнары арасында мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урыннарда Түбән Кама (76 мөрәҗәгать, 2015 елга караганда 29% % ка артык), Зеленодольск (64 мөрәҗәгать, узган ел белән чагыштырганда ике тапкыр кимрәк), Әлмәт (50 мөрәҗәгать, 2015 елга караганда 24 %ка кимрәк), Алабуга (33 мөрәҗәгать, узган елга караганда ике тапкыр күбрәк) муниципаль районнары тора. Республиканың башка муниципаль районнарыннан кергән мөрәҗәгатьләр саны диаграммада күрсәтелде.

33 диаграмма

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең республика муниципаль районнары буенча саны




Шулай ук ел дәвамында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә турыдан-туры яисә башка регионнардагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аркылы Россиянең башка төбәкләрендә: Алтай, Пермь, Забайкалье крайларында, Архангельск, Саратов, Свердловск, Ульяновск, Пенза, Мәскәү, Омск өлкәләрендә, Башкортостан Республикасында, Удмурт Республикасында, Чувашия Республикасында, Мәскәү шәһәрендә яшәүчеләрдән 28 (барлык мөрәҗәгатьләрнең 1,6 %ы) мөрәҗәгать керде. Моннан тыш, узган ел Украина һәм Молдова Республикасы, Үзбәкстан гражданнарының мөрәҗәгатьләрен дә карарга туры килде.

Мөрәҗәгатьләрнең төрләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынан 725е – шикаять, калган 1 004е – башка төр мөрәҗәгатьләр (мәгълүмат, аңлатма, консультацияләр бирү, ярдәм күрсәтү турында үтенечнамәләр). 2016 елда мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынан шикаятьләргә туры килгән өлеш, 2015 ел белән чагыштырганда, шул ук дәрәҗәдә калды һәм 42 % (2015 елда – 43 %) тәшкил итте.

34 диаграмма


2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрне төрләре буенча бүлү



2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр арасында консультацияләр бирү, гамәлдәге законнарның нормаларын аңлату һәм проблеманы яки каршылыклы очракны хәл итүдә ярдәм күрсәтү соралган гражданнар мөрәҗәгатьләре санының арта баруы күзәтелә.

35 диаграмма


2011 – 2016 елларда шикаятьләрнең һәм консультация, аңлатма бирү соралган мөрәҗәгатьләрнең чагыштырмасы



Шикаятьләрнең гомуми санын **шикаять бирү субъектлары буенча** түбәндәгечә бүлеп карарга була.

36 диаграмма

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләрне шикаять бирү субъектлары буенча бүлү



2016 елда шикаять бирелү субъектларына барлык дәрәҗәдәге гавами хакимият органнары (федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары), суд органнары, төрле оешмаларның җитәкчеләре һәм гражданнар керде.

Иң күпсанлы шикаятьләр (196 шикаять, яки 27 %), 2013 – 2016 елларда кебек үк, җирле үзидарә органнарының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булды.

Икенче урынны гражданнарның гамәлләренә карата язылган шикаятьләр били (162 шикаять, яки 22,3 %)

Шикаять бирелү субъектлары арасында өченче урында төрле оешмаларның җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары тора (158 шикаять, яисә 21,8 %).


Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаять белән гражданнар 110 (яки 15,2 %) очракта мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары гамәлләренә һәм карарларына 59 (яки 8 %) шикаятьтә ризасызлык белдерелде.

Суд органнары карарлары 42 (яки 5,4%) гражданны канәгатьләндермәгән.

37 диаграмма

2011– 2016 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән шикаятьләрнең шикаять бирелү субъектлары буенча саны



Чагыштырма анализдан күренгәнчә, гомуми исәпнең 50 % шикаятендә гражданнар гавами хакимиятнең төрле органнары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) зарланганнар. Шул ук вакытта мөрәҗәгатьләрнең гомуми санында аларның өлеше 381 дән 365 кә кадәр кимегән. Шикаятьләрнең иң зур өлеше, узган еллардагы кебек үк, җирле үзидарә органнарының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) туры килә. Шулай да мондый шикаятьләрнең саны (196) 2015 ел дәрәҗәсендә калды (2015 елда – 200). Гражданнардан федераль дәүләт хакимияте органнарына кагылышлы алынган шикаятьләр саны 4 % ка артты (2015 елда – 106, 2015 елда –

110). Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына карата гражданнардан кергән шикаятьләр саны 20 % ка кимеде (2015 елда – 75 шикаять, 2016 елда – 59 шикаять). Мондый шикаятьләрнең күп өлеше федераль һәм региональ законнарда гарантияләнгән, шул исәптән күпбалалы гаиләләрнең, инвалид баласы булган гаиләләрнең, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак хокукларын гамәлгә ашыру, шулай ук инвалид балаларны тернәкләндерүнең кирәкле техник чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләренә кагылды.

Моннан тыш, төрле оешмаларның җитәкчеләренә һәм вазыйфаи затларына карата шикаятьләрнең саны да шул ук дәрәҗәдә калды (2015 елда – 160, 2016 елда – 158).

Шулай ук 2016 елда шикаять бирелү субъектлары арасында башка гражданнар ешрак очрады (18 % ка күбрәк).

Суд органнарының карарларына шикаятьләр саны 2015 ел дәрәҗәсендә калды.

Бала хокукларының алар гарантияләнгәндә генә түгел, ә гамәлгә ашырылганда һәм якланганда чын кыйммәткә әверелүен аңлап, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә баланың бозылган хокукларын торгызу, Татарстан Республикасы территориясендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре яклануны тәэмин итү бурычларын үтәү аерым урын били.

Гомумән алганда, 2016 елда гражданнар шикаятьләрен карау йомгаклары буенча 58 % очракта (2011 елда – 81 %, 2012 елда – 69 %, 2013 елда – 28 %, 2014 елда – 66 %, 2015 елда – 68 %) бала хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында квалификацияле консультацияләр һәм аңлатмалар бирелде.

35 % (2011 елда – 8 %, 2012 елда – 15 %, 2013 елда – 28 %, 2014 елда – 34 %, 2015 елда – 35 %) очракта баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда ярдәм күрсәтелде, шул исәптән 77 % очракта мәсьәләнең асылы уңай хәл ителде.

2016 ЕЛДА ТОРМЫШ КӨНКҮРЕШЕНЕҢ ТӨП ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫНЫҢ САКЛАНУЫ

БҮЛЕК 3

3.1. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү

Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенең 6 статьясында һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 20 статьясында һәр баланың яшәүгә хокукы аерылгысыз хокук буларак таныла. Һәр баланың яшәүгә хокукны тәэмин итә алу – дәүләтнең ни дәрәҗәдә демократик булуын күрсәтүче мөһим күрсәткечләрнең берсе. Бала хокуклары турында Конвенцияне ратификацияләп, Россия Федерациясе «ата-аналарның, законлы опекуннарның яисә бала турында кайгыртучы теләсә кайсы башка затның барлык төрдәге физик һәм психологик изүеннән, кимсетүеннән яисә усал ниятләрдә файдалануыннан, кайгыртмаудан яисә илтифатсызлык кылудан, тупаслыктан яисә эксплуатацияләүдән, шул исәптән сексуаль явыз ниятләрдә файдаланудан, баланы яклау буенча законнарда каралган, административ, социаль һәм агарту чараларын» үтәү йөкләмәләре алды.»

3.1.1. Балаларның тышкы сәбәпләр (бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр) аркасында үлүе


Балалар үлеме структурасы анализында балаларның тышкы сәбәпләр аркасында вафат булу очраклары аеруча игътибар талҗп итә. Балаларның гомерен куркыныч астына куя торган шартлар булып, кызганычка каршы, бәхетсезлек очраклары, суицидлар, җинаятьләр кала бирә.

Ләкин балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләрен кисәтеп тә яки алар белән идарә итеп тә була торган категориягә керә һәм тиешле дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, «балачак өлкәсендә» эшләүче төрле оешмалар мондый фаҗигаләрне кисәтү буенча профилактика эшен, массакүләм мәгълүмат чаралары, ата-аналар белән тыгыз элемтәдә торып, оешкан рәвештә тиешле дәрәҗәдә башкарсалар, бу югалтуларны юк дәрәҗәсенә киметергә мөмкин булыр иде.

2016 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, тышкы сәбәпләр аркасында балалар һәлак булуның 84 очрагы теркәлгән, бу вафат булган балаларның гомуми саныннан 17,6% тәшкил итә (473). 2016 елда суицидлар, бәхетсезлек очраклары һәм җинаятьләр аркасында балалар үлеме саны кимүгә таба баруын дәвам итте.

38 нче диаграмма


2013-2016 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булган балаларның гомуми саны



Балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләренә ясалган структур анализ, тулаем алганда, һәр нигез буенча балалар үлеменең кимүен күрсәтә.


39 нчы диаграмма

2013–2016 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булган балалар саны



40 нчы диаграмма

2013–2016 елларда тышкы сәбәпләр аркасында һәлак булу структурасы



Ел саен су коену чорында сулыкларда фаҗигаләр булып тора, 2016 елның эссе җәе дә искәрмә булмады. Татарстан Республикасы Граждан-нар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – ТР ГХМ) мәгълүматларына караганда, су объектларындагы бәхетсезлек очракларында 7 бала һәлак булган.


Бәхетсезлек очракларын анализлаудан күренгәнчә, фаҗигаләр җәйге лагерьларда булмаган балалар арасында теркәлгән. 2016 елда сулыкларда балалар белән булган бәхетсезлекләрнең сәбәбе ике очракта балаларны ата-ана күзәтүеннән башка калдыруда һәм биш очракта су объектларын-да куркынычсызлык кагыйдәләрен бозуда күренә.

Шуның белән бергә су объектларында 2016 елда балалар су коенган-да гына һәлак булмадылар. Апрельдә кечкенә малай елга аша салынган бүрәнәгә басып чыкканда батып үлә. Абыйлары чыгып өлгерә, ә кекенә энекәшләре суга егылып төшә. Ул бала балалар бакчасына да йөрми тор-ган була, әбисе белән өйдә тора.

2015 ел белән чагыштырганда су объектларында һәлак булучылар саны һзган ел дәрәҗәсендә кала.

41нче диаграмма


2013–2016 елларда балаларның сулыкларда һәлак булуы



2016 елда сулыкларда батып үлгән балалар арасыннан 2 бала 6 яшькә кадәр булды, ә 7 яшьтән алып 13 яшькә кадәр булган 4 бала һәм 14 яшьтән алып 17 яшькә кадәр булган балигъ булмаган 1 бала туры килде.

42 нче диаграмма

2013–2016елларда су объектларында һәлак булган балалар саны (яшь буенча)



2013 һәм 2016 елларда балаларның суга бату очраклары географиясе таблицада бирелде.

7нче таблица

2013 – 2016 елларда су объектларында һәлак булган балалар саны (муниципаль берәмлекләр буенча)


Муниципаль берәмлек исеме	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***
Югары Ослан муниципаль районы	-	-	*1*	***1***
Арча муниципаль районы	-	-	-	***2***
Баулы муниципаль районы	-	-	-	***1***
Мамадыш муниципаль районы	-	-	-	***1***
Питрәч муниципаль районы	*1*	-	-	***1***
Түбән Кама муниципаль районы	-	-	-	***1***
Әлмәт муниципаль районы	*1*	*1*	*1*	-
Чаллы шәһәре	-	*1*	*1*	-
Алабуга муниципаль районы	*1*	-	*1*	-
Зәй муниципаль районы	-	-	*1*	-
Теләче муниципаль районы	-	-	*1*	-
Чирмешән муниципаль районы	-	-	*1*	-
Казан шәһәре	*2*	*1*	-	-
Әлки муниципаль районы	-	*1*	-	-
Минзәлә муниципаль районы	-	*2*	-	-
Мөслим муниципаль районы	-	*1*	-	-
Спас муниципаль районы	-	*1*	-	-
Тукай муниципаль районы	-	*1*	-	-
Чистай муниципаль районы	-	*1*	-	-
Зеленодольск муниципаль районы	*1*	-	-	-
Югары Ослан муниципаль районы	*1*	-	-	-
Кама Тамагы муниципаль районы	*1*	-	-	-
Нурлат муниципаль районы	*1*	-	-	-
Балык бистәсе муниципаль районы	*1*	-	-	-
Тәтеш муниципаль районы	*1*	-	-	-
БАРЛЫГЫ	***11***	***10***	*7*	*7*

Сулыклардагы бәхетсезлек очраклары буенча 2016 елда Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә суда балалар фаҗигасенә китергән сәбәпләрне ачыклау һәм андый очракларны кисәтү өчен бер материал да җибәрелмәгән. Шундый ук хәлне Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2015 елда да күзәтелгән иде. Йогынты ясауның һәм бәхетсезлек очракларының сәбәпләрен белүнең әлеге механизмыннан файдалану мондый фаҗигаләрне кисәтү буенча кирәкле профилактик чара буларак каралырга тиеш.

Татарстан Республикасы ГГМ министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 елда балигъ булмаганнар катнашында **42 янгын** чыккан, аларда 26 балигъ булмаган бала зыян күргән, шулардан 7 се – һәлак булган, 19 – төрле җәрәхәтләр алган. Узган ел белән чагыштырганда, янгыннарда һәлак булган балалар саны 42% ка кимегән (2015 елда – 12 бала һәлак булган). Балигъ булмаганнар катнашында булган янгыннар саны 35% ка кимегән (2015 елда 65 янгын, 2016 елда 42 янгын). Шулай итеп, 2016 елда янгыннарда балалар белән булган хәлләр соңгы 4 елда уңайрак булып санала.

43нче диаграмма


2013 – 2016 елларда янгыннарда һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны



Элеккечә, анализдан күренгәнчә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар аеруча хәтәр төркемгә керә. Бу кече яшьтә булуга, килеп чыккан хәлне тиз генә аңлап, хәл итү юлын таба белмәүгә бәйле. Һәлак булучылар арасында дүрт бала 6 яшькә кадәрге, ике бала –7 дән 13 яшькә кадәрге, бер бала – 14 тән 17яшькә кадәрге категориягә керә.

44 нче диаграмма

2013–2016 елларда янгыннарда һәлак булган һәм җәрәхәтләр алган балалар саны (яшь буенча)



Һичшиксез, 2016 елның гыйнварында Лениногорск районында булган янгын киң җәмәгатьчелекне тетрәндерергә мәҗбүр итте, ул янгында биш баласы белән ана кеше янып үлде. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бу фаҗигане өйрәнгәннән һәм күпбалалы гиләне шундый һәлакәткә китергән сәбәпләрне ачыклаганнан соң Лениногорск муниципаль районы профилактика субъекты системалары эшендә җитешсезлекләр барлыгы ачыкланды. Күпбалалы О.А.Журавлева гаиләсе (алты балигъ булмаган балалы) беркайда да исәпкә һәм патронажга куелмаган. Гаилә аз керемле буларак дәүләттән законнарда билгеләнгән пособиеләрне ала. Моннан тыш, О.А.Журавлевлар гаиләсе элек ана кеше спиртлы эчемлекләр кулланганлыктан һәм балаларны караучысыз калдырып йөргәнлектән социаль яктан тотрыксыз гаиләләр исәбенә куелган һәм ведомствоара исәптә торган була. Ләкин уңай реабилитация сәбәпле исәптән төшерелә. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үткәргән тикшерүдән күренгәнчә, гаиләне социаль яктан тотрыксыз гаиләләр исәбеннән төшерү сәбәпләре нигезсез була.

Бу коточкыч фаҗигане өйрәнү йомгаклары буенча республикада балалары булган шундый тотрыксыз гаиләләрне өйрәнү комиссиясе эшләде һәм ул мондый гаиләләргә ярдәм итү һәм, янгын чыгып, балаларның янып үлүләрен профилактикалау буенча республика күләмендә башкарылган эш булды. 2016 елда өч бала янып үлгән: Лениногорск, Алабуга һәм Сарман районнарында.

8 нче таблица

2013–2016 елларда янгыннарда һәлак булган һәм җәрәхәтләр алган балалар саны (муниципаль районнар буенча)

Муниципаль берәмлек исеме	*2013 ел*		*2014 ел*		*2015 ел*		*2016 ел*	
	һәлак булган балалар	*җәрәхәт алган балалар*	*һәлак булган балалар*	*җәрәхәт алган балалар*	*һәлак булган балалар*	*җәрәхәт алган балалар*	*һәлак булган балалар*	*җәрәхәт алган балалар*
Лениногорск	-	*3*	-	-	-	-	***5***	-
Сарман	-	-	-	-	-	-	***1***	-
Алабуга	*2*	*2*	-	*1*	-	-	***1***	*1*
Казан шәһәре	*2*	*4*	*2*	*6*	*3*	*11*	-	*7*
Чаллы шәһәре	*2*	*2*	-	*1*	-	*2*	-	*5*

Зелено-дольск	-	-	2	-	-	-	-	2
Кайбыч	-	-	-	-	-	-	-	1
Зәй	-	2	-	3	-	-	-	1
Минзәлә	-	-	-	-	-	-	-	1
Чирмешән	-	-	-	-	-	-	-	1
Актаныш	1	-	-	-	4	-	-	-
Спас	-	-	-	-	2	-	-	-
Арча	-	2	-	-	2	-	-	-
Чүпрәле	-	-	-	-	1	-	-	-
Әлмәт	-	4	-	3	-	2	-	-
Түбән Кама	2	-	-	1	-	1	-	-
Тукай	-	-	-	-	-	1	-	-
Бөгелмә	-	1		3	-	1	-	-
Баулы	-	-	1	-	-	-	-	-
Кукмара	-	-	2	-	-	-	-	-
Тәтеш	-	-	3	-	-	-	-	-
Азнакай	-	-	-	1	-	-	-	-
Биектау	-	1	-	1	-	-	-	-
Зелено-дольск	-	3	-	-	-	-	-	-
Менделеевск	-	2	-	-	-	-	-	-
Алексеевск	3	-	-	-	-	-	-	-
БАРЛЫГЫ	***12***	*26*	***10***	*20*	***12***	*18*	*7*	*19*

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: балигъ булмаганнар катнашында булган янгыннарның иң зур өлешен елдан-ел балаларның ут белән саксызлыгы тәшкил итә, 2016 ел искәрмә булмады. 2016 елда балалар зыян күргән 42 янгыннан шул сәбәпле 27 янгын килеп чыккан.

9нчы таблица

2013– 2016 елларда балалар зыян күргән янгыннарның килеп чыгу сәбәпләре	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***
Балаларның ут белән саксыз булуы	*46*	*53*	***51***	***27***
Электр җиһазларын урнаштыру һәм эшләтү кагыйдәләрен бозу	*8*	*5*	***4***	*7*
Олыларның ут белән саксыз булуы	*4*	*1*	***3***	***3***
Мичләрне урнаштыру һәм эшләтү кагыйдәләрен бозу	*2*	-	***2***	-


Мөлкәтне юкка чыгару (аңа зарар китерү), кеше сәламәтлегенә зыян салу (янгын чыгару) буенча мәкерле гамәлләр кылу	-	-	**2**	**1**
Тәмәке тарткандагы саксызлык	5	4	**1**	**-**
Газ, керосин, бензин һәм башка матдәләрдә эшләүче көнкүреш җиһазларын эшләтү кагыйдәләрен бозу	2	_	_	**2**
Башка сәбәпләр	2	3	**2**	**2**

Янгыннардан соң балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан 8 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән. Шулай да әлеге эшне җитәрлек дип бәяләп булмый, чөнки янгыннар турында муниципаль комиссияләргә материаллар җибәрү янгыннарда балаларның фаҗигале һәлак булуына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү кебек мөһим бурычны башкаруга ярдәм итә. Балаларны тәрбияләүдә җаваплылыкны арттыру күзлегеннән ата-аналарга тәэсир итү механизмы буларак әлеге алымны куллану алга таба мондый фаҗигаләрне булдырмау һәм кисәтү, профилактика буларак каралырга тиеш.

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлеменә китергән шартлар структурасында ***юл-транспорт һәлакәтләрендә*** җәрәхәтләр алу аерым урын алып тора. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (алга таба – ТР буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе) мәгълүматлары буенча, 2016 елда балигъ булмаганнар катнашында 631 юл-транспорт һәлакәте (ЮТҺ) теркәлгән, аларда 19 бала һәлак булган һәм 803 бала җәрәхәт алган.

45нче диаграмма

2013–2016 елларда Татарстан Республикасында балалар катнашында булган ЮТҺ саны




Узган елның шул чоры белән чагыштырганда, балигъ булмаганнар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре 20% ка арткан (2015 елдагы 622 очрактан 2016 елда 756 очракка кадәр).

ЮТҺ аркасында җәрәхәтләр алган балалар саны, узган елгы саннар белән чагыштырганда, шулай ук 22% ка арткан (2015 елдагы 631 очрактан 2016 елда 803 очракка кадәр). Һәлак булган балалар саны элеккечә – 19.

46 нчы диаграмма


2013–2016 елларда ЮТҺдә һәлак булган һәм җәрәхәт алган балалар саны



Узган ел йомгаклары буенча, республикада юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күргәннәр арасында 7 яшьтән 14 яшькә кадәрге башлангыч һәм урта сыйныф укучылары күбрәк. Шул ук вакытта ЮТҺендә һәлак булган балалар арасында 18 яшькә кадәр булган барлык категория дә урын алган.


47нче диаграмма

2013–2016 елларда ЮТҺ аркасында гомере үзелгән балалар саны (яшь буенча)



48нче диаграмма

2013–2016 елларда ЮТҺ аркасында җәрәхәт алган балалар саны (яшь буенча)



Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе мәгълүматлары буенча, 2016 елда 153 ЮТҺ – бу балигъ булмаганнар катнашындагы ЮТҺ гомуми саныннан 20,2% - балалар гаебе белән килеп чыккан. Шулай итеп, балалар гаебе белән килеп чыккан ЮТҺ саны соңгы 3 ел ел дәрәҗәсендә калган диярлек, бу исә балаларга юлларда куркынычсызлык нигезләрен укыту методикасын камилләштерү, анда инновацион технологияләр кертүзарурлыгы турында сөйли.

Балалар гаебе белән килеп чыккан ЮТҺнең төп сәбәпләре түбәндәгеләр булды: транспорт якынлашканда, махсус билгеләнмәгән урында юлны аркылы чыгу (68 очрак), каршылыклар артыннан кинәт юлга йөгереп чыгу (34 очрак), велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы (31 очрак).

10 нчы таблица

2013–2016 елларда балалар гаебе белән булган ЮТҺ сәбәпләре

ЮТҺ сәбәпләре	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***
Транспорт якынлашканда, махсус билгеләнмәгән урында юлны аркылы чыгу	*32*	*26*	*68*	*66*
Каршылык артыннан кинәт юлга йөгереп чыгу	*41*	*40*	*34*	*38*
Велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы	*57*	*53*	*31*	*29*
Светофорның тыю сигналына юлны аркылы чыгу	*6*	*7*	*6*	*8*
Балаларның юлга чыгып уйнавы	*2*	*6*	*1*	*5*
Автомобиль юлыннан хәрәкәт итү	*1*	*1*	*0*	*2*
Юл хәрәкәте кагыйдәләрен балаларның башкача бозуы	*48*	*20*	*11*	*5*
Барлыгы	*187*	*153*	*151*	*153*

Олылар (транспорт йөртүчеләр) гаебе белән булган ЮТҺнең төп сәбәпләренә тизлек режимын сакламау, каршы хәрәкәт өчен билгеләнгән полосага чыгу, юл аша чыгу урыннарында җәяүлеләрнең өстенлекләре булса да, аларны уздырмау, транспорт чарасы белән исерек хәлдә идарә итү керә.

ЮТҺ китергән шартларны караганнан соң, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре исеменә Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан **733** ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында **материаллар җибәрелгән**.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 елда тагын 20 бала бүтән бәхетсезлек очраклары (тәрәзәләрдән егылып төшү, авыр предметлардан җәрәхәт алу һ.б.) аркасында һәлак булган.

Җитди әһәмият бирүне сорый торган проблема мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге балаларның тәрәзәдән егылып төшүләренә кагыла 9 суицидка кагылышы булмаган).

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләреннән күренгәнчә, 2016 елда мәктәпкәчә яшьтәге 4 бала тәрәзәдән егылып төшкән. Мондый фактлар:

Казан шәһәрендә (2 очрак), Түбән Кама (1 очрак), Бөгелмә (1 очрак). Иң өлкән балага 5 яшь, иң яшенә – бер яшь. 2016 елда егылып төшүчеләр арасында һәлак булучылар булмаган, имгәнү һәм җәрәхәтләнү теркәлгән. Ләкин мондый вәзгыять Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне нык борчый, шуңа күрә аның тарафыннан муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыклары исеменә мондый очракларны алга таба булдырмау буенча профилактика чаралары күрү турында тиешле мөрәҗәгатьләр юлланды.

Балаларның үлеменә китергән фаҗигале бәхетсезлек очракларының сәбәпләренә һәм шартларына ясалган анализдан күренгәнчә, әлеге очракларның күбесенең олыларның үз ата-ана вазыйфаларына җавапсыз караулары аркасында барлыкка килүе хак. Минем фикеремчә, үз ата-ана вазыйфаларына салкын карау сәбәпле балалар һәлак булган яки бала сәламәтлегенә каты зыян килгән барлык очракларда да һәркайсына ата-аналарда аларның үз ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү буенча гаепләре булу-булмау күзлегеннән бәя бирелергә тиеш. Әлеге мәсьәләне ата-аналарны Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка тар-

ту турындагы административ законнар кысаларында да, ата-аналарны Россия Федерациясе Җинаять кодексының 125 (куркыныч шартларда калдыру), 156 (балигъ булмаганнарны тәрбияләү буенча бурычларны үтәмәү) статьялары буенча җинаять җаваплылыгына тарту өчен нигезләр булуны исәпкә алып та карау өчен нигезләр бар. Мондый якын килү, төп көчне булган хәлләрне теркәүгә һәм исәпкә алуга бирүгә генә кайтып калмыйча, һәр очракны җентекләп өйрәнергә, иң яхшы эшли торган һәм максатчан профилактика чараларын уйлап табарга мөмкинлек бирер, дип уйлыйм. Ләкин, югарыда әйтеп киткәнчә, бәхетсезлек очраклары буенча тиешле материалларны балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә юллау тәжрибәсе киң кулланылмый, бу сүзләр һәр ЮТҺ очрагы буенча мондый материалларны җибәрү Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең тиешле дәрәҗәдә оештырылган эшенә кагылмый.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасында тышкы сәбәпләр аркасында балалар үлеменең һәм суицид, бәхетсезлек очраклары һәм аларга карата кылган җинаятьләр аркасында балалар үлеменең бердәй төгәл исәбен алып бару вәзгыяте хәл ителмәгән килеш кала. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, шулай ук Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан Статистик мәгълүматның төрле булу очраклары бар.

Бу ситуация бүген балалар үлеме статистикасының адекват чынлыктан читтә торуын күрсәтә һәм өйрәнелә торган өлкәдә объектив анализ ясарга комачаулый. **Моңа бәйле рәвештә, балаларның бәхетсезлек очраклары аркасында һәлак булуын һәм җәрәхәтләр алуын профилактикалау максатыннан түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саныйм:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасында тышкы сәбәпләр аркасында балалар үлеменең бердәй төгәл исәбен алып бару буенча төрле ведомстволарның оператив теркәүнең һәм исәпкә алып баруның бердәй методологиясенә нигезләнгән үзара регламентация турындагы мәсьәләне карарга тиеш;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ның ЮХИДИ идарәсе, иҗтимагый волонтерлык оешмалары белән берлектә янгыннарда, суда, юлларда, урманда, өйдә һәм башка вәзгыятьләрдә куркынычсызлык нигезләренә өйрәтү предметларына гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпкәчә балалар бакчаларында системалы өйрәтә һәм әзерләү дәресләре алып баруны тәэмин итәргә,

шулай ук балалар белән бәхетсезлек очракларын профилактикалау максатыннан һәм ата-аналарның җаваплылыгын арттыру йөзеннән ата-аналар җыелышлары үткәрү;

җирле үзидарә органнары балигъ булмаганнарны, шул исәптән каникул вакытларында да, максималь җәлеп итәргә тиеш;

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМна балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр исеменә суда балаларның фаҗигале үлеменә китерү торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү буенча һәм ата-аналарны (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрү эшен активлаштырырга;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә балалар катнашында булган бәхетсезлек очраклары шартларын һәм сәбәпләрен ачыклау максатларында профилактика рәвешендәге системалы чаралар эшләү, шул исәптән ата-аналарны (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы буенча җаваплылыкка тарту өчен нигезләрне тикшерергә;


«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына балалар катнашында булган бәхетсезлек очракларын, халыкта ата-ана җаваплылыгының нинди урын алып торуын аңлый башлавына ирешү күзлегеннән чыгып, массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуда ярдәм итәргә.

Балалар үлеменең тышкы сәбәпләре арасында **суицидлар** бүген аерым урын алып тора.

2016 елда республикада, 2015 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, балигъ булмаганнар арасында теркәлгән суицид очраклары санының кимүе күзәтелде. 2016 елда 13 балигъ булмаган бала үз-үзенә кул салган, соңгы 6 елда бу иң аз күрсәткеч. Шулай да республикада бер генә шундый очрак булса да, бу өлкәдә борчылырга сәбәп бар.

49 нчы диаграмма

2011–2016 елларда балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны



Идел буе федераль округы субъектлары буенча суицидаль вәзгыять түбәндәгечә билгеләнә:

11нче таблица

2016 елда ИФО субъектлары буенча балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны

ИФО субъекты исеме	Балалар саны (мең кеше)	балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны (кеше)	10 мең балага карата суицидлар саны
Чуваш Республикасы	250	12	0,48
Башкортостан Республикасы	880	41	0,47
Удмурт Республикасы	328	15	0,46
Пермь крае	557	22	0,39
Марий Эл Республикасы	140	5	0,36
Мордовия Республикасы	136	4	0,29
Саратов өлкәсе	541	14	0,26
Оренбург өлкәсе	516	12	0,23
Ульян өлкәсе	217	5	0,23
Татарстан Республикасы	796	13	0,16
Пенза өлкәсе	229	3	0,13
Самара өлкәсе	583	6	0,10
Киров өлкәсе	243	2	0,08
Түбән Новгород өлкәсе	571	2	0,04

2016 елда Татарстан Республикасында булган суицидларның күпчелеге Казан (5) һәм Әлмәт (2) шәһәрләрендә булды. Актаныш, Балтач, Кукмара, Лаеш, Тукай һәм Ютазы муниципаль районнарында берәр факт теркәлде. Балигъ булмаганнарның үзләренә кул салу алымнары: 10 очракта – асылыну, 3 очракта биектән егылып төшү.

12 нче таблица

2012–2016 елларда Татарстан Республикасында төгәлләнгән балалар суицидлары саны (муниципаль берәмлекләр буенча)

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге	***Суицидлар саны***					
	2011 ел	***2012 ел***	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015ел***	***2016 ел***
Казан шәһәре	*4*	*3*	*1*	*8*	***5***	***5***
Әлмәт	*3*	*2*	*2*	*-*	***-***	***2***
Балтач	*-*	*1*	*1*	*-*	***-***	***1***
Тукай	*-*	*-*	*-*	*1*	***-***	***1***

Актаныш	*2*	*-*	*1*	*-*	*-*	***1***
Кукмара	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***
Лаеш	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***
Ютазы	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*	***1***
Чаллы шәһәре	*-*	*-*	*2*	*5*	*3*	*-*
Зеленодольск	*2*	*1*	*3*	*-*	*1*	*-*
Баулы	*-*	*1*	*-*	*1*	*1*	*-*
Югары Ослан	*-*	*1*	*-*	*-*	*1*	*-*
Нурлат	*1*	*-*	*1*	*-*	*1*	*-*
Азнакай	*1*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*
Апас	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*
Спас	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*
Чистай	*-*	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*
Бөгелмә	*3*	*2*	*1*	*3*	*-*	*-*
Түбән Кама	*3*	*1*	*1*	*1*	*-*	*-*
Яңа Чишмә	*1*	*-*	*1*	*1*	*-*	*-*
Алексеевск	*-*	*1*	*-*	*1*	*-*	*-*
Чүпрәле	*1*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*
Питрәч	*-*	*-*	*-*	*1*	*-*	*-*
Зәй	*-*	*-*	*2*	*-*	*-*	*-*
Лениногорск	*1*	*1*	*1*	*-*	*-*	*-*
Балык Бистәсе	*1*	*2*	*-*	*-*	*-*	*-*
Аксубай	*1*	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*
Әлки	*-*	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*
Арча	*-*	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*
Әгерҗе	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*
Сарман	*1*	*-*	*-*	*-*	*-*	*-*
Барлыгы	***27***	***19***	***17***	***23***	***16***	***13***


Республика районнары һәм шәһәрләре арасында соңгы алты елда суицидаль хәлне анализлаудан күренгәнчә, шундый афәт булган шәһәрләрдән Казан (26 суицид), Чаллы шәһәре (10 суицид), Әлмәт һәм Бөгелмә районнары (9ар суицид), Зеленодольск районы (7 суицид), Түбән Кама районы (6 суицид), Актаныш районы (4 суицид), Балтач, Баулы, Нурлат, Яңа Чишмә, Лениногорск һәм Балык Бистәсе (өчәр суицид). Күпмедер дәрәҗәдә бу һәр муниципаль берәмлектәге балалар санына бәйле. Шуның белән бергә, бер генә очрак та булырга тиеш түгел дигән фикердән чыгып эш итәбез икән, бирелгән абсолют саннар әлеге муниципаль районнарда профилактика эшенең җитәрлек булмавын раслый.

Профилактик характердагы чаралар һәм механизмнар булдыру эшчәнлегендә алга таба профилактика эшен алып бару өчен суицидаль тәртип күзлегеннән хәтәр төркемне билгеләргә мөмкинлек бирә торган анализ үткәрү мөһим.

Соңгы 4 елда яшүсмерләр арасындагы суицид проблемасының социаль портретын анализлаудан күренгәнчә, аның күбесе 16 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган. Шулай да яшәрә бару тенденциясе чагыла: балалар-суицидантлар арасында 14 яшьтән 16 яшькә кадәргеләре һәм кече яшьтәге балалар да күренә. Мәсәлән, 2016 елда ике суицид корбанына нибары 10 яшь була.

50 нче диаграмма

2013–2016 елларда суицид кылган балаларның яшь составы




Җенси билгедән чыгып караганда, суицидантлар арасында ит-атлар күпчелекне тәшкил итә. «В.П.Сербский исемендәге федераль медицина тикшеренү психиатрия һәм наркология үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе материаллары буенча малайлар суицидларны кылалар, ә кызлар суицид кылырга маташалар. Бу рәвешле бирелгән нәтиҗәне Татарстан Республикасында балалар суициды мониторингы да беркадәр раслый: 2016 елда 12 малай һәм 1 кыз суицид кылган.

Яшәү урыны буенча караганда, суицидантлар арасында (шәһәр, авыл) шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2016 елда 13 суицидның 7се (яисә 53,8 %) шәһәр балалары тарафыннан, 6сы (яисә 46,2%) – авыл балалары тарафыннан кылынган. Шуңа күрә балалар суициды темасы – эре мегаполислар проблемасы дип кенә әйтеп булмый. Эксперт белешмәләреннән күренгәнчә, шәһәрдә яшәүчеләр арасында суицидаль хәтәр, аның авылда яшәүче халыкка таралуы чагыштырмача аз йогынты ясый.

Балаларның мәшгульлегеннән чыгып караганда, һәлак булучыларның барысы да укучылар булган: 10 бала мәктәптә укыган, 3 яшүсмер урта һөнәри белем бирү оешмасында укый торган булган.

51 нче диаграмма

2013–2016 елларда суицид кылган балаларның шөгыль белән тәэмин ителеше



Суицид кылучылар арасында ***тәртипсез гаиләдә*** тәрбияләнүче балаларның булуы аерым мәсьәлә булып тора. Суицид кылучылар арасында ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның булуы аеруча борчу тудыра. 2016 елда әбисе тәрбиясендәге 1 ятим бала алдан уйлап үз-үзенә кул салды. (Казан) Соңгы биш елда (2012 – 2016) еллардагы суицидларны гомумиләштерү 11 ятим баланың (яки суицид кылган барлык балаларның гомуми санының 12,5%) суицид корбаны булуын күрсәтте, берсе – балалар йортында тәрбияләнүче, икесе – урта һөнәри белем бирү оешмасы укучысы, дүртесе – опекага алынган, дүртесе уллыкка алынган балалар. Ләкин бу балалар опека һәм попечительлек органнарының игътибар һәм контроль зонасында торганнар.

Моннан тыш, 2016 ел йомгаклары буенча балигъ булмаган суицидантларның икесе (Тукай һәм Балтач муниципаль районнары) исәптә яисә социаль хезмәтләр күзәтчелегендә (тәртипсез гаилә булганлыктан) торганлыгы ачыкланды. Соңгы 3 елда (2014 – 2016 еллар) 10% бала (5 кеше) теге яисә бу дәрәҗәдә начар гаиләдә тәрбияләнгән булып чыкты.

Шуның белән бергә, 2016 елда үлгән дүрт бала закон белән конфликтта була һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә исәптә тора. Соңгы өч елда (2014-2016) 52 суицидант баланың 10ы (яисә 19%) балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрнең профилактик эш зонасында исәптә тора.

Шулай итеп, 2016 елда балалар арасында суицид вәзгыятен анализлау йомгаклары буенча 13 баланың 5 се тиешле хезмәтләр – балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрнең игътибар үзәгендә тора. Соңгы өч елдагы мәгълүматны гомумиләштерүдән күренгәнчә, мондый балалар күрсәтелгән органнар игътибарыннан читтә тормый. Әлеге балаларның үлеме шушы органнар тарафыннан башкарылган профилактикага бәйле эшләрнең җитәрлек булмавын дәлилли.

2016 елда, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ министрлыгы күрсәткечләре буенча, өч яшүсмер (23%) суицидны ***алкоголь (наркотик)***

кулланган *халәттә кылган.* Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, алкоголь эчкән халәт 74 суицидаль омтылышның 13енә хас була (18%) Шулай итеп, алкогольле халәт 20% суицидаль вәзгыять яшүсмернең суицидаль халәтен тагын да катлаулан-дыра торган фактор булып тора.

Суицид кылган һәм кылырга теләгән балаларның психик саулыгын анализлау шуны раслый, баланың мондый тәртибе психик авыруының көчәеп китүенә бәйле. 2016 елда шулар арасыннан бер генә бала психиатрда исәптә торган. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белгечләре фикеренчә, күпсанлы тикшеренүләр күрсәткәнчә, яшүсмернең суицидаль кәефе нерв системасы авырулары булуга бәйле түгел.

2016 елда яшүсмерләрнең үз-үзләренә кул салудан үлүләре сәбәпләрен анализлау, балалар үлеменә китергән сәбәпләрдән түбәндәгеләрне билгеләргә нигез бирде:

3 очракта гаиләдәге үзара каршылыклар;

2 очракта катлаулы романтик үзара мөнәсәбәтләр һәм башка сәбәпләр;

1 очракта мәктәптәге каршылыклы вәзгыять;

1 очракта җинаять җаваплылыгына тартылуга бәйле рәвештә;


4 очракта сәбәпләре билгесез булып калды.

Ләкин яшүсмерне нинди фаҗигале фикерләрнең үлемгә китергәнен белү мөмкин булмаса да, шунысы мөһим: аны шушы барлыкка килгән хәлдән арындырырга, ярдәм итәргә якында бер кеме дә булмаган. Шуңа күрә балаларда стрессқа каршы торучанлык, тотрыклылык тәрбияләү бик мөһим. Балалар белән профилактик эш нәкъ менә шуңа юнәлдерелгән булырга тиеш. Ә ата-аналар белән профилактик эшнең максаты – барын-нан да элек, авыр минутларда балаларга аннан чыгу юлын күрсәтә торган кешеләрнең янда булуын аңлату.

Суицид кылырга маташучы балигъ булмаганнарның саны тотрыклы калу аеруча борчу тудыра. 2016 елда балигъ булмаганнар арасында суи-цид кылырга маташучылар саны шактый артты: 74 очракка кадәр җитте (2013 елда – 59, 2014 елда – 55, 2015 елда – 60).

52 нче диаграмма

2013-2016 елларда балигъ булмаганнар арасында башланган суицидлар саны



Республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча бу хәл түбәндәге рәвешчә билгеләнә: .

13 нче таблица


2016 елда башланган суицидлар саны (муниципаль берәмлекләр буенча)

Муниципаль район, шәһәр исеме	Количество суицидальных попыток
Казан шәһәре	*41*
Чаллы шәһәре	*10*
Арча	*3*
Әлмәт	*2*
Бөгелмә	*2*
Алабуга	*2*
Зеленодольск	*2*
Лаеш	*2*
Лениногорск	*2*
Нурлат	*2*
Түбән Кама	*1*
Яңа Чишмә	*1*
Питрәч	*1*
Саба	*1*
Спас	*1*
Барлыгы	***74***

Яшь буенча караганда балигъ булмаганнарның төп өлеше 16 яшьтән 18 яшькә кадәргеләр тәшкил итә. Шулай да яшәрә бару тенденциясе чагыла: балалар-суицидантлар арасында 14 яшьтән 16 яшькә кадәргеләре һәм кече яшьтәге балалар да күренә.

53 нче диаграмма

2014 – 2016 елларда суицидка омтылган балаларның яшь составы



Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, суицидаль омтылыш ясаган балаларның

гомуми санынннан 82%ы кызларга туры килә. 74 очракның 11 ендә бары тик кызлар арасында гына демонстратив суцидаль омтылыш күзәтелде.

Балигъ булмаганнарның суицидаль омтылышларының төп алымнары– кан тамырын кисү һәм агулану.

Ведомстволарның – проблемалы балалар арасында профилактика субъектларының суицидларны кабатлау булмасын өчен чаралар күрү буенча үз вакытында һәм төгәл үзара эшчәнлек мөһим профилактика чарасы булып тора. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: балаларның начар хәлдә калуын профилактикалау системасы субъектлары – ведомстволарның кабат башкарыла торган суицидларны кисәтү чараларын күрү буенча үзара хезмәттәшлеге республикада начар алып барыла. Аерым алганда, Казан шәһәрендә балигъ булмаганнарның 41 суицидаль омтылышыннан 25 очрагы турында гына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә мәгълүм, Моннан тыш, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләре нигезендә 2016 ел дәвамында Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ территориаль бүлекчәләренә сәламәтлек саклау учреждениеләреннән 16 омтылыш турында хәбәр алынган, ә бер елга 74 суицидаль омтылыш булган. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының бу өлкәдәге эшен җитәрлек түгел дип танырга кирәк.

Ясалган анализ нигезендә нәтиҗә ясарга мөмкин, түбәндәге ***балаларны хәтәр төркемгә*** кертергә кирәк:

балаларның һәм гаиләләрнең начар хәлдә калулары, төрле ведомствода (социаль яклау, опека һәм попечительлек органнары, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр) һәм ведомствоара контроль һәм исәп органнарында торучы балигъ булмаган балалар;

элек суицидаль омтылыш булган балалар.

Гамәлдә һәр суицид омтылышы буенча Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе тарафыннан РФ Җинаять кодексының 110 статьясы нигезендә («Үзенә кул салуга җиткерү») җинаять эше ачыла, аның кысаларында булган эшнең бөтен фактлары ачыклана. 2016 елда 13 суицидның 11 е буенча һәм 74 суицид омтылышының 11е буенча җинаять эше ачылды. Тикшерү чаралары йомгаклары буенча җинаять составы булмау сәбәпле 15 эш туктатылды, 1 җинаять эше буенча гаепләү карары чыгарылды.

Мисал*: Минзәлә район суды тарафыннан 42 яшьлек Мусинга хөкем карары чыгарылды, ул РФ Җинаять кодексының 110 статьясында каралган җинаятьне кылуда гаепле дип табылды. 2011 елдан алып 2016 елның сентябренә кадәр бергә торучы хатынының улын даими җәберләп торган . Чираттагы кыйналудан соң малай суицид кылырга маташкан. Вакытында күрсәтелгән медицина ярдәме нәтиҗәсендә генә малай исән*

калган. Мусинга 2 ел дәвамында шартлы рәвештә иректән мәхрүм ителү җәзасы бирелгән.

Балаларның һәм яшүсмерләрнең үз-үзләрен суицидаль тотуны профилактикалау максатларында түбәндәгеләрне тәкъдим итү зарур дип уйлыйбыз:

«Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июлендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм муниципаль комиссияләргә, бабалар һәм гаиләләр иминлеген профилактикалау системасының башка органнарына үз карамагындагы һәм ведомствоара буйсынудагы игътибар, контроль һәм исәпкә алу зоналарындагы суицидаль хәтәр төркем балаларын профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерү чараларын күрергә;

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе балаларның үз-үзләрен суицидаль тотышларын профилактикалау һәм кисәтү буенча эшчәнлеге кысаларында балаларның һәм гаиләләрнең начар хәлдә калуларын профилактикалауның барлык субъектлары арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү буенча эшне дәвам итәргә, шул исәптән балигъ булмаганның суицид ясарлык кәефе булуын ачыклаганда, аңа квалификацияле ярдәм күрсәтү регламентын эшләү һәм кабул итү турындагы мәсьәләне карарга кирәк;

мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәрергә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча республика сәламәтлек саклау учреждениеләренең балигъ булмаганнар тарафыннан башкарып каралган һәм аларга билгеле булган суицид очраклары турында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә үз вакытында һәм мәҗбүри мәгълүмат бирүне билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә кирәк;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына республиканың мәгариф оешмаларында конфликтлы очракларны хәл итүнең профессионал һәм нәтиҗәле алымнарын эшләү һәм куллану, мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәрергә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча чаралар күрергә кирәк;

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына түбәндәгеләр буенча профессиональ һәм нәтиҗәле методикалар эшләү һәм куллану чараларын күрү:

мәгариф оешмаларында конфликтлы хәлләрне хәл итү буенча;

мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренең суицидаль хәтәр билгеләрне тану өлкәсендә, шундый хәтәрне җиңеп чыгу, бала белән уртак тел таба белү буенча компетенцияләрне арттыру буенча;

укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәргә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча, бала белән партнерлык һәм дуслык юлларын эзләп табарга;

балалар белән аларда стессларга каршы торучанлык күнекмәләрен булдыру эшләре алып барырга, позитив һәм дуслык алымнары табу юлын күрсәтергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына хәтәр төркемдәге балаларга үз вакытында һәм тиешле дәрәҗәдәге психологик ярдәм күрсәтү максатларында психологик хезмәтләр белгечләренең һөнәри квалификация дәрәҗәсен камилләштерү һәм арттыру буенча чаралар күрергә кирәк.

Балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләренең берсе - **аларга карата башкарылган җинаятьләр аркасында балаларның һәлак булуы**.

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ биргән мәгълүматлар буенча, 2016 елда 1 бала үтерелгән (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 105 статьясы) (алга таба – Россия Федерациясе ҖК) (2015 елда – 4 бала). Үз аналарының корбаннарына әверелгән яңа туган сабыйларның саны тотрыклы кала, РФ Җинаять кодексының 106 статьясы буенча кузгатылган җинаять эшләре буенча – елына 2 бала. Саксызлык аркасында зыян китереп, 15 балигъ булмаган бала вафат булган (РФ Җинаять кодексының 109 статьясы).


3.1.2. Рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклану хокукын тәэмин итү

Балаларга карата көч куллануны һәм рәхимсезлекне кисәтү мәсьәләләре эшчәнлекнең актуаль һәм өстенлекле юнәлеше булып тора.

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ биргән мәгълүматлар буенча, 2016 елда балаларга карата төрле характердагы 1 619 җинаять кылынган (балаларны тәрбияләп торуга акча бирүдән явыз ният белән качу фактлары буенча җинаятьләрдән тыш).

54 нче диаграмма

Балигъ булмаганнарга карата 2013–2016 елларда кылынган җинаятьләр саны



Диаграммадан күренгәнчә, балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр санының узган елдан башлап кими бару тенденциясе бара, 17,8% тәшкил итте (-349 җинаять).

Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләрнең гомуми саны арту фонында, җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны, узган ел белән чагыштырганда, 35% ка кимеде һәм 1 066 кешене тәшкил итте.

14нче таблица

2013-2016 елларда җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны


Җинаять төрләре	***Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны***			
	2013 ел	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***
Зыян күрүчеләр дип танылган балалар саны, *шул исәптән*	**1 349**	**1 491**	**1 638**	**1 066**
РФ ҖК ст. 105 («Үтерү»)	21	19	12	8
РФ ҖК ст.106 («Ананың яңа туган баласын үтерүе»)	1	2	2	2
РФ ҖК ст. 109 («Саксызлык аркасында үлемгә китерү»)	17	27	12	15
РФ ҖК ст. 110 («Үз-үзен үтерүгә җиткерү»)	4	19	2	5
РФ ҖК ст. 111 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү»)	14	8	7	5
РФ ҖК ст. 112 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян китерү»)	26	14	21	29
РФ ҖК ст. 115 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә җиңелчә зыян китерү»)	50	39	50	55

РФ ҖК ст. 116 («Кыйнаулар»)	350	356	378	275
РФ ҖК ст. 117 («Җәфалау»)	6	19	36	28
РФ ҖК ст. 119 («Үтерү белән янау»)	45	48	58	37
РФ ҖК ст. 125 («Куркыныч астында калдыру»)	4	0	7	4
РФ ҖК ст. 127 («Законсыз рәвештә иректән мәхрүм итү»)	2	3	7	1
РФ ҖК ст. 131 («Көчләү»)	27	20	70	15
РФ ҖК ст. 132 («Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре»)	73	74	139	48
РФ ҖК ст. 133 («Сексуаль характердагы гамәлләр кылуга мәҗбүр итү»)	0	5	1	4
РФ ҖК ст. 134 («16 яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү»)	66	84	177	66
РФ ҖК ст. 135 («Бозыклык гамәлләре кылу»)	44	35	63	9
РФ ҖК ст. 156 («Балаларга карата рәхимсезлек кылу белән бәйле ата-аналар бурычларын үтәүдән баш тартканөчен җинаятьләр»)	54	101	104	82
РФ ҖК ст. 150, 151, 151.1 («Балигъ булмаган затны җинаять кылуга, җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү белән бәйле җинаятьләр»)	9	19	13	92
РФ ҖК ст. 240–242 («Фәхишәлек белән шөгыльләнүне, порнография материалларын яисә предметларын законсыз эшләү һәм таратуны оештыру һәм шуңа җәлеп итү белән бәйле җинаятьләр»)	1	7	27	19
РФ ҖК ст. 158, 159, 161–163 («Милеккә каршы җинаятьләр (караклык, мошенниклык, талау, юлбасарлык, куркытып алу»)	498	377	323	234

Әлеге җинаятьләр буенча зыян күрүчеләр дип танылган балалар турындагы белешмәләргә ясалган анализ яшүсмерләргә карата кылынган хокуксыз гамәлләрнең сабый балаларга карата кылынган җинаятьләрдән 43% ка күбрәк булуын, ә 2016 елда кызларга каршы башкарылган җинаятьләр саны малайларга карата башкарылганнарыннан 5% ка күбрәк булуын күрсәтте.

55 нче диаграмма


2013–2016 елларда балаларга карата кылынган җинаятьләр саны, яшь һәм җенес буенча



Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләреннән күренгәнчә, 2016 елда ***балаларга карата көч кулланып башкарылган җинаятьләр 2015 ел белән чагыштырганда* 22% ка кимеде** (2013 елда – 709, 2014 елда – 650, 2015 елда – 1 100, 2016 елда – 854). Балаларга карата кылынган җинаятьләрнең гомуми саныннан 53% ны алып тора.

56 нчыдиаграмма

2013-2016 елларда балигъ булмаганнарга карата көч кулланып башкарылган җинаятьләр саны һәм шулар буенча зыян күргән дип танылган балалар саны



Игътибар итегез: 2016 елда көч кулланылган җинаятьләрнең корбаннары булган балигъ булмаганнарның саны кимеде – 328 балага (2013 елда – 766, 2014 елда – 769, 2015 елда – 975, 2016 елда – 647). Бу җинаять

эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балаларның гомуми саныннан 60% бала көч кулланылган җинаятьләрнең корбаннары булган дигәнне аңлата.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 112 статьясы («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян китерү») буенча балаларга карата кылынган җинаятьләрнең артуы күзәтелә.

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләреннән күренгәнчә, җенси кагылгысызлыкка каршы җинаятьләрдән зыян күргән балигъ булмаганнар саны кимүгә таба бара, ләкин гомуми сан һаман зур булып кала. 2016 елда 22 көчләү (2015 елда – 161), сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре – 184 (2015 елда – 198), сексуаль характердагы гамәлләргә тарту – 8 (2015 елда – 1), 16 яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү – 266 (2015 елда – 297), бозыклык гамәлләре кылу – 39 (2015 елда – 66) теркәлде.

Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләргә ясалган мониторинг җенси кагылгысызлыкка каршы гаилә әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләрнең саны кимү турында сөйли. Аларның гомуми саны 2016 елда 441 җинаять булды. Шуның белән бергә, 2015 елдагы кебек үк, ул балаларга карата көч кулланып кылынган җинаятьләрнең яртысын тәшкил итә. (52%). Әлеге категориягә кергән 854 җинаятьтән:

270– ата-аналар тарафыннан (2015 елда – 234, 2014 елда – 168, 2013 елда – 104);

142 – аналары белән бергә яшәүчеләр тарафыннан (2015 елда – 169, 2014 елда – 22, 2013елда – 2);

29 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан кылынган (2015 елда – 169, 2014 елда – 9, 2013 елда – 76).

Балаларның җенси кагылгысызлыгына каршы башкарылган җинаятьләрнең 29 очрагында аларның балалар оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан кылынуы аерым игътибар бирүне һәм моңа каршы чаралар күрүне таләп итә. Бу көч куллану характерындагы гомуми җинаятьләрнең 3,4% ын тәшкил итә, (2015 елда барлыгы 30 очрак булып, ул гомуми җинаятьләрнең 0,2% ын тәшкил итте).

Балигъ булмаганнарга карата көчләү җинаятьләрен кылуга китергән төп шартлардан, элеккечә, балаларның начар тәртипле гаиләләрдә яшәүләре, ата-аналарның балаларына карата игътибарсыз булуы, балаларны күзәтүсез калдыруны аерып күрсәтергә була. Әлеге категориягә караган 69 (яисә 8%) җинаять начар тәртипле гаиләләрдә яшәүче балаларга карата башкарылган (2015 елда –1 100дән 142 яисә 13%).

Шушы уңайдан «Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999

елның 24 июлендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм муниципаль комиссияләргә, балалар һәм гаиләләр иминлеген профилактикалау системасының башка органнарына җаваплылыкны арттыруга игътибарны юнәлтергә кирәк дип уйлыйм. Кызганычка каршы, 2016 елда балалар үлеменә китергән, гаиләне ачыклау буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда муниципаль органнарның битарафлык фактлары урын алды.


***Мисал**: **Татарстан Республикасы** Алексеевск район суды карары белән Ч. Россия Федерациясе Җинаять кодексының 109 статьясындагы 1 өлешендә каралган җинаятьне кылган өчен 1,5 елга иреген нән мәхрүм ителде һәм 20 000 сум штраф салынды. Ч., ике айлык елый торган улына сосканы, ике-өч тапкыр аракыга манып, авызына каптыра. Нәтиҗәдә, бала этил спирты белән агуланып вафат була.*

***Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил** тикшергәннән соң аның ике балигъ булмаган (2005 һәм 2015 елгы балалар) баласын, авыр тормыш сәбәбенә бәйле рәвештә ГКУ «Кайгырту» яшүсмерләр өчен социаль приютка һәм Сабыйлар йортына урнаштырганлыгы билгеле булды. 2014 елда Ч.гаиләсендә 2 айлык бала шулай ук вафат була. Бу гаилә игътибарга алынырга тиеш булса да, җаваплы органнар тарафыннан балаларны приютка урнаштыру мәсьәләсе хәл ителми.*

2016 елда балаларга карата кылган сексуаль характердагы җинаятьләр саны кимеде, (2013 елда – 328, 2014 елда – 328, 2015 елда – 752, 2016 елда – 538).

57нче диаграмма

2013–2016 елларда балигъбулмаган балаларга карата сексуаль характердагы җинаятьләр саны




Әлеге категориягә караган 19 җинаятьне балигъ булмаганнарны фахишәлек, порнография материалларын һәм предметларын законсыз әзерләүгә һәм таратуга җәлеп итү һәм моны оештыру белән бәйле хокукка

каршы гамәлләр тәшкил итте (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 240-242 статьялары). 19 бала зыян күрүче дип танылды. Анализ әлеге өлкәдәге җинаятьчелекнең 2015 ел (29) белән чагыштырганда кимүен күрсәтә, ләкин барлык җинаятьләргә карата бу юнәлештәге күрсәткеч процент белән билгеләгәндә шул ук дәрәҗәдә кала (3,5%). Ә 2013 елда әлеге юнәлештә 1 җинаять теркәлгән булса, 2014 елда – 7). Мондый хәл балаларга карата җинаять кылу хәтәрен артуны күрсәтә, шуңа күрә хокук саклау органнары, балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектлары тарафыннан аларны булдырмау чараларын көчәйтүне таләп итә.

Сексуаль характердагы җинаятьләр арасында ***балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы кылынган җинаятьләр*** төп урынны алып тора. 2016 елда бу юнәлештәге 519 җинаять теркәлде, бу балигъ булмаганнарга карата кылынган барлык җинаятьләрнең 61% ын тәшкил итә. Күрсәтелгән категориядәге җинаятьләрнең узган ел белән чагыштырганда шактый кимүенә карамастан, аларның саны күп булып кала.

58 нче диаграмма

2013–2016 елларда җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләр саны һәм җинаятьләрдән зыян күргән балалар саны




Җенси кагылгысызлыкка каршы җинаятьләрдән зыян күргән балигъ булмаганнар саны 2016 елда 3 тапкырга кимеде һәм 142 баланы тәшкил итте (2013 елда – 210, 2014 елда – 218, 2015 елда – 450). Бу көч куллану турында җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләр дип танылган балаларның 22% җенси кагылгысызлыкка каршы җинаять корбаннары булганны күрсәтә (2015 елда – 46%)

2016 елда кече яшьтәгеләрнең җенси кагылгысызлыгына каршы кылынган җинаятьләр санының яшүсмерләргә карата кылынганнарыннан артыграк булуы тенденциясе сакланып калды. Кече яшьтәгеләрнең җенси кагылгысызлыгына каршы кылынган җинаятьләр саны узган чорга караганда шактый кимеде (2015 ел белән чагыштырганда 62 %).

59 нчы диаграмма


2013–2016 елларда җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләр саны



Кыз балалар җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләрнең корбаннары булып тора. Ләкин ир балаларга җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләрнең арту тенденциясе игътибарны җәлеп итә.

60 нчы диаграмма

2013–2016 елларда җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаятьләр саны



Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләргә ясалган мониторинг җенси кагылгысызлыкка каршы гаилә әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләрнең саны кимү турында сөйли. Аларның гомуми саны 2016 елда 131 җинаять булды, ягъни әлеге юнәлештәге барлык җинаятьләрнең 25% гаиләдә башкарылган (2015 елда – 30%). Әлеге категориягә кергән 519 җинаятьтән:

2 – ата-аналар тарафыннан (2013 елда – 2, 2014 елда – 0, 2015 елда – 8);

122 – аналары белән бергә яшәүчеләр тарафыннан (2013 елда – 0, 2014 елда – 6, 2015 елда – 96);

7 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан кылынган (2013 елда – 94, 2014 елда – 5, 2015 елда –120).

Шулай итеп, җенси кагылгысызлыкка каршы җинаятьләрдән зыян күрү хәтәре яный торган төркемгә бүген ана белән яшәүче ирле гаилә һәм анда тәрбияләнүче бала тора, җенси кагылгысызлыкка каршы җинаятьләрнең 24%ы ана белән яшәүче ирдән, 93%ы шундый гаиләләрдән булганны күрсәтә.

Административ күзәтчелектәге затлар (гаилә әгъзалары) белән яшәүче балалар шулай ук хәтәр төркемгә керә. Балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдә җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси иреген каршы җинаять кылу аркасында административ күзәтчелектәге затларның яшәве балаларның тормышына һәм сәламәтлегенә реаль куркыныч тудыра, балаларга каршы җинаять кылу куркынычы яный торган социаль хәвефле вәзгыять китереп чыгара.

Мисал: *Сарман муниципаль районында әбисенең бергә яшәүче ире әбинең 4 яшьлек оныгын көчләгән. Җинаятьче элек җенси кагылгысызлыкка каршы җинаять кылган өчен хөкем ителгән һәм хәзер эчке эшләр органнарының административ күзәтчелегендә тора.*

Мисал: *Казанда агасы балигъ булмаган ике туган сеңлесенә карата сексуаль характердагы көч кулланган һәм кылган гамәлен телефонга төшергән. Элек җинаятьче җенси кагылгысызлыкка каршы җинаять кылган өчен хөкем ителгән булган һәм эчке эшләр органнарының административ күзәтчелегендә торган.*

Балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләрне профилактикалау максатында җенси кагылгысызлыкка каршы җинаять кылган өчен административ күзәтчелектә торган затларга карата мәгълүматны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль (шәһәр) комиссияләре адресына вакытында тапшыру эшен төгәл оештыру сорала. Шушы уңайдан Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасында Эчке эшләр министры А.В.Хохорин адресына тиешле мөрәҗәгать җибәрелде.

Балигъ булмаганнарга карата көч кулланып җинаять кылуга китергән төп шартлардан, элеккечә, балаларның начар тәртипле гаиләләрдә яшәүләре, ата-аналарның балаларына карата игътибарсыз булуы, балаларны күзәтүсез калдыруны, җавапсызлык һәм битарафлыкны аерып күрсәтергә була. Җенси кагылгысызлыкка каршы кылган 31 җинаять начар тәртипле гаиләләргә туры килә.


2016 елда балигъ булмаганнарга карата балалар учреждениеләре хезмәткәрләре тарафыннан кылынган 29 җинаять теркәлү факты аеруча игътибар итүне һәм йогынты ясауны таләп итә, чөнки 27 очракта ул балаларга карата җенси кагылгысызлыкка каршы кылынган җинаять иде. Бу 2015 ел белән чагыштырганда 3 тапкырга артыграк (былтыр 9). Монда шуны билгеләп үтәргә кирәк, сүз ике педагогка: Әгерҗе муниципаль

районы ДЮСШ футбол буенча тренер-мөгаллим Б. һәм Әлмәт шәһәре гомуми белем бирү мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы Х. га карата җинаять эше турында бара. Әлеге җинаятьләр буенча 4 бала зыян күргән дип танылган.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында балаларны көчләүләр, аларга карата рәхимсезлек кылу вәзгыятенә ясалган анализ 2016 елда хәлнең 2015 ел белән чагыштырганда кимүгә таба баруын чагылдыра.

61 нче диаграмма

2013-2016 елларда балигъ булмаганнарга карата көч кулланып башкарылган җинаятьләр саны



Билгеле бер дәрәҗәдә бу республикада ел дәвамында республикада алып барыла торган профилактик эшләрнең уңай нәтиҗәсе дип әйтергә мөмкин. Шул рәвешле, тиешле хокук саклау органнарының, дәүләт хакимиятенең, муниципаль хакимиятнең тиешле органнарының һәм хокук саклау органнарының балаларның көчләүләрдән һәм аларга карата башка төр рәхимсезлекләр кылудан дәүләт тарафыннан яклануына гарантияләрне тәэмин итү эше дәвам ителергә тиеш.

Балаларны көчләүгә һәм аларга карата рәхимсезлек кылуга юл куймау максатларында Татарстан Республикасында балаларга карата җинаятьләр кылуны профилактикалау һәм көчләү корбаннары булган балаларны яклау буенча чаралар комплексын күрү зарур дип саныйм.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына балаларга карата рәхимсезлекләргә каршы тору, көчләүләрнең булырга тиеш түгеллеге турында халыкка аңлату буенча, баланы көчләгән һәм аңа карата рәхимсезлек кылган өчен җаваплылык турындагы, балаларның үзаңын һәм аларда үз-үзләрен яклауны, үз-үзләре белән горурлануны арттыру буенча; балаларга һәм гаиләләргә ярдәм күрсәтә торган төрле социаль хезмәтләр эшчәнлеге турындагы мәгълүмат кампанияләрен даими уздыру хакындагы мәсьәләне даими карарга. Шулай ук белгечләрне көчләүләрдән зыян

күргән балаларга ярдәм итү, мондый очраклар билгеле булганда чаралар күрү буенча күнекмәләргә өйрәтүгә, шулай ук ирексезләүләрне профилактикалау буенча инициативаларга ярдәм күрсәтүгә җитди игътибар бирергә кирәк;

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы, Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән берлектә хәтәр төркемгә караган балаларга үз вакытында һәм тиешле дәрәҗәдәге психологик ярдәм күрсәтү һәм мониторинг нәтиҗәләрен тикшерүче органнарга һәм оешмаларга тапшыру максатларында психологик хезмәтләр белгечләренең һөнәри квалификация дәрәҗәсен камилләштерү һәм арттыру буенча чаралар күрергә кирәк.

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына республиканың мәгариф оешмаларында конфликтлы очракларны хәл итүнең профессионал һәм нәтиҗәле алымнарын эшләү һәм куллану, мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан укучыларга тәрбияви йогынты ясауның балаларны суицид кылуга этәрергә мөмкин рөхсәт ителмәгән алымнарын куллануларын булдырмау буенча чаралар күрергә кирәк;

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләрне профилактикалау максатында женси кагылгысызлыкка каршы җинаять кылган өчен административ күзәтчелектә торган затларга карата мәгълүматны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль (шәһәр) комиссияләре адресына вакытында тапшыру эшен төгәл оештыру сорала;

Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр буенча тикшерү чараларын башкарганда тиешле органнарның – балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының балалар проблемаларын профилактикалау буенча үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә башкару мәсьләсе буенча эшләренә (эшләмәүләренә) хокукый бәя бирергә;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә, башка органнарга – балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларына түбәндәгеләр буенча чаралар күрүне көчәйтергә:

проблемалы гаиләләрдә яшәүче, административ күзәтү астында булган кешеләр, аналары белән бергә яшәүче ирләре булган гаиләләрдә яшәүче хәтәр төркемгә кергән балаларны ачыкларга;

игътибар, контроль, ведомство һәм ведомстводан тыш объект булган гаиләләрдә яшәүче хәтәр төркемгә кергән балаларга карата җинаять кылуларны булдырмаска.

Көчләү корбаннары булган балаларны тернәкләндерүне оештыру һәм үз вакытында үткәрү бүгенге актуаль проблемаларның берсе, дип уйлыйм. Кызганычка каршы, минем тәкъдимнәрем әйтелгән булса да, бүгенге көнгә республикада рәхимсезлекләргә дучар булган балаларны социаль-психологик тернәкләндерүнең нинди дә булса булыша торган системасы булдырылмаган. Ә бит мондый хезмәтнең күрсәтелүе балага карата кылынган һәр рәхимсезлек очрагында бик кирәк.

3.1.3. Тискәре мәгълүматтан яклау хокукын тәэмин итү

Мәгълүмат алу теләге кешенең табигатьтән бирелгән төп ихтыяҗларының берсе булып тора. Кеше, шәхес буларак, мәгълүмат чолганышында тәрбияләнә һәм формалаша.

Күптән түгел генә баланың тирә-юнендәге мәгълүмат ата-аналар һәм укытучылар тарафыннан җайга салына һәм бала, кирәк очракта, тискәре мәгълүматтан җиңел генә яклана ала иде. Соңгы 15 – 20 ел эчендә мәгълүмат кыры бик зур үзгәрешләр кичерде. Бүген балаларның үсеше, белем алуы, аларны тәрбияләү һәм социаль мохиткә яраклаштыру гипермәгълүматка ия җәмгыять шартларында бара. Шик тә юк, бүгенге көндә мәгълүмат кыры дигәндә, иң элек, замана баласының һәрьяклы үсеше өчен кирәк булган куәтле белем бирү, танып белү, күңел ачу ресурсы күз алдына килә. Шул ук вакытта, мәгълүмат технологияләренең зур тизлекләрдә үсүе балаларны һәм яшьләрне безнең җәмгыять өчен яңа булган, аларның физик, психик, әхлакый һәм рухи үсешенә тискәре йогынты ясарга һәм аны имгәтергә сәләтле шартларга куйды.

Социаль мохиткә традицион институтлар (гаилә, мәктәп) ашаяраклаштыру процессы актив рәвештә тулыландырыла бара, ә кайчакта аларны массакүләм мәгълүмат чаралары һәм яңа массакүләм коммуникацияләр, беренче чиратта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре алмаштыра.

Бүген балаларны һәм яшьләрне чолгап алган мәгълүмат кыры дигәндә балалар һәм яшьләр мәгълүмат ала торган барлык социаль каналларның берлеген күз алдында тотарга кирәк. Балалар өчен мәгълүмат алу чыганаклар булып бүген түбәндәгеләр санала:

массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясе (ТВ, радио, басма һәм интернет-ММЧ);

басма продукция (кибетләрдәге китаплар, китапханә);

төрле чыганаклардагы аудио-визуаль продукция (дисклар, флешкалар);

тамаша чаралары аша таратыла торган мәгълүмат (театр, мәдәни-агарту, күңел ачу: концертлар, кино, спектакльләр);

хәрәкәттәге радиотелефон элемтәсе аша тарала торган мәгълүмат;

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша тарала торган мәгълүмат.

«Интернет» челтәре — иң глобаль, шул ук вакытта мәгълүмат урнаштыру ягыннан да, балаларның мондый мәгълүматтан файдалануы ягыннан да контрольдә тоту иң кыен булган чыганак. Планшет компьютерлар һәм смартфоннар кебек чыбыксыз электрон җайланмалар таралуга бәйле рәвештә «Интернет» челтәренә керү фактта контрольдә тотып булмаслык дәрәҗәгә җитте. Ата-аналарның һәм балалар белән эшләүче белгечләрнең заманча гаджетлар белән эшләгәндә түбән компетенцияле булуы әлеге мәгълүмат чыганагын контрольдә тотуны тагын да кыенлаштыра.

Шуңа өстәп, нәкъ менә «Интернет» челтәре бүгенге көндә законга каршы килә торган контентның төп чыганагы булып тора. Балаларның һәм яшүсмерләрнең медиафайдалануын анализлау буенча Роскомнадзор белешмәләре күрсәткәнчә,

9 – 16 яшьлек балаларның кимендә өчтән бере челтәрдә сексуаль характердагы материаллар белән танышкан;

11 – 16 яшьләрдәге һәр икенче бала физик сәламәтлеккә куркыныч янауны, көч куллануны пропагандалау һәм расачылык турында мәгълүмат алган;

мәктәп укучыларының өчтән беренә «Интернет» челтәре аша сексуаль характердагы хәбәрләр килгән;

Һәрбер унынчы бала кибербуллингка (виртуаль өндәү, кибермохитнең куркыныч агрессиясе) тап булган.

Балаларны суицидларга һәм үзенең гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерә торган гамәлләргә өндәүче интернет-контент, шулай ук, актуальлеге буенча беренче планга чыга торган тагын бер җитди куркыныч булып тора.

Балаларны тискәре мәгълүматтан саклау проблемасы, иң беренче чиратта, норматив-хокукый яктан җайга салуны таләп итә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, балаларны мәгълүмати иминлек белән тәэмин итү – гомумтанылган халыкара хокук. Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенең 13 һәм 17 статьялары нигезендә дәүләт

балаларның һәрьяклы тулы хокуклы үсеш өчен кирәкле мәгълүмат алу хокукын тәэмин итү белән беррәттән, аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерергә сәләтле мәгълүматтан файдалана алуларына тиешле чикләүләр дә кертергә тиеш.

Мәсәлән, Бала хокуклары турында БМО конвенциясенең 13 статьясы нигезендә, бала үз фикерен ирекле әйтеп бирергә хокуклы; бу хокук төрле төрдәге мәгълүматны һәм фикерләрне, кысаларга кертмичә, телдән, язмача яисә бастырылган килеш, сәнгать әсәре рәвешендә яисә, баланың теләге буенча, башка чараларны кулланып эзләү, алу һәм тапшыру хокукы бирә.

Бу хокукны гамәлгә ашыруга кайбер чикләүләр булырга мөмкин, ләкин алар законда каралган һәм кирәкле булырга тиеш:

а) башка затларның хокукларын һәм абруен хөрмәт итү өчен;

б) дәүләт иминлеген, җәмәгать тәртибен (ordre public), сәламәтлекне, халыкның әхлагын саклау өчен.

Бала хокуклары турында БМО Конвенциясенең 17 статьясы нигезендә, бу Конвенциядә катнашучы дәүләтләр массакүләм мәгълүмат чараларының мөһим урын тотуын аңлыйлар һәм балага төрле милли һәм халыкара чыганаклардан мәгълүмат алу, аеруча социаль, рухи һәм әхлакый бөтенлеккә, шулай ук баланың физик һәм психик сәламәт булуына юнәлдерелгән мәгълүмат алу мөмкинлеген тудыралар. Шул максаттан чыгып, Конвенциядә катнашучы дәүләтләр

а) социаль һәм мәдәни яктан бала өчен файдалы һәм 29 статья таләпләре исәпкә алынган мәгълүмат тараткан өчен һәм материаллар бастырган өчен массакүләм мәгълүмат чараларын билгеләп үтәләр;

б) мондый мәгълүматны һәм материалларны төрле мәдәни, милли һәм халыкара чыганаклардан табып әзерләү, аларны алмашу һәм тарату өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне билгеләп хуплыйлар;

в) балалар әдәбияты чыгаруны һәм таратуны билгеләп үтәләр;

г) нинди дә булса аз санлы милләт яисә җирле халык вәкиле булган баланың телгә булган ихтыяҗына массакүләм мәгълүмат чараларының аеруча игътибар бирүен билгеләп үтәләр;

д) баланы аның иминлегенә зыян китерә торган мәгълүматтан һәм материаллардан яклау буенча кирәкле принципларны эшләүне хуплыйлар.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясенең илкүләм законнары күпмедер дәрәҗәдә формалашты һәм 2012 ел ахырыннан гамәлгә керде.

Балаларны аларның сәламәтлегенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында Россия Федерациясе законнары федераль законнар нормалары белән чикләнә.

«Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 436-ФЗ номерлы Закон) балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп норматив хокукый акт булып тора. Әлеге законның норматив нигезләмәләре 2012 елның 1 сентябреннән гамәлгә керде. Закон балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала. Аның гамәли көче Россия Федерациясе территориясендә алда телгә алынган барлык чыганакларның продукцияләре әйләнеше өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә кагыла.

Балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы белән расланган 2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләр кылуның илкүләм стратегиясендә балалар мәнфәгатендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләренең берсе буларак балаларны мәгълүмати иминлек белән тәэмин итү каралган.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 2 декабрендәге 2471-р номерлы күрсәтмәсе белән кабул ителгән Балаларның мәгълүмати иминлеге концепциясе (алга таба – Концепция) иң соңгы кабул ителгән норматив хокукый актларның берсе булып тора. Концепциядә балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итүнең төп принциплары, бу өлкәдә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның өстенлекле бурычлары һәм механизмы билгеләнгән.

Шулай да, интернетның куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә төп закон акты булып «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон санала. Катгый әһәмияткә ия булган тагын бер закон буларак «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 28 июлендәге 139-ФЗ номерлы Федераль закон карала. «Интернеттагы кара исемлекләр турында» закон кабул итү, кайбер тәнкыйтьчеләр һәм скептиклар фикеренчә, Рунетның эшләвенә куркыныч тудырырга тиеш иде. Әлеге законны гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 октябрендәге 1101 номерлы карары белән расланган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге домен исемнәренең, сайтларга күрсәткечләрнең Россия Федерациясендә таралуы тыелган мәгълүмат урнаштырылган «Интернет» челтәре сайтларын танырга мөмкинлек бирә торган бердәм реестры» автоматлаштырылган бердәм мәгълүмат системасын булдыру, формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре (алга таба – Бердәм реестр) һәм Россия Феде-

рациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органнарының Россия Федерациясендә тарату тыелган, ләкин «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша таратыла торган аерым төр мәгълүматка һәм материалларга карата карарлар кабул итү кагыйдәләре барлыкка килде. Әлеге норматив хокукый актлар бүгенге көндә гамәлдә булган һәм «Интернеттагы яман мәгълүматларны кисеп ташлый торган скальпель» ролен башкаручы Бердәм реестрның эшләү тәртибен регламентлаштыра.

Балаларны тискәре мәгълүматтан саклау буенча төп гамәлләрнең берсе **балалар-яшьләр мохитенә массакүләм мәгълүмат чаралары аша зарарлы контент үтеп керә торган мәгълүмат каналларын ябуның** хокукый механизмнарын булдырудан гыйбарәт. Бүген балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында Россия Федерациясе законнарының үтәлешен үз компетенцияләре чикләрендә тикшереп торучы дәүләт органнарының аерым бер системасы барлыкка килде:

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) Бердәм реестрны формалаштыра һәм алып бара, балигъ булмаганнарның порнографик сыннары төшерелгән «Интернет» челтәре аша тарала торган материалларда һәм (яисә) порнографик характердагы тамаша чараларында балигъ булмаганнарны башкаручы буларак катнашырга җәлеп итү турында белдерүләрдә тыелган мәгълүмат булу-булмау турында; «Интернет» челтәре аша таратыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясендә наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның прекурсорларын ясау, әзерләү һәм куллану ысуллары, мондый чараларны, матдәләрне һәм аларның прекурсорларын сатып алу урыннары турында, составында наркотик матдә булган үсемлекләрне үрчетү ысуллары һәм урыннары турында карарлар кабул итә;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы «Интернет» челтәре аша таратыла торган мәгълүматта наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның прекурсорларын ясау, әзерләү һәм куллану ысуллары, мондый чараларны, матдәләрне һәм аларның прекурсорларын сатып алу урыннары турында, шулай ук составында наркотик матдә булган үсемлекләрне үрчетү ысуллары һәм урыннары турында карарлар кабул итә;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт (Роспотребнадзор) «Интернет» челтәре аша таратыла торган мәгълүматта үз-үзеңә кул салу ысуллары, үз-үзеңә кул салырга өндәүләр турында тыелган мәгълүмат булу-булмау турында карарлар кабул итә;

Федераль салым хезмәте (РФ ФСХ) «Интернет» челтәре аша таратыла торган мәгълүматта «Интернет» челтәрен һәм башка элемтә чараларын кулланып, «Комарлы уеннар оештыруны һәм үткәрүне дәүләт җайга салуы турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон таләпләрен һәм «Лотерея турында Федераль закон таләпләрен боза торган тыелган мәгълүмат булу-булмау турында карарлар кабул итә;

мәгариф һәм фән өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү функцияләрен башкара торган федераль башкарма хакимият органы (Рособрнадзор) (балаларны зарарлы мәгълүматтан яклау өлкәсендәге таләпләрнең уку-укыту процессы кысаларында үтәлеше өлешендә);

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау өлкәсендәге РФ законнары таләпләре үтәлешен барлык төрдәге чыганакларда аудио-визуаль продукциягә караган мәгълүмат продукциясе, шулай ук тамаша чаралары аша таратыла торган мәгълүмат продукциясе әйләнешендә, шулай ук китапханә эшен оештырганда дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыра.

Тискәре йогынты ясый торган интернет-контентны туктату буенча чаралар күрү вәкаләте бүген бары тик федераль дәүләт хакимияте органнарына гына бирелгән һәм ул Бердәм реестр автоматлаштырылган бердәм мәгълүмат системасы кысаларында башкарыла. Бу функцияләрне үтәү өчен Роскомнадзорның рәсми сайтында (https://rkn.gov.ru/) «Интернет» челтәрендәге сайтларда, социаль челтәрләрдә тыелган мәгълүмат булуы турында мөрәҗәгатьләр кабул итү өчен интерактив

форма:урнаштырылган.

Мөрәҗәгатьләр дәүләт органнарыннан, муниципаль органнардан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән, һәм, шулай ук физик затлардан да булырга мөмкин.

Роскомнадзорга мөрәҗәгатьләр кергәннән соң бер тәүлек эчендә электрон рәвештәге тиешле запрос, югарыда телгә алынган компетенция нигезендә, вәкаләт бирелгән федераль органнарга җибәрелә. Мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карар тәүлек эчендә Роскомнадзорга тапшырыла

Хокукка каршы килә торган мәгълүматның булуы расланган очракта, аны юкка чыгару буенча эш башлана. Хостинг хуҗасы мәгълүматны бетерми икән, бу ресурсны туктату механизмы эшли башлый.

Тәжрибәдән чыгып шуны әйтергә була, интернет-ресурсларга законга каршы килә торган мәгълүматлар урнаштыруны булдырмау процедураларын оператив һәм нәтиҗәле итеп башкаруга омтылу төрле каршылыклар китереп чыгара.

Мәсәлән, Роскомнадзор белешмәләре буенча, 2016 елның июненә алар адресына кергән 270 000 мөрәҗәгатьтән, вәкаләтле органнар тарафыннан каралганнан соң, бу хакта Бердәм реестрга «наркотикларның законсыз әйләнеше», «балалар порнографиясе», «суицидка өндәү», «комарлы уеннар» һ.б категорияләр буенча 121 500 язу теркәлгән. Провайдерларга мөрәҗәгать иткәннән соң, алар тарафыннан 93 550 ресурстан хокукка каршы килә торган мәгълүмат алынган, калган 27 950 ресурс «Интернет» челтәренә керү хокукы бирү хезмәтләре күрсәтә торган элемтә операторлары тарафыннан туктатылган. Икенче төрле әйткәндә, мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән ресурсларның яртысында гына зарарлы мәгълүмат юкка чыгарылган. Моннан тыш, Татарстан Республикасы прокуратурасы мәгълүматлары буенча, республика прокуратура органнары тарафыннан «I.C.M Интернетта хокук бозуларга каршы система» мәгълүмат-аналитика комплексы ярдәмендә ачыкланган тыелган мәгълүмат урнаштырылган интернет-битләрнең бары тик 5 104, яисә 7 %ы гына Бердәм реестрга кертелгән һәм Роскомнадзор таләбе буенча юкка чыгарылган.

Мондый вәзгыять балаларның хокукларын, мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм «Интернет» челтәрендәге тискәре контенттан яклау буенча гамәлдәге механизмнарның җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмавын, балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итүнең бүгенге системасының «Интернет» челтәре һәм мәгълүмат технологияләре үсешенә бәйле хәвефләргә, хокукка каршы килә торган арта баручы контентка туры килмәвен раслый. Болар барысы да **«Интернет» челтәрендә тискәре контентны юкка чыгаруның гамәлдәге тәртибенә, аны камилләштерү, нәтиҗәлелеген һәм оперативлыгын арттыру максатларында, үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карауны таләп итә.**

Моннан тыш, мәгълүмати иминлекне тәэмин итү өлкәсендә гамәлдәге законнарның һәм хокук куллануның башка җитешсез яклары да бар:

балаларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматның төрләре исемлеген төгәлләштерергә кирәк. Бүген, аерым алганда, әлеге исемлеккә балаларның психоэмоциональ хәленә тискәре йогынты ясый торган монстр уенчыклар кертелмәгән. Шулай итеп, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары балаларны уеннар һәм уенчыклар аркылы бирелә торган мәгълүматтан яклауны гарантияләми. Шул ук вакытта, уеннар һәм уенчыклар баланың сәламәтлегенә һәм психик яктан үсешенә төзәтеп булмаслык зарар китерә (куркыныч уенчыклар: монстрлар, табуттагы курчак «мәетләре», болар балада курку, паника, патологик некрофиль кызыксыну уятырга мөмкин). Моннан тыш, 436-ФЗ номерлы Закон сувенир продукциясенә һәм баланың көнкүрешендә

кирәкле предметларга кагылмый, ә аларга исә, еш кына, эротик характердагы наркотиклар куллану атрибутикалары (марихуана рәсеме) урнаштырыла. Бу бигрәк тә төрле аксессуарларга, балалар сумкаларына, косметичкаларга, һ.б хас;

мәгълүмат продукциясенең законда беркетелгән «яшь» классификациясен һәм аңа тиешле тамга куюны гамәлдә куллану проблемасы бар, мәгълүматның кайсы яшь төркеме өчен булуын хәл итү бүген җитештерүчеләргә һәм продукцияне таратучыларга тапшырылган, алар исә балалар өчен хәвефне һәрвакытта да аңлап бетермәскә мөмкин.

Мәгълүмат продукциясен таратучыларның бу продукция адреслангән яшь категориясен киметеп яисә арттырып күрсәтүе иң нык таралган хокук бозуларның берсе. Яшьне киметеп күрсәтү балаларга сәламәтлеккә һәм үсешкә зыян китерә торган мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлеге бирә;

бүген балалар өчен тыелган мәгълүмат урнаштырган өчен юридик җаваплылык (аның хокукка каршы килүен тану) каралмаган. Мәсәлән, беренче ике категориягә керә торган мәгълүматның - «балигъ булмаганнарның порнографик сыннары төшерелгән «Интернет» челтәре аша тарала торган материалларда һәм (яисә) порнографик характердагы тамаша чараларында балигъ булмаганнарны башкаручы буларак катнашырга җәлеп итү турында белдерүләрдә тыелган мәгълүмат урнаштыру» һәм «наркотик чараларны, психотроп матдәләрне һәм аларның прекурсорларын ясау, әзерләү һәм куллану ысуллары турында мәгълүмат урнаштыру» гамәлләренең хокукка каршы килүе турында Россия Федерациясе Җинаять кодексында (242.1 һәм 242.2 статьялар) һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында (6.13 статья) билгеләнсә дә, суицидка өндәү федераль законнарда тыелган мәгълүмат булып саналмый. Шул уңайдан Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына үзгәрешләр кертү юлы белән бу кимчелекне бетерергә кирәк дип саныйм. Мондый мәгълүматларның (суицидларга өндәү һәм аларны пропагандалау) иҗтимагый куркынычлылык дәрәҗәсенә туры килә җаваплылык - җинаять җаваплылыгы булырга тиеш. Шуңа бәйле рәвештә Россия Федерациясе Җинаять кодексына үз-үзен үтерүгә пропагандаланган яисә бу гамәлнең ысулларын тараткан өчен җаваплылык билгеләү турындагы нигезләмәләр өстәргә тәкъдим ителә.

Балаларның мәгълүмати иминлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтенең тагын бер җитди өстенлекле бурычы балаларның һәм яшүсмерләрнең медиагыйлемен арттырудан, аларда мәгълүмат кырында кылган гамәлләре өчен җаваплылык хисе булдырудан, танып-белү ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән, десоциальләшү куркынычын, яшүсмерләрнең девиант һәм хокукка каршы гамәлләрен бетерүдән гыйбарәт.

Бары тик тыю гамәлләрен генә кулланып, балаларны алар өчен куркыныч булган һәм арта барган куркынычлардан саклап калып булмый. Балаларны һәм яшүсмерләрне мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат чолганышында имин яшәргә өйрәтергә кирәк. Ләкин әлеге бурычны гамәлгә ашыру бик авыр, чөнки үзенчәлекле механизмнар эшләү һәм балалар белән эшчәнлекнең яңа алымнарын булдыру таләп ителә.

Киберкуркынычсызлык дәрәҗәсен арттыру, «Интернет» челтәрендә балаларның иминлеге проблемасына ата-аналарны һәм педагогларны җәлеп итү һәм мәктәп балаларының санлы грамоталылыгын арттыру максатларында, 2016 елда 27 – 30 октябрьдә үткәрелгән мәгълүмат иминлеге буенча бердәм республика дәресе кысаларында балалар белән әлеге темага сөйләшүнең беренче адымнары ясалды. Республиканың 1 324 мәктәбендә (гомуми саның 98,9 %ы), 72 % укучылар һәм 46 % ата-аналар төрле тематик чараларда катнашты. «Интернет» челтәрендә иминлек дәресе турында мәгълүмат Докладның 1.7 бүлегендә бәян ителде.

Имин мәгълүмат пространствосын булдыру өлкәсендә тагын бер мөһим юнәлеш булып ата-аналарны медиаагарту эшләре тора. Ата-аналар балалары «яши» һәм «кереп йөри» торган параллель, виртуаль дөнья турында мәгълүматлы булырга, балаларны сагалап торучы хәвефләр хакында белергә, ярдәм, яклау, киңәш кирәк очракта алар белән янәшә булырга тиеш.

Сүз дә юк, алда язылган ике бурычны гамәлгә ашыру өчен медиаиминлек өлкәсендә балалар белән эшләүче педагогларның һәм башка белгечләрнең компетенция дәрәҗәсен арттырырга кирәк.

Татарстан Республикасында балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүгә бәйле хәвефләрдән яклау системасының торышы мәсьәләсе хакында республика дәрәҗәсендә фикер алышу өчен 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме белән 2016 елның 30 маенда Казан шәһәрендә Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау буенча республика форумы уздырылды (алга таба – Форум).

Форум кысаларында төп акцент түбәндәгеләргә ясалды:

имин һәм позитив мәгълүмат мохите булдыру буенча тәкъдимнәр эшләүгә;

балаларны һәм ата-аналарны медиаиминлек нигезләренә өйрәтүгә;

балаларда интернетка бәйлелекне һәм химик булмаган башка төр бәйлелекләрне профилактикалауга;

балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) физик, психик, рухи, әхлакый үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау өлкәсендә җәмәгатьчелекнең, коммерциячел оешмаларның роленә.

Форум турында мәгълүмат Докладның 1.5 бүлегендә бирелде.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, балаларның мәгълүмати иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар кабул итәргә кирәк дип саныйм.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәм:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 2 декабрендәге 2471-р номерлы күрсәтмәсе белән кабул ителгән Балаларның мәгълүмати иминлеге концепциясе нигезләмәләрен исәпкә ала торган республика программасын эшләү мәсьәләсен карарга;

Мәгълүмати иминлек турында гамәлдәге законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү турындагы мәсьәләне карарга.

3.2. Баланың сәламәтлек саклауга һәм үсешкә хокукын тәэмин итү

Баланың сәламәтлеге аның тормышы камил һәм тулы хокуклы булуның төп нигезе. Балаларга күрсәтелә торган медицина хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеген, бу хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуны, төрләрен арттыруны тәэмин итүгә, балаларга медицина ярдәме күрсәтүне заманча тәртипләр һәм стандартлар нигезендә үтемле оештыруга һәм медицина технологияләрен кертүгә, балаларны дарулар, махсус дәва продуктлары, медицина әйберләре белән тәэмин итүне оештыруга, балаларга хезмәт күрсәтә торган наркология хезмәтен үстерүгә, балаларны сыйфатлы туклану белән тәэмин итү системасын камилләштерүгә, балаларны һәм яшүсмерләрне ял иттерү һәм савыктыру системасын үстерүгә, мәгариф учреждениеләренең сәламәтлек саклау эшчәнлеген арттыруга нигезләнә торган заманча технологияләр – бала хокуклары турындагы конвенция нигезендә Россия федерациясе законнары белән беркетелгән гарантияләр яшь буынның сәламәтлеген саклау, аның сәламәт үсешен тәэмин итүне күздә тота.

3.2.1. Балалар үлеменә гомуми анализ

Берләшкән милләтләр оешмасының Бала хокуклары турында Конвенциясен ратификацияләү Россия Федерациясенә балаларның исән-имин яшәвен максималь тәэмин итү бурычын йөкли.

Бу өлкәдә балалар хокукларын гамәлгә ашыру торышын билгели торган төп критерий булып балалар үлеме дәрәҗәсе тора.


Әлеге бүлектә балалар үлемен анализлауның нигезен 2017 елның 1 мартына Татарстанстат һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек

саклау министрлыгы тарафыннан ясалган якынча (оператив) белешмәләр тәшкил итә.

2016 елда республикада балалар үлеме кимеде һәм 10000 балага 6,13 очракны тәшкил итте. Бу 2015 ел күрсәткеченә (6,76 очрак) һәм 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясен гамәлгә ашыру индикаторларына (10000 балага 7,9 очрак) караганда түбәнрәк. 2016 елда барлыгы 473 бала үлде, бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 40 балага кимрәк.

62 диаграмма

2013 – 2016 елларда Татарстан Республикасында балалар үлеме *(кеше)*




Балалар үлеме структурасы бик катлаулы. Ул, нигездә, үлемнең сәбәпләренә һәм үлгән балаларның яшенә бәйле.

Балалар үлеменең яшь буенча бүленеше, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә нигезләнеп, түбәндәге диаграммада бирелә.

63 диаграмма

2013 – 2016 елларда балалар үлеменең яшь буенча бүленеше



Соңгы дүрт елда балалар үлеменең сәбәпләре түбәндәге таблицада бирелә.

15 нче таблица


2013–2016 елларда балалар үлеменең сәбәпләре

Сәбәпләр	2013 ел, кеше	Өлеш, %	2014 ел, кеше	Өлеш %	2015 ел, кеше	Өлеш, %	2016 ел, кеше	Өлеш, %
Авыру	**468**	77,3	**483**	81,7	**427**	83	**384**	82
Башка сәбәпләр	**137**	22,6	**108**	18,2	**84**	16,4	**84**	18
Барлыгы	**605**		**591**		**513**		**473**	

Балалар үлеменең иң зур өлеше ***сабыйлар үлеменә*** туры килә: 2013 елда – 65 %, 2014 елда – 62 %, 2015 елда – 66 %, 2016 елда – 63 %. Сабыйлар үлеме дәрәҗәсе – демографик күрсәткечләрнең халык үлеме дәрәҗәсен билгели торган төп статистик мәгълүматларының берсе, ул 20 гасыр урталарыннан бирле илләрне халыкның тормыш дәрәҗәсе буенча классификацияләгәндә төп фактор булып санала. Шул ук вакытта бу саннар дәүләтнең балалар иминлеге өчен шартлар тудыру дәрәҗәсен дә күрсәтә. Хисап чоры күрсәткечләре буенча, республикада соңгы дүрт елда сабыйлар үлеме кимүнең уңай тенденциясе саклана. 2016 елда сабыйлар үлеме 13,4 процентка кимеде: бер яшькә кадәр 297 бала үлде, бу – исән туган 1000 балага 4,6 очрак.

64 диаграмма

2013–2016 елларда сабыйлар үлеме (бер яшькә кадәр)




Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы сабыйлар үлеме дәрәҗәсе буенча Россия Федерациясе (исән туган 1000 балага – 6,0) һәм Идел буе федераль округы (исән туган 1000 балага – 5,6) буенча уртача күрсәткечтән түбәнрәк урынны били.

Шулай ук *перинаталь үлем очракларының* кимүе игътибарны җәлеп итә, аны үле туган балалар һәм туганнан соң (иртә неонаталь үлем) 7 тәүлек булганчы үлгән балалар тәшкил итә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2016 елда перинаталь чорда барлыкка килә торган җитешсезлекләрдән 593 бала вафат булган,

2015 елның шушы чорына караганда 37 гә кимрәк. Бу – соңгы дүрт елдагы иң түбән күрсәткеч. Перинаталь үлем дәрәҗәсенең кимүе иртә неонаталь үлем очракларының 13 %ка (22 очрак) кимүе һәм үле туган балалар санының 4 %ка, яисә 14 очракка азрак булуы белән аңлатыла.

65 диаграмма

2013–2016 елларда Татарстан Республикасында перинаталь үлем



2013 – 2015 елларда перинаталь үлем очракларының күп булуына бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз чыгышларында бала табу учреждениеләрен структура һәм кадрлар белән тәэмин ителеш ягыннан камилләштерү, бу учреждениеләрне сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина ярдәме күрсәтүнең норматив таләпләренә туры китерү, сәламәтлек саклау учреждениеләренең реанимация койкалары һәм кирәкле белгечләр белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә туры китерү зарурлыгына басым ясаган иде.

2016 ел йомгаклары буенча вәзгыятьнең берникадәр яхшыруы күренә: сабыйлар үлеме, перинаталь үлем очраклары шактый кимеде, бу республикада күрелгән чараларның һәм кабул ителгән карарларның нәтиҗәсе булып тора. Мәсәлән, 2016 елның сентябрендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында Перинаталь үзәк ачылды һәм кулланылышка тапшырылды. Яңа туган балалар өчен реанимация койкаларының саны арттырылды. Алар109 га җитте (2013 елда – 95, 2014 елда – 104, 2015 елда – 98 койка). Шулай ук неонатологларның да саны бераз артты. 2016 елда бу өлкәдә 122 белгеч (2013 елда – 121 белгеч, 2014 елда – 122 белгеч, 2015 елда – 120 белгеч) эшләде.


Шулай итеп, 2016 елда бала табу учреждениеләре эшенең уңай булуын танырга кирәк. Шул ук вакытта яңа туган балаларга, бала табу учреждениеләрендә булган вакытта, югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтү республикада яңа туган балаларга медицина ярдәме күрсәтү системасында иң мөһим һәм иң четерекле тармакларның берсе булып кала һәм алга таба да камилләштерүне һәм үстерүне таләп итә.

3.2.2. Балалар сәламәтлеге торышына гомуми анализ

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләренә караганда, балигъ булмаганнарның сәламәтлеген даими рәвештә ел саен тикшерү балаларның сәламәтлеге торышын түбәндәгечә тасвирларга мөмкинлек бирде.

66 диаграмма

2013–2016елларда балигъ булмаганнарның сәламәтлеге торышын төркемнәргә бүлү



Югарыда китерелгән саннар күрсәткәнчә, медицина тикшерүе үткән балаларның гомуми саныннан күбесенең сәламәтлеге икенче төркемгә карый (2016 елда – 71,3 %), беренче төркемгә кергән балалар саны 15 %тан да артык түгел, өченче төркемгә керүче балалар саны 11 % тәшкил итә. Узган ел йомгаклары буенча дүртенче һәм бишенче төркемгә керүче балалар саны 2 %ка җитте.

Балалар авыруларын анализлау балигъ булмаганнарның сәламәтлеге торышын бәяләргә мөмкинлек бирә.

16 нчы таблица

2013 – 2016 елларда балаларда ачыкланган авырулар

2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел	2015 елга карата,%	Беренче тапкыр ачыкланган авырулар
101472	93247	99007	100447	+1,5%	Җәрәхәтләнүләр, агуланулар һәм тышкы сәбәпләрдән килгән кайбер башка зыяннар
25497	22780	25164	25865	+2,8%	Нерв системасы авырулары

3252	2778	3129	3012	-3,7%	Психик тайпылышлар һәм тәртипнең үзгә булуы (барлыгы)
	80	85	92	+8,2%	Шул исәптән, аутистик тайпылышлар
983	1140	1309	1207	-7,8%	Педикулез
	0	5	2	-60%	Сирәк (орфан) авырулар
686	364	348	255	-26,7%	Корчаңгы
85	100	100	107	+7%	Шешләр (яман шешләр)
104	134	161	157	-2,5%	I төр шикәр авыруы (инсулинга бәйлелек)
142	116	124	75	-39,5%	Вируслы гепатит
80	67	70	67	-4,3%	Туберкулез
64	55	45	44	-2,2%	Трихомоноз
56	19	11	34	+209%	Дизентерия
18	13	23	14	-39,1%	ВИЧ (барлык рәвешләре)
55	37	20	13	-35%	Гонокок инфекциясе
28	17	12	11	-8,3%	Сифилис (барлык рәвешләре)
14	8	4	7	+75%	Менингокок инфекциясе
2	3	3	2	-33,3%	Вакцинадан соң өзлегүләр

Авыруларны анализлаудан күренгәнчә, 2016 елда имгәнүләр, агуланулар һәм кайбер башка тышкы сәбәпләр аркасында балаларның авыру күрсәткече 2015 елның шундый ук күрсәткеченә караганда 1 440 очракка артты. Шулай итеп, 2016 елда 100 007 бала имгәнде, агуланды, башка сәбәпләр аркасында авырды (2015 елда – 99 007). Балаларның тышкы сәбәпләр аркасында авыруы идарә ителә торган авырулардан санала, шунлыктан әлеге нозология буенча булган очракларны киметү максатында профилактика эшенә зур игътибар бирергә кирәк.

Балаларда беренче тапкыр ачыкланган авырулар исемлегендә икенче урында тотрыклы рәвештә нерв системасы авырулары тора. Соңгы өч елда бу авырулар белән чирләү очраклары арта бара.

Балалар арасында психик тайпылышларның һәм тәртипнең үзгә булуы арту аеруча борчылу тудыра. Ел саен якынча 3 мең балада беренче тапкыр әлеге нозология авырулары ачыклана. Шулай ук аутистик тайпылышлары булган балалар саны да арта бара.

Сирәк очрый торган (орфан) авырулардан интегүче балалар саны кимеде.

2016 елда бу авыру билгеләре беренче тапкыр 2 балада табылды (2015 елда – 5 балада).

Ел саен 100 гә якын балада яман шеш авырулары, 150гә якын балада 1 төр шикәр авыруы табыла.

I төр шикәр авыруы

2016 елда балаларның корчаңгы, педикулез, туберкулез кебек социаль авырулары белән чирләү очраклары кимү дәвам итте.

Балаларның вируслы гепатит, ВИЧ (барлык рәвешләре) белән авырулары шулай ук кимеде.

Шул ук вакытта дизентерия табылган очраклар артты (23 кешегә), хисап елында әлеге авыру белән 34 бала чирләде.

Җиде бала менингококк инфекциясе белән авырды.


Вакцинадан соңгы өзлегү очраклары берничә тапкыр гына теркәлде.

Балигъ булмаганнарның җенси юл белән күчә торган инфекцияләр белән авыруы һәм балалар, яшүсмерләр арасында йөклелек очракларының артуы сәламәтлек саклауны камилләштерүгә һәм бу хәлләрнең социаль куркынычлылыгына аеруча игътибар бирүне таләп итә. Соңгы дүрт елда җенси юл белән күчә торган авыруларны **(сифилис, гонокок инфекциясе, трихомоноз) беренче тапкыр йоктырган** балаларның саны ел саен кими бара. Мондый авырулар белән чирләү очраклары сирәк күзәтелә.

Статистика мәгълүматлары балигъ булмаганнар арасында соңгы алты елда йөклелек очракларының тотрыклы рәвештә кимүен күрсәтә. Мәсәлән, 2016 елда ул (335), соңгы еллар белән чагыштырганда, бу юнәлештәге иң кечкенә күрсәткеч. 2011 ел белән чагыштырганда, йөккә узган кызларның саны ике тапкыр кимеде (2011 елда балигъ булмаганнарның йөклелеге 599 очракта, 2016 елда 335 очракта теркәлде).

67 диаграмма

2013–2016 елларда балигъ булмаганнар арасында йөклелек статистикасы



Балигъ булмаганнарның йөклелек очракларының 30 %тан артыгы аны өзү (аборт) белән төгәлләнә: 2015 елда 389 йөклелекнең 130 аборт белән тәмамланды, 2016 елда 335 йөклелекнең 105 аборт белән

тәмамланды. Балигъ булмаганнар арасында абортлар саны, йөклелек очракларына параллель рәвештә, кими бара (2013 елда – 189, 2014 елда – 141, 2015 елда – 125, 2016 елда – 103). Кызганычка каршы, балигъ булмаган кыз баланың аборт ясатуы туарга өлгерми калган нарасый гына түгел, ә кыз балаларның – булачак әниләрнең бала таба алу сәләтенә дә җитди куркыныч тудыра.

Югарыда китерелгән анализның республикада балигъ булмаганнар арасындагы йөклелек очраклары һәм балаларның венерик авырулар белән авыру очраклары динамикасының уңай үзгәрешен раславын танырга кирәк. Шулай да балалар тормышында мондый хәлләр булмасын өчен без профилактика эшен дәвам итәргә тиеш. Профилактика эшенең бер варианты буларак, балалар арасында агарту эшләре алып бару нәтиҗәле булыр иде. Аны республиканың гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Гаилә» дәресе кысаларында оештырырга мөмкин. Кызганычка каршы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, белем бирү учреждениеләренең әлеге эшчәнлек юнәлешендәге проблемалары, беренчедән, педагогларның әхлакый тәрбия, укучыларга җенси белем бирү мәсьәләләрендә һөнәри компетенцияләренең түбән дәрәҗәдә булуга, профилактика эшен оештыруда заманча интерактив технологияләрдән файдалана белмәвенә бәйле.

Моннан тыш, венерик авыру йоктырган яисә йөкле балигъ булмаганнар белән аралашканда һәрбер очракның җинаять – көчләү, җенси характердагы гамәлләргә мәҗбүр итү, уналты яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү булырга мөмкинлеген истә тотарга кирәк. Шуңа күрә сәламәтлек саклау, хокук саклау һәм балаларның сукбайлыгын профилактикалау органнары, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, балага һәрьяклап квалификацияле ярдәм күрсәтү, җинаять кылуда гаепле затларга җәза бирү, балага авыру йоктырган чыганакны белү һәм зарарсызландыру һәм киләчәктә бу хәлләр килеп чыкмасын өчен профилактик эш уздыру максатларында, дөрес хезмәттәшлек итәргә тиеш.

Балалар арасында наркомания һәм алкогольгә бәйлелек, социаль күренеш буларак, балалар сәламәтлеге өлкәсендә үзләренә аерым игътибар таләп итә торган тагын бер кискен проблема булып тора.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 11 февралендәге 90 номерлы карары белән расланган 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясендә (алга таба – Балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясе) балаларга хезмәт күрсәтүче наркология хезмәтләрен үстерү сәламәтлек саклау өлкәсендәге төп бурычларның берсе буларак карала.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, нарколог ярдәменә мохтаҗ балалар саны соңгы

дүрт елда 437 кешегә кадәр кимеде. Шул ук вакытта наркология ярдәме таләп ителә торган балаларның 69 %ы гына мондый ярдәм белән тәэмин ителә. Шуңа карамастан, мондый ярдәмне күрсәтә алырлык медицина оешмалары саны һәм балалар наркологлары кими бара.

17нче таблица

2013 – 2016 елларда балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтү

Күрсәткеч	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел
Нарколог ярдәменә мохтаҗ балалар саны	449	491	518	437
Наркология хезмәте белән тәэмин ителгән балалар саны	269	309	336	301
Балигъ булмаганнарга наркология ярдәме күрсәтү оештырылган медицина оешмалары саны, шул исәптән:	37	38	37	34
амбулатор	37	38	37	34
стационар	2	2	2	2
Балалар наркологлары (кеше/% тәэмин ителеш)	28/62%	26/57%	23/51%	21/46%

2016 елда гына да алкоголь куллана торган 284, наркотиклар куллана торган 82 балигъ булмаган ачыкланды.

Алкоголь һәм наркотиклар куллану, физик һәм психик сәламәтлеккә зыян китерүдән тыш, балалар һәм яшүсмерләр тарафыннан җинаятьләр кылуга, шулай ук үз-үзенә кул салу омтылышлары ясауга китерә.

Югарыда китерелгән белешмәләр бүгенге көндә Татарстан Республикасында балаларга нарколог хезмәте күрсәтүнең торышын тиешенчә дип бәяләргә мөмкинлек бирми, шуңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итү зарур дип саный:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты алкоголь һәм наркотик бәйлелектән интегүче балигъ булмаганнар өчен социаль-реабилитация үзәге булдыру мәсьәләсен карарга тиеш;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

Балаларга наркология ярдәме күрсәтү системасын үстерү мәсьәләсен карарга тиеш;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр белән бергәләп балигъ булмаганнарның наркотик чараларны һәм (яисә) психотроп матдәләрне медицинадан тыш куллану предметына профилактик медицина тикшерүләре буенча эшне активлаштырырга тиеш;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

җирлеүзидарәорганнарыбеләнберлектәмәгарифучреждениеләрендә, шулай ук һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга наркотик чараларны һәм (яисә) психотроп матдәләрне, башка агулы матдәләрне медицинадан тыш куллану предметына психологик тестлар үткәрүнең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары күргә тиеш;


наркотикларга каршы «Мөстәкыйль балалар» проектында катнаша торган балаларның һәм яшүсмерләрнең санын арттыру буенча эшне активлаштырырга кирәк.

Балалар сәламәтлеге торышын билгели торган критерийларның берсе – ***балаларның инвалидлык дәрәҗәсе.***

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе белешмәләренә караганда, 2017 елның 1 гыйнварына республикада 14 743 инвалид бала яши, бу барлык балаларның 1,8 %ы. 2015 ел белән чагыштырганда, бу саннар 226 кешегә кимеде (2015 елда инвалид балаларның гомуми саны 14 969 иде), бу мондый категориягә керә торган балалар санының бераз кимүен күрсәтә.

68 диаграмма

2012 – 2016 елларда Татарстан Республикасында инвалид балаларның гомуми саны




Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медик-социаль экспертиза баш бюросы» ФКУ (алга таба – Баш бюро) белешмәләре буенча, 2016 елда инвалидлык алу өчен 7 220 бала мөрәҗәгать иткән, бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 7,3 %ка кимрәк (2015 елда – 7 788 бала). Шуларның 6 256ы , яисә 86 %ы, инвалидлык алды (2013 елда – 7 919 бала, яисә 94,4 %, 2014 елда – 7 418 бала, яисә 91,4 %, 2015 елда – 6 623 бала, яисә 85 %).

Шулай итеп, 2016 елда инвалидлыкка тикшеренү узган балаларның 13,4 %ы инвалид дип танылмады (2014 елда – 8,6 %, 2013 елда – 5,6 %, 2015 елда – 15 %) бу 964 очракны (2013 елда – 470, 2014 елда – 696, 2015

елда – 1 165) тәшкил итә, шул исәптән 540 очракта, тулысынча терелүгә бәйле рәвештә, тикшеренү нәтиҗәсендә (2013 елда – 290, 2014 елда – 398, 2015 елда – 770) инвалидлык статусын кабат бирүдән баш тартылды.

69 диаграмма

2013 – 2016 елларда балаларга инвалидлык бирелү (бирелмәү) турында белешмәләр



Баланы инвалид дип танудан баш тарту турында чыгарылган 964 карарның 282сенә югарырак инстанцияләргә – Баш бюрога яисә «Федераль медик-социаль экспертиза бюросы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә (2013 елда – 76, 2014 елда – 149, 2015 елда – 293) шикаять белдерелде, бу гомуми каршы килүләрнең 29 %ын тәшкил итә. 264 очракта карар үзгәртелмәде (2013 елда – 66, 2014 елда – 143, 2015 елда – 285).

Балаларның инвалидлыгын танудан баш тартуның төп сәбәпләре түбәндәгеләр:


медик-социаль экспертизага җибәрү өчен медицина оешмалары белгечләре бәян иткән дәлилләрнең җитәрлек булмавы;

«Затны инвалид итеп тану тәртибе һәм шартлары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 20 февралендәге 95 номерлы карары белән расланган Затны инвалид итеп тану тәртибе кагыйдәләренең 6 пункты таләпләрен үтәмәү, әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән таләпләрнең кайсы да булса берсенең үтәлмәве.

Инвалид дип танылган балаларның гомуми саныннан 1 567 балага (25 %) «инвалид бала» категориясе беренче тапкыр бирелде, 4 689 баланың (75 %) инвалидлыгы кабат расланды.

70 диаграмма

2013–2016 елларда балалар инвалидлыгы күрсәткечләре



2016 елда беренче тапкыр инвалидлык алучылар 10 000 балага 19,7 кеше туры килә (2013 елда – 26,6; 2014 елда – 26,1; 2015 елда – 22,6). Инвалидлыгы кабат расланучылар 2016 елда 10 000 балага 58,9 кеше туры килә (2013 елда – 92,5; 2014 елда –71,6; 2015 елда – 62,6).

Югарыда китерелгән 2015 – 2016 еллардагы белешмәләрне анализлау күрсәткәнчә, хисап чорында түбәндәгеләрнең кимүе күзәтелде:

тикшеренүгә җибәрелгән балалар саны (7 % ка);

инвалид дип танылган балалар саны (5,5 % ка);

инвалидлыкны беренче тапкыр алган балалар саны (10,6 % ка);

инвалидлыгы кабат расланган балалар саны (3,7 % ка)

инвалидлык бирүдән баш тарткан балалар саны (1,6 %).

Инвалидлык алу өчен тикшеренү үткән балалар саны һәм инвалидлык бирелгән балалар саны кими бару белән бергә, 2013 елдан башлап беренче мәртәбә 2016 елда баланың инвалидлыгын танудан баш тартуларның гомуми саны да кимеде. Бу медик-социаль экспертиза үткәргәндә кулланыла торган классификацияләүнең һәм критерийларның камилләштерелгән вариантларын – организм функцияләренең бозылу дәрәҗәсен бәяләүне һәм балаларга инвалидлык бирүнең критерийларын тәгаенләштерә торган «Федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан гражданнарга медик-социаль экспертиза үткәргәндә кулланыла торган классификацияләр һәм критерийлар турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 17 декабрендәге 1024н номерлы боерыгын куллана башлауга да бәйле дип саныйбыз.

Шул ук вакытта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан медик-социаль экспертиза органнары карарларына шикаятьләр килү дәвам итте. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең медик-социаль экспертиза органнары карарларын тикшерергә вәкаләте


булмавын истә тотып, чыгарылган карарларны тагын бер тапкыр карау мөмкинлеге һәм медик-социаль экспертиза органнары карарларына шикаять белдерүнең билгеләнгән тәртибен мөрәҗәгать итүчеләргә аңлату хакында Баш бюро җитәкчесе Р.Х. Низамовка мөрәҗәгать җибәрелде.

Балаларны беренче тапкыр инвалид дип тану аерым игътибар таләп итә.

Республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча беренче тапкыр инвалид дип танылган балалар саны 71 диаграммада күрсәтелде.

71 диаграмма

2016 елда республика муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча балаларның беренче тапкыр инвалид дип танылу дәрәҗәсе (10000 балага)




Татарстан Республикасы Мөслим (32,8), Алексеевск (32,4), Әгерҗе (31,9), Теләче (31,3) һәм Кама Тамагы (31,2) муниципаль районнарында беренче тапкыр инвалид булу дәрәҗәсе югары. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Мөслим һәм Кама Тамагы муниципаль районнарында шундый хәл өченче ел рәттән, ә Теләче муниципаль районында алтынчы ел рәттән сакланып кала. Шулай да Мөслим муниципаль районында 2016 елда беренче тапкыр инвалид дип танылган балалар саны бераз (56,7 дән 32,8 гә) кимеде – 10 000 балага 32,8 тәшкил итте.

Югарыда китерелгән белешмәләр чыгып, сәламәтлек саклау учреждениеләре Баш бюро белән берлектә күрсәтелгән районнарда балалар инвалидлыгы буенча барлыкка килгән хәлне бетерү буенча чаралар комплексы эшләү һәм кабул итү максатларында балаларның инвалидлыгын, аңа китергән сәбәпләрне һәм шартларны җентекләп анализларга тиеш дип саныйбыз.

Беренче тапкыр инвалид булып танылган балалар яшь төркемнәре буенча түбәндәгечә бүленде.

72 диаграмма

2013 – 2016 елларда балаларны беренчел тикшерү белешмәләре (яшь категорияләре буенча)



Югарыда китерелгән белешмәләр күрсәткәнчә, соңгы дүрт елда тикшерү нәтиҗәләре буенча инвалидлык беренче тапкыр билгеләнгән иң күп очрак 3 яшькә кадәр булган балалар арасына туры килә.

2016 елда балалар инвалидлыгының башлангыч сәбәбе булган авырулар структурасын анализлау түбәндәгеләрне күрсәтә.

18 нче таблица

2013 – 2016 елларда балаларның беренчел инвалидлыгының авыру төрләре буенча структурасы (кеше)

Авыру төрләре	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел
Психика какшау һәм үз-үзен таркау тоту	368	440	445	471
Нерв системасы авырулары	350	356	350	312
Тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы	464	475	335	198
Эндокрин система авырулары, туклану һәм матдәләр алмашы бозылу	138	163	149	167
Шешләр	74	93	84	83
Күз һәм күрү аппараты авырулары	111	81	82	71
Колак авырулары	57	55	65	69
Сөяк-мускул һәм тоташтыргыч тукыма-лар авырулары	90	107	72	53
Сидек юллары һәм җенес органнары авы-рулары	40	36	26	26
Җәрәхәтләр, агуланулар һәм башка тыш-кы сәбәпләр	53	31	19	25

Перинаталь чорда барлыкка килә торган авырулар	12	20	23	16
Кан ясау системасы авырулары	22	17	16	15
Ашкайнату органнары авырулары	23	19	18	12
Сулыш органнары авырулары	39	23	13	8
Туберкулез	1	1	1	2
Барлыгы	1947	1982	1754	1567

Соңгы елларда балаларның инвалидлык структурасында беренче урынны психик яктан какшау һәм үз-үзен таркау тоту алып тора. Башка еллардагы кебек үк,

әлеге күрсәткеч буенча үсеш югары темпта бара: 2016 елда 471 кеше, яисә 2015 елга караганда 26 кешегә артык балага инвалидлык бирелде. Моннан тыш, югарыда әйтеп үтелгәнчә, психик яктан какшау һәм үз-үзен таркау тоту ел саен 3 меңгә якын балада ачыклана. Шуңа карамастан, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада балалар психиатрлары белән тәэмин ителеш 19 белгечне (2013 елда – 17 белгеч, 2014 елда – 17 белгеч, 2015 елда – 15 белгеч), балалар психотерапевтлары белән тәэмин ителеш – 2 белгечне (2013 елда – 1 белгеч, 2014 елда – 2 белгеч, 2015 елда – 2 белгеч) тәшкил итте. **Әлеге вәзгыять, психика какшаудан интегүче балаларның квалификацияле һәм һәркем файдалана алырлык психиатр ярдәме белән тәэмин ителеше күзлегеннән чыгып караганда, җентекләп анализ ясауны һәм кадрлар белән тәэмин итү буенча карарлар кабул итүне таләп итә.**

Икенче урынны, гадәттәгечә, нерв системасы авырулары алып тора, бу юнәлештәге интенсивлык күрсәткече 10 мең балага 3,9 тәшкил итә.

Тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы өченче урынны били, интенсивлык күрсәткече 10 мең балага 2,5 тәшкил итә. Шулай ук әлеге сәбәпләр аркасында беренче тапкыр инвалидлык алган очракларның шактый кимүе игътибарны җәлеп итә: 2015 елда 335 очрак булса, 2016 елда – 197 очрак.

Ел йомгаклары буенча дүртенче урынны туклану бозылу һәм матдәләр алмашу бозылу аркасында килеп чыга торган эндокрин системасы авыруларына бәйле рәвештә беренче тапкыр инвалидлыгы билгеләнгән балалар санының артуы борчылу уята: 2015 елда шундый 149 очрак булса, 2016 елда 167 очрак теркәлде.

Татарстан Республикасында балалар һәм яшүсмерләр арасында I төр шикәр авыруы белән чирләү һәм аның таралышы өлешендә хәвефле статистика да үзенә игътибарны җәлеп итә. Татарстан Республикасы

Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2013 – 2015 елларда республикада балалар һәм яшьләр арасында I төр шикәр авыруның таралышы шактый арту билгеләп үтелә, авыру билгеләр булган балалар саны якынча 9,5 %ка арта, бу элек фаразланган саннардан (3 %) шактый артык. 2015 елда Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр арасында I төр шикәр авыруының таралышы 100 мең балага 126,6 кеше, ә авыручылар 10 мең балага 21 кеше туры килә иде. 2016 елда бу чир Татарстан Республикасында беренче тапкыр 100 балада һәм яшүсмердә табылды. Бүгенге көндә республикада мондый төр шикәр авыруыннан интегүче 835 бала яши. Әлеге хәл I төр шикәр авыруын профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү зарурлыгын таләп итә.

Балаларның авыруларга бирешүчәнлегенә һәм балаларның инвалидлык алуларына бәйле вәзгыятьне истә тотып, Татарстан Республикасында нәтиҗәле һәм һәркемгә җитәрлек дәрәҗәдә эшли торган медицина тернәкләндерүе системасын булдыру аеруча әһәмиятле һәм мөһим булып тора. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, әлеге система бүген балаларны тернәкләндерү буенча ике дәүләт үзәгеннән гыйбарәт, аларның берсе – балалар поликлиникасы составында, икенчесе – төрле медицина учреждениеләре составындагы биш бүлектән торган медицина тернәкләндерү үзәге. Тернәкләндерү учреждениеләренең мондый челтәре, әлбәттә, бу хезмәткә булган ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый.

Шулай итеп, республикада балалар авыруларын һәм инвалидлыгын анализлап, якын киләчәктә Татарстан Республикасы балалар сәламәтлеген саклау системасын үстерүнең төп бурычлары түбәндәгеләр булырга тиеш саныйбыз:

1. Балаларның тышкы сәбәпләр аркасында килеп чыга торган авыруларын профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү;

2. Балалар арасында I төр шикәр авыруын профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү;

3. Балигъ булмаганнар арасында йөклелекне профилактикалау буенча нәтиҗәле чаралар эшләү һәм кабул итү;

4. Балаларга психиатрия ярдәме системасын үстерү;

5. Балаларга наркология ярдәме күрсәтү системасын үстерү;

6. Балаларны медицина тернәкләндерүе буенча нәтиҗәле һәм һәркем файдалана алырлык система булдыру, балаларның беренче тапкыр инвалидлык алу күрсәткечләре зур булган республика муниципаль районнарында, балалар инвалидлыгының сәбәпләрен һәм моңа китерә торган шартларны анализлау юлы белән, балаларның инвалид булуын профилактикалау буенча чаралар күрү.

3.2.3. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре

Балаларга профилактик вакцина ясау һәм туберкулез диагностикасы

Татарстан Республикасында 2016 елда балаларга профилактик вакцина ясауның торышын анализлау күрсәткәнчә, ата-аналарның барлык төр авырулар буенча да, туберкулездан тыш, балаларына профилактик вакцина ясатудан баш тарту очраклары 2015 елдагы 27 857 очрактан 2016 елда 40 136га кадәр арткан.

19 нчы таблица

2013–2016 елларда балаларга профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулез диагностикасыннан баш тарту статистикасы

Профилактик вакцина ясау һәм туберкулез диагностикасы		**Баш тартулар саны**				
		2013 ел	**2014 ел**	**2015 ел**	**2016 ел**	**2015 елга %**
Профилактик вакцина ясау, шул исәптән:	дифтерия	3380	4170	4200	5700	+35,7%
	бума ютәл	2118	2447	2443	2940	+20,3%
	полиомиелит	2837	3758	3546	5437	+53,3%
	кызамык	3393	4159	4100	6219	+51,7%
	эпидемиологик паротит	3381	4169	4100	6176	+50,6%
	кызылча	3451	4242	4210	6308	+49,8%
	В гепатиты вирусы	3898	4918	4554	6678	+46,6%
	туберкулез	472	626	722	678	-6,1%
Туберкулин диагностикасы			5032	4421	3686	-16,5%

Шул ук вакытта, профилактик вакцина ясатудан баш тарту күпьеллык вакциналар ярдәмендә күптән бетерелгән куркыныч һәм авыр чирләр йоктыру хәвефен тудыра. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе белешмәләре буенча, 2016 елда бума ютәл белән авыру очракларының, 2015 ел белән чагыштырганда, 76,7 %ка артуы теркәлгән. Әлеге авыруга барлыгы 372 кеше дучар булган, шуларның 367се балалар, шул исәптән, 287се бума ютәлгә каршы профилактик вакцина ясатылмаган балалар. Шулардан бары тик 69 балага гына (24%) вакцина медицина күрсәтмәләре буенча ясалмаган булган.


Профилактик вакцина ясаудан баш тартуның кимүе буенча уңай тенденция туберкулезга профилактик вакцина ясауга карата (44 очрак, яисә 6,1%) һәм туберкулин диагностикасы буенча күзәтелде (735 очрак, яисә 16,5%). Бу, күпмедер дәрәҗәдә, профилактик вакцина ясату һәм ту-

беркулин диагностикасының зарурлыгы турында балаларның законлы вәкилләре белән максатчан агарту, аңлату һәм профилактик эш алып баруга, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль районнардагы балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренең бу юнәлештәге эшенең активлашуына бәйле.

Шулай да балалар арасында туберкулез авыруы беренче тапкыр табылган очракларның тотрыклы булуы җитди куркыныч тудыра һәм уйлануларга этәрә.

73 диаграмма

2013 – 2016 елларда балалар арасында туберкулез авыруы беренче тапкыр табылган очраклар



Моннан тыш, туберкулез йоктыру куркынычын бәяләп бетермәү көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Туберкулин диагностикасы ясалмаган бала чирнең башлангыч стадияләрдә табылуына һәм үз вакытында күрсәтелгән медицина ярдәменә өметләнә алмый, димәк, башка балалар өчен авыру йоктыру куркынычы туа. Республикада балалар арасында 2015 – 2016 елларда бу авыруны ата-анасының профилактик вакцина ясатудан баш тартуы аркасында йоктыру очракларының булуы шул хакта сөйли.

Туберкулин диагностикасыннан баш тартуның түбәндә бер мисалын китерәбез. 2015 елда Әгерҗе шәһәрендә флюрография тикшерүе вакытында гомуми белем бирү учреждениеләренең берсендә белем алучы балада туберкулез авыруы табылды. 2013 – 2015 елларда бу балага, законлы вәкилләренең баш тартуы аркасында, тиешле тикшерүләр үткәрелмәгән булган. Ләкин аңа кадәр бала фтизиатр табибта исәптә торган. Балага бу чир туган тиешле заттан йоккан. Шулай булуга карамастан, әлеге бала мәгариф оешмасына йөргән һәм башка балаларның сәламәтлеген куркыныч астына куйган.

2016 елда «ЕЛЕНА-СЕРВИС» урта гомуми белем бирү мәктәбе» хосусый белем бирү учреждениесе укучысында таркалу фазасына җиткән инфильтратив үпкә туберкулезы табылды. 2014 елда ясалган «Диаскинтест» пробасы уңай булуга һәм фтизиатр табибта тикшерү узмауга карамастан, ул белем бирү оешмасына йөргән. Татарстан Республикасы буенча

Роспотребнадзор идарәсе үткәргән санитария-эпидемиология тикшерүе барышында законнарны түбәндәгечә бозулар ачыкланды: иммунодиагностика һәм фтизиатр табибта тикшеренү үтүдән баш тарткан балаларны белешмә – рөхсәт кәгазеннән башка уку-укыту оешмаларына кертү, югарыда телгә алынган мәгариф оешмасының алты хезмәткәренең үпкәгә рентген яисә флюрография үтү нәтиҗәләре турында белешмәләре булмау. Ачыкланган хокук бозулар буенча мәгариф учреждениесенә административ җәза һәм бу хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелде. Шулай ук мәгариф оешмасында укучы балада туберкулез инфекциясе табылуга бәйле рәвештә, 250 кв.м мәйданга дезинфекция үткәрелде, авырган бала белән аралашкан 15 балага фтизиатр табиб тикшерүе үткәрелде. Мондый очрак башкача кабатланмады. Әлеге хәл, югарыда телгә алынган белем бирү оешмасында авырган бала белән бергә укучы баланың ата-анасыннан кергән мөрәҗәгатькә бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан да тикшерелде. Гомуми белем бирү учреждениесе директоры Н.Г. Әхәтова адресына санитария-эпидемиология законнары нормаларын, балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген саклау таләпләрен бозуның ачыкланган фактларын бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне; хокук бозуларга күз йомган затларга дисциплинар җаваплылык билгеләүне; белем бирү оешмасында балаларның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, уңайлы укуны, сәламәтлек саклауга хокукны тулысынча гамәлгә ашыруны һәм гамәлдәге законнар таләпләренә җавап бирә торган белем алуны гарантияли торган тиешле уку шартлары тудыруга юнәлдерелгән чаралар күрүне таләп итеп бәяләмә җибәрелде.

Балаларның законлы вәкилләренең профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартуының сәбәбе булып, кагыйдә буларак, баланың әлеге гамәлләрдән соң үзлегеп китүеннән курку тора. Ләкин, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, балаларда профилактик вакциналардан соң үзлегүләр бик сирәк очрый.

20 нче таблица

2013 – 2016 елларда балаларның вакцинадан соң үзлегү очраклары статистикасы

Вакцинадан соңгы үзлегүләр, саны	**2013 ел**	**2014 ел**	**2015 ел**	**2016 ел**
	2	3	3	2

Баш тартулар проблемасы балаларның сәламәтлек саклауга һәм белем алуга хокукларын тәэмин итү ягыннан җитди әһәмияткә ия. Ата-аналарның профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартуы баланың белем алу хокукын гамәлгә ашыруга турыдан-туры йогынты ясый, чөнки бу гамәл аркасында бала

мәгариф учреждениеләренә кертелмәскә мөмкин. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең бу хактагы дәлилләнгән хокукый позициясе 2015 ел йомгаклары буенча ясалган докладта бәян ителгән иде, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

профилактик вакцина ясау һәм туберкулин диагностикасы баланың сәламәтлеген саклауга хокукын тәэмин итүгә юнәлдерелгән;

профилактик вакцина ясау вакцина кертү юлы белән йогышлы авырулардан профилактикалауны күздә тота һәм аңардан баш тарту китереп чыгарырга мөмкин хәлләрне хокукый җайга салу таләп ителә һәм баланы мәктәпкә яисә балалар бакчасына кертмәү өчен нигез була алмый;

туберкулез диагностикасыннан, шул исәптән Манту пробасы ясатудан яисә тиешле белешмә бирү өчен баланы туберкулезга тикшерүнең табиб тәкъдим иткән башка альтернатив ысулларыннан баш тарту очракларына баланың белем алуга дәүләт тарафыннан гарантияләнгән хокукларын киметү дип карарга ярамый. «Мәгариф турында» Россия Федерациясе законының 17 статьясы нигезендә мондый очракларда белем алуга хокук өйдә уку рәвешендә, икенче төрле әйткәндә, белем бирү белән шөгыльләнә торган оешмадан читтә башкарылырга мөмкин.

Балаларга профилактик вакцина ясаудан һәм туберкулин диагностикасыннан баш тартулар вәзгыятен анализлау нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына профилактик вакцина ясауның һәм туберкулин диагностикасы үткәрүнең максатка ярашлы һәм зарури булуы турында балаларның законлы вәкилләре белән агарту, аңлату һәм профилактик эш алып баруны дәвам итәргә тәкъдим итә.

Балаларны кирәкле дарулар һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итү проблемалары

Гомер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү бурычын ***тиешенчә үтәү проблемасы*** 2016 елда да Татарстан Республикасында актуаль булып калды.

«Россия Федерациясендә гражданнарың сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль закон нигезендә (алга таба – Закон) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына дарулар-га мохтаҗ гражданнарны алар белән тәэмин итүгә бәйле оештыру-идарә вәкаләтләре дә, бюджеттан финанслау буенча финанс йөкләмәләре дә йөкләнгән.

Бүген Гомергә куркыныч яный торган һәм хроник көчәя баручы, гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларның федераль регистрының региональ исемлегендә 272 бала теркәлгән.

21нче таблица

2013 – 2016 елларда Гомергә куркыныч яный торган һәм хроник көчәя баручы, гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларның федераль регистрының региональ исемлегендә теркәлгән балалар саны

№ п/п	Гомергә куркыныч яный торган һәм хроник көчәя баручы, гомер озынлыгын кыскартуга яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулар исеме	Балалар саны, кеше			
		2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел
1	Гемолитик-уремик синдром	26	29	30	32
2	Пароксизмаль төнге гемоглобинурия	1	1	1	0
3	Ачыкланмаган апластик анемия	7	5	6	8
4	II (фибриноген), VII (лабиль), X (Стюарт – Прауэр) факторларның нәселдән килгән кытлыгы	2	2	5	7
5	Идиопатик тромбоцитопеник пурпура (Эванс синдромы)	44	43	41	43
6	Иртә җенси өлгерү	42	41	40	36
7	Аромат аминокислоталар алмашы бозылу (классик фенилкетонурия, гиперфенилаланинемиянең башка төрләре)	93	90	91	92
8	Тирозин алмашы бозылу	2	2	2	3
9	Май кислоталары алмашы бозылу	0	1	1	2
10	Галактоземия	8	9	10	10
11	Мукополисахаридоз, I төр	2	3	3	2
12	Мукополисахаридоз, II төр	2	2	3	4
13	Бакыр алмашы бозылу (Вильсон авыруы)	4	3	2	3
14	Төгәлләнмәгән остеогенез	14	14	15	14
15	Үпкә (артериаль) гипертензия (идиопатик) (беренчел)	2	4	4	2
16	Системалы башлана торган яшүсмерләр артриты	16	16	16	14
Барлыгы		**265**	**265**	**270**	**272**

Бу балаларның бары тик 136сы гына бюджет акчалары исәбеннән дарулар белән, 84е бюджет акчалары исәбеннән махсус туклану белән тәэмин ителде.

Россия Федерациясе субъектларының мондый чыгым вәкаләтен үтәүдәге төп проблемасы сирәк очрый торган (орфан) авыруларны дәвалау өчен кирәкле даруларның кыйммәт булуында. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, гомергә куркыныч яный торган авырулардан интегүче балаларны дару-

лар һәм махсус дәвалау продуктлары белән тәэмин итү өчен 2016 елда ихтыяҗ 224,3 млн.сум иде. Ләкин хисап чорында бары тик 140,0 млн. сум бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирелде. Мондый финанслауның әлеге йөкләмәләрне тулысынча үтәргә мөмкинлек бирмәве көн кебек ачык.

2016 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын гомер озынлыгына тәэсир итә торган яисә инвалидлыкка китерә торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү бурычын һәм суд карарларын тиешенчә үтәргә мәҗбүр итү буенча үткәрелгән судлар фонында әлеге проблема тагын да кискенрәк төс ала.

2016 елда югарыда әйтелгән проблема буенча дүрт суд карары чыгарылды (шуларның икесендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дә катнашты). Чыгарылган карарларның икесе бөтенләй дә үтәлмәде: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар белән тәэмин итү йөкләмәләрен тиешенчә үтәргә мәҗбүр итү турындагы суд карарларын җиренә җиткереп үтәү өчен финанс ихтыяҗы елына 74,1 млн. сум булырга тиеш.

Шуңа бәйле рәвештә гомергә куркыныч яный торган сирәк (орфан) авырулардан интегүче балаларны дарулар һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру мәсьәләсен карарга кирәк.

2016 елда, гражданнардан кергән мөрәҗәгатькә бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***I төр шикәр авыруыннан интегүче балаларны медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итү мәсьәләсен*** өйрәнде.

Мөрәҗәгать итүнең тарихы. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә югарыда телгә алынган авырудан интегүче ир баланың әнисеннән мөрәҗәгать алынды. Анда бәян ителгәнчә, канда глюкоза күләмен билгеләү өчен балага елына 12 туб тест-полосалар бирелә. Ләкин, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 9 ноябрендәге 750 номерлы боерыгы белән расланган Инсулинга бәйлелек барлыкка килә торган шикәр авыруы белән чирле балаларга беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү стандарты (алга таба – Беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү стандарты) нигезендә, канда глюкоза күләмен үлчәү ешлыгы елына 1 460 үлчәүгә туры килергә тиеш, шуны истә тотып, аның баласы елына түләүсез 29 туб алырга хокуклы. Шул ук вакытта, реаль ихтыяҗдан (кандагы глюкоза күләмен тәүлегенә 10 – 12 тапкыр үлчәү ихтыяҗыннан) чыгып караганда, балага тагын да күбрәк тест-полосалар

бирелергә тиеш: аена 5 туб яисә елына 60 туб. Моннан тыш, балага ай саен инсулин помпасы өчен җайланмалар кирәк, моңа катетеры булган канюль комплекты (10 мең сумга якын), кандагы глюкозаны тәүлек буена мониторинглау өчен сенсорлар комплекты (12 – 18 мең сум) керә. Ләкин әлеге җайланмаларны мөрәҗәгать итүче үз акчасына сатып алырга мәҗбүр, ә бу исә гаилә өчен матди кыенлыклар тудыра.

Әлеге мөрәҗәгатьне карау һәм Татарстан Республикасында балаларның 1 төр шикәр авыруы белән чирләвенең, аларны медицина билгеләнешендәге кирәкле әйберләр белән тәэмин итүнең бүгенге торышын өйрәнү барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәгеләр ачыкланды.

Татарстан Республикасында соңгы елларда балалар һәм яшүсмерләр арасында 1 төр шикәр авыруының таралышы шактый артты. 2015 елда республикада балалар һәм яшүсмерләр арасында 1 төр шикәр авыруының таралышы 100 мең кешегә 126,6, авыручылар – 100 мең кешегә 21 кеше булса, 2016 елда Татарстан Республикасында шикәр авыруы беренче тапкыр 100 балада һәм яшүсмердә табылды. Бүген республикада 1 тип шикәр авыруыннан интегүче 835 бала яши. Аларны дарулар һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән, аерым алганда кандагы глюкоза күләмен өй шартларында мониторинглау системасы (аңа тест-полосалар да керә) белән тәэмин итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

дәүләт социаль ярдәмен алу хокукына ия гражданнар (федераль ташламалардан файдаланучылар), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 28 декабрендәге 2885-р күрсәтмәсе белән расланган 2017 елга Сәламәтлек өчен кирәкле һәм мөһим медицина кулланылышындагы дарулар исемлеге һәм социаль хезмәтләр җыелмасы бирелгәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 22 октябрендәге 2229-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Медицина әйберләре алу өчен бирелгән рецептлар буенча сатыла торган медицина әйберләре исемлеге нигезендә;

Татарстан Республикасы законнары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокукы булган гражданнар (региональ ташламалардан файдаланучылар), дарулар белән түләүсез тәэмин ителү хокукына ия гражданнарга бирелә торган дарулар һәм медицина әйберләренең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 17 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Амбулатор дәвалану вакытында табиб рецептлары буенча дарулар һәм медицина әйберләре түләүсез бирелә торган авырулар категорияләре исемлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 16 мартындагы 315-р номерлы боерыгы белән расланган Дарулар белән түләүсез тәэмин ителү хокукына ия гражданнарга бирелә торган дарулар,

медицина әйберләре һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары бирелә торган исемлеге нигезендә.

Югарыда телгә алынган Беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү стандарты нигезендә канда глюкоза күләмен елына 1 460 тапкыр тикшерү «анализатор ярдәмендә кандагы глюкоза күләмен тикшерү» буенча медицина хезмәте күрсәтү һәм сәламәтлек саклау учреждениеләрендә үткәрелә торган тикшерү ысулы булып тора. Тест-полосалар һәм аларны билгеләү нормативлары моңа кертелми.

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү стандарты нигезендә медицина ярдәме стандартына кертелмәгән дарулар, медицина әйберләре һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктларын билгеләү һәм кабул итү табиблар комиссиясе тарафыннан бирелгән медицина күрсәтмәсе булганда гына (шәхси түзеп торалмаучылык булганда, гомергә куркыныч янаганда) рөхсәт ителә.

Шулай итеп, 1 төр шикәр авыруыннан интегүче бала, гамәлдәге законнар нигезендә тест-полосаларны табиблар комиссиясе карары белән, алар билгеләгән күләмдә, түләүсез алу хокукына ия.

Инсулин помпасына чыгым материаллары белән тәэмин итү өлешендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан түбәндәгеләр билгеләнде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 19 декабрендәге 1382 номерлы карары белән расланган 2016 елга Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасының Мәҗбүри медицина иминияте база программасы буенча медицина ярдәме күрсәтүнең югары технологияле төрләре исемлегенә «Эндокринология» һәм «Педиатрия» профильләре буенча махсус *(«Комплексное лечение, включая установку средств суточного мониторирования гликемии с компьютерным анализом вариабельности суточной гликемии и нормализацией показателей углеводного обмена с системой непрерывного введения инсулина (инсулиновая помпа)», «Комплексное лечение тяжелых форм сахарного диабета на основе молекулярно-генетических, гормональных и иммунологических исследований с установкой инсулиновой помпы под контролем систем суточного мониторирования глюкозы»)* дәвалау ысуллары керә. Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 декабрендәге 1403 номерлы карары белән расланган 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт программасының мәҗбүри медицина иминияте буенча база программасында да бар.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, бүген республикада 270 балада инсулин

помпасы бар, 2016 елда югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү кысаларында шуларның 40ына инсулин помпалары куелды. Помпаларны кулланганда инсулинның аналоглары — инсулин лизпро, инсулин аспарт, инсулин глулизин, шулай ук чыгым материаллары – инсулин помпалары өчен резервуарлар, инфузия җайланмалары, катетерлар, кыстыргычлар, инсулин помпаларын тоташтырып кую өчен тышлыклар һәм башкалар файдаланыла. Бер кеше аена куллана торган инсулинның, якынча алганда, бәясе 1 855, 06 сум һәм чыгым материаллары 9 – 10 мең сум тора. Ләкин чыгым материаллары белән тәэмин итү Югары технологияле медицина ярдәме төрләренә керми. Шулай итеп, 1 төр шикәр авыруы белән интегүче балаларга инсулин помпасына чыгым материаллары бирелми, алар, шул исәптән мөрәҗәгать иткән ана да, бу әйберләрне үз акчаларына алырга мәҗбүр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына инсулин помпаларына чыгым материалларын (резервуарлар, инфузия җайланмалары, катетерлар, кыстыргычлар һ.б.) дәвалау ысулы итеп Мәҗбүри медицина иминияте база программасы буенча медицина ярдәме күрсәтүнең югары технологияле төрләре исемлегенә кертү мәсьәләсен карау башлангычы белән чыгарга тәкъдим итәбез.

Мәгариф оешмаларында укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту буенча тиешле шартлар тудыру проблемасы

Белем бирү учреждениеләрендә балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга хокуклары үтәлеше Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәрвакыт игътибар үзәгендә тора.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда беркетелгән төп академик хокукларның берсе – укучыларның гомерне һәм сәламәтлекнең саклауга хокукы. Мәгариф оешмасы, үз чиратында баланың сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен кирәкле шартларны тудырырга тиеш (28 статья).

Әлеге законның 41 статьясы нигезендә укучыларның сәламәтлеген саклау законнарда күрсәтелгән тәртиптә беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне һәм укучыларның тукланууын оештыруны үз эченә ала.

Белем алучыларга беренче медицина-санитария ярдәме күрсәтүне оештыру эшләрен сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы башкара, күрсәтелгән ярдәм укучыларга медицина оешмалары, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән тәртиптә медицина эшчәнлеген алып бара торган белем бирү оешмалары тарафыннан күрсәтелергә мөмкин. Билгеләнгән тәртипләр буенча, мәгариф оешмасы медицина эшчәнлеген башкару өчен тиешле шартларга һәм таләпләргә туры килә торган урынны медицина оешмасына түләүсез

бирә. Мәгариф оешмасы биргән бүлмә санитария-эпидемиология нормаларына һәм медицина эшчәнлеген башкару өчен билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш. Медицина хезмәткәрләренә эшләү өчен тиешле шартлары булган бүлмә бирелмәгән очракта яисә медицина оешмасының мәгариф оешмасы биргән бүлмә урнашкан җирдә аерым эшләргә (хезмәт күрсәтүләргә) лицензиясе булмаса, балигъ булмаганнарга белем һәм тәрбия алу чорында медицина ярдәмен медицина оешмасы биналарында күрсәтү рөхсәт ителә.

Укучыларга беренче медицина-санитария ярдәмен мәгариф оешмасында белем алу урынында күрсәтүне оештыру өстенлеклерәк булып тора.

Мәгариф учреждениеләрендә белем алучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә беренче медицина-санитария ярдәмен оештыру вәзгыятен анализлау күрсәткәнчә, 2016 елда 396 балалар бакчасында тәрбияләнүчегә һәм 333 мәктәптә укучы балаларга мәгариф учреждениеләре базасында оештырылган һәм лицензия таләпләренә җавап бирми торган беренче медицина-санитария ярдәме тәкъдим ителгән. Башкача әйткәндә, 21,6 % балалар бакчаларында һәм 23,5 % мәктәптә беренче медицина-санитария ярдәмен күрсәтү тиешенчә оештырылмаган.

22 нче таблица

2013 – 2016 елларда мәгариф оешмалары тарафыннан укучыларның сәламәтлеген саклау һәм нығыту өчен тиешле шартлар тудыру белешмәләре

Күрсәткеч исеме			**2013**	**2014**	**2015**	**2016**
Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары саны, барлыгы:			1876	1924	1889	1 836
шул исәптән	медицина кабинетлары булганнар		1026	1040	1084	1 098
	шулардан	медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булганнар	495	557	651	702
	фельдшер-акушерлык пунктларында хезмәт күрсәтелүчеләр		932	1367	805	738
Гомуми белем бирү оешмалары саны, барлыгы:			1 486	1 459	1 403	1 419
шул исәптән	медицина кабинетлары булганнар		642	667	702	710
	шулардан	медицина эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булганнар	235	227	332	377
	фельдшер-акушер пунктларында хезмәт күрсәтелүчеләр		834	792	701	687

Шул ук вакытта, медкабинетлары булган мәктәпләр арасында лицензияле медкабинетлары булган мәктәпләр өлеше соңгы хисап елында (2015 елда 433 балалар бакчасында (23%) һәм 370 мәктәптә (26,4%) 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясен гамәлгә ашыруның индикатив күрсәткеченнән югары.

Әлеге фактка карамастан, бу өлкәдәге вәзгыять таләп иткәнчә, мәгариф оешмаларындагы медицина бүлмәләрен санитария-эпидемиология нормаларына һәм медицина эшчәнлеген башкару өчен кирәкле нормаларга туры китерү буенча чаралар күрелергә тиеш.

Укучыларның сәламәтлеген саклау хокукын тәэмин итүнең тагын бер гарантиясе мәктәптә балаларның туклануын оештырудан гыйбарәт.

Россия Федерациясендә Мәгариф турында Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлеше нигезендә укучыларны тукландыру бурычы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага йөкләнә.

Мәктәпләрдә бер тапкыр тукландыру яисә ике тапкыр тукландыру өчен шартлар тудырылырга мөмкин. Балаларны ике тапкыр кайнар азык белән тукландыру бурычы мәгариф учреждениесендә белем бирү эшчәнлеге федераль дәүләт стандартлары нигезендә оештырылган очракта барлыкка килә, бу стандартлар буенча, уку-укыту программаларын гамәлгә ашырганда, белем бирү оешмасына аерым таләпләр йөкләнә. Бүген республикадагы барлык мәктәпләрнең 1 – 4 сыйныфларында белем бирү башлангыч гомуми белемнең Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча оештырылган, бу стандарт Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 6 октябрендәге 373 номерлы боерыгы белән расланды. Шулай итеп, Татарстан Республикасының барлык мәктәпләрендә 1 – 4 сыйныфлар кайнар ризык белән ике тапкыр тулысынча тәэмин ителергә тиеш.

23 нче таблица

2016 – 2017 уку елында мәктәп балаларын кайнар ризык белән тәэмин итү күрсәткечләре

Сыйныфлар	Кайнар ризык белән тәэмин ителгән мәктәп балалары өлеше, %			Кайнар ризык белән тәэмин ителмәгән мәктәп балалары өлеше, %
	бер тапкыр ашату	ике тапкыр ашату	барлыгы	
1 – 4	38,8	59,5	98,3	1,7
5 – 9	52,4	42,9	95,3	4,7
10 – 11	55,8	36,4	92,2	7,8
Барлыгы	**49**	**46,3**	**95,3**	**14,2**

Шулай итеп, бүгенге көндә укучыларның 95,3 %ы бер яисә ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителгән, бу, гомумән алганда, республи-

када мәктәп балаларын туклану белән тәэмин итүне уңай дип бәяләргә мөмкинлек бирә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, барлык яшь төркемнәрендәге укучыларны ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итү Татарстан Республикасының Аксубай, Апас, Әтнә, Кайбыч, Лаеш, Саба, Тукай, Теләче, Балтач һәм Менделеевск муниципаль районнарында тулысынча хәл ителгән.

Шулай да 10 – 11 сыйныфларны кайнар ризык белән тәэмин итү турында бирелгән белешмәләр игътибарны җәлеп итә. Бүген бу сыйныфларда белем алучы балаларның 7,8 %ы мәктәптә гомумән дә кайнар ризык белән тукланмый. Бу яшьтә физик, акыл ягыннан нагрузкаларның күп булуын, яшь үзенчәлекләрен истә тотып, бу проблеманың белем бирү оешмаларында, шул исәптән ата-аналар алдында агарту, аңлату эшләре оештыру һәм тәкъдим ителә торган ризыкның сыйфатына игътибар итү, кирәк булган очракта, аны яхшырту чаралары күрү өчен нигез булып торуын билгеләп үтәбез.

1 – 4 сыйныфларны кайнар ризык белән тәэмин итү республика буенча 98,3 % тәшкил итә. Федераль дәүләт белем бирү стандартының укучыларны 100 процент ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итү таләбен бу категория укучылар өчен үтәмәү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда Буа, Кукмара, Кама Тамагы, Сарман муниципаль районнарына хас.

Шул уңайдан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге муниципаль районнарның хакимият башлыкларына 1 – 4 сыйныфларда укучыларның, ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итү өлешендә, сәламәтлек саклауга хокуклары бозылуны күрсәтергә мәҗбүр булды.

«Россия Федерациясендә Мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясындагы 4 өлеше нигезендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын финанс белән тәэмин итү җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралганча, җирле үзидарә органнары гражданнарның аерым категорияләре өчен муниципаль берәмлек бюджеты исәбеннән социаль ярдәмнең һәм социаль яклауның өстәмә чараларын билгеләү хокукына ия.

Шулай итеп, җирле үзидарә органнарының тиешле норматив хокукый актлары нигезендә, укучыларның аерым категорияләре өчен туклану түләүсез булырга мөмкин. Мәсәлән, укучыларның мондый категорияләренә күпбалалы һәм (яисә) начар хәлле гаиләләрдән булган балалар кертелә ала.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча 2016/2017 уку елы башына 40 302 укучы, шуларның 23 483 е – начар хәлле гаиләләрдән булган балалар, 16 819 укучы – күпбалалы гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар түләүсез туклану белән тәэмин ителгән.

24 нче таблица

2016/2017 уку елы башына укучыларны түләүсез тукландыру белән тәэмин итү күрсәткечләре

Сыйныф-лар	Туклану белән тәэмин ителгән гомуми белем бирү оешмалары укучылары (кеше)			
	начар хәлле гаиләләрдән булган укучы-лар	шулардан түләүсез ту-клану белән тәэмин ителүчеләр	күпбалалы гаиләләрдән булган укучы-лар	шулардан түләүсез ту-клану белән тәэмин ителүчеләр
1 – 4	17586	11006	20349	7666
5 – 9	17842	10528	20800	7885
10 – 11	3032	1949	3229	1268
Барлыгы	**38460**	**23483**	**44378**	**16819**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, республикада, гомумән алганда, начар хәлле гаиләләрдән булган балаларны түләүсез тукландыру дәрәҗәсе 9,1 %ка арткан һәм күпбалалы гаиләләрдән булган балаларны түләүсез тукландыру дәрәҗәсе 2,6 %ка кимегән.

Мәктәпләрдәге начар хәлле гаиләләрдән булган балаларның барысын да түләүсез тукландыру белән тәэмин итеп бетерә алмау борчу уята, шундый категориягә керә торган 38 460 баланың бары тик 23 483 е (61 %) генә бу хокуктан файдалана. Начар хәлле гаиләләрдән булган калган 40 % баланың бу хокуктан файдалану мөмкинлеге тәэмин ителмәгән. Шул ук вакытта бу балаларга сәламәт һәм дөрес туклану дәүләт тарафыннан тәэмин ителгән булырга тиеш.

Әйтелгәннәрдән чыгып, республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына начар хәлле гаиләләрдән булган балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү мәсьәләсен карарга кирәк дип саныйбыз.

Әзерләнә торган **продукциянең сыйфаты һәм әзерләү шартлары** республика мәктәпләрендә белем алучыларның, балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрнең тукланuын оештыруны тәэмин итү торышын тулысынча һәм объектив бәяләү өчен җитди критерий булып тора.

Әлеге мәсьәләләр күзәтчелек органнарының аеруча игътибар үзәгендә тора.

Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә түбәндәге проблемалар ачыкланды: төп азык-төлек продуктларын куллану нормасы тулы күләмдә үтәлми; республика муниципаль районнарының барысында да менюда ит, яшелчә һәм җиләк-җимеш, балык, эремчек продуктларының кимүе күзәтелә; туклану һәрвакытта да нисбәтле түгел: яшелчәләргә караганда углеводлар, боткалар һәм макарон әйберләре ешрак бирелә; сезонлы яшелчәләр бирү буенча туклану нормалары үтәлми.

2016 елда Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе тарафыннан мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын тикшерү вакытында, сайлап алынган ризыкның гомуми күләменнән 2,2 %ы микробиологик күрсәткечләр буенча норматив таләпләргә (2015 елда – 2,7 %), калория һәм химик составлары буенча 4,7%ы гигиена таләпләренә (2015 елда – 7,8%) туры килмәде. Гомуми белем бирү оешмаларында микробиологик күрсәткечләр буенча иминлек таләпләренә әзер ризыкның 2,2 %ы, (2015 елда – 2,5%), ә санитар-химик күрсәткечләр буенча 2,8 % ы (2015 елда – 2,0%) туры килмәде. Татарстан Республикасы 10 муниципаль районының 22 мәктәбендә (Чистай, Зеленодольск, Нурлат, Кайбыч, Питрәч, Лаеш, Алабуга, Әгерҗе, Тәтеш, Мөслим), бу тикшерүләрнең гомуми санының 4, 3%ы, яшь буенча 7– 10, 11 – 18 яшьлек балалар өчен аерым төзелгән меню булмауга бәйле кимчелекләр ачыкланды, шулай ук 2016 елда Чистай, Алексеевск, Зәй, Азнакай муниципаль районнарының, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләренең 9 гомуми белем бирү оешмаларында әзер ризык порциясе күләменең 1,4 % таләпләргә туры килмәве билгеле булды. 2016 елда гомуми белем бирү оешмаларын тикшерү вакытында нисбәле булмаган туклану фактлары, икенче төрле әйткәндә менюда аксым, май һәм углеводлар чагыштырмасы бозылу табылмады.

Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе билгеләп үткәнчә, гомуми белем бирү хезмәткәрләре штатына керә торган квалификацияле медицина персоналы җитмәве карала торган тармакта төп проблема булып тора. Медицина хезмәткәренең эше, аеруча авыл җирендә, аның медицина оешмасындагы төп эше белән бергә алып барыла, шунлыктан аның тукланууны оештыру өлкәсендәге функцияләре башка затлар – директор, производство мөдире яисә аш пешерүче тарафыннан башкарыла.

2016 елда мәгариф оешмаларында контроль-күзәтчелек гамәлләре нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы буенча Роспотребсоюз идарәсе белгечләре тарафыннан сөттән ясалмаган майлар кушылган сөт продуктларын (ак май, сөт, каймак, сыр, эремчек) куллану очраклары теркәлде. Бу 21 мәктәпкә һәм 9 балалар бакчасына хас булды.

2016 елда, шулай ук 5 гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасында балаларга мәктәп яны укыту-тәҗрибә, бакча участокларында һәм теплицаларда үстерелгән, составларындагы нитратлар күләме буенча Таможня берлегенең «Азык-төлек продукциясенең куркынычсызлыгы турында» ТР ТС 021/2011 техник регламентында билгеләнгән гигиена нормативларына туры килми торган җиләк-җимеш продукциясе белән тукландыру фактлары ачыкланды. Татарстан Республикасы буенча Роспотребсоюз идарәсе тарафыннан шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының башкарма комитетлары җитәкчеләренә балаларны тукландыру өчен үз җиләк-җимеш, яшелчә продукцияләреннән файдалана торган мәгариф оешмаларында производство тикшерүе үткәрергә тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы прокуратурасы мәгълүматларына караганда, 2016 елда үткәрелгән тикшерүләр вакытында мәгариф оешмаларында укучыларның тукануын оештыруда кимчелекләр табылды. Ел дәвамында балалар тукануын оештыру өлкәсендә тикшерү гамәлләре буенча Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары прокурорлары тарафыннан барлыгы 30 күрсәтмә чыгарылды, аларны карау нәтиҗәләре буенча 40 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды, административ хокук бозулар турында эш кузгату хакында 10 карар чыгарылды.

3.2.4. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру

2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясендә каралганча, балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру сәламәтлек саклау өлкәсенең өстенлекле юнәлешләренең берсе буларак билгеләнгән.

2016 елда Татарстан Республикасында балаларның ялын һәм савыгуын оештыру түбәндәге программалар нигезендә җайга салынды:

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «2014 – 2020 елларга балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру» ярдәмче программасы;

«Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмә;

«2016 елга балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 елның 9 октябрендәге 756 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;


«Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат стандартын раслау турында» 2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфат стандарты.

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялы, аларны савыктыру системасын үстерү максатларында республикада 2013 елдан бирле балаларның стационар җәйге савыктыру лагерьларын капиталь ремонтлау программасы гамәлгә ашырыла, ул ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары белән раслана. Мәсәлән, 2016 елда савыктыру лагерьларын җәйге сезонга әзерләү барышында 12 дәүләт һәм муниципаль балалар савыктыру лагерьларында капиталь ремонт һәм реконструкция эшләре үткәрелде (2015 елда – 20 лагерьда, 2014 елда – 15 лагерьда, 2013 елда – 6 лагерьда). Моннан тыш, Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән 2016 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Чайка» балалар савыктыру лагере яңадан төзелде һәм кулланылышка тапшырылды. Программа гамәлгә ашырылган дүрт елда 53 стационар шәһәр яны лагере төзекләндерелде. Әлеге чаралар уңай бәяләнергә тиеш. Алар 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясендә 2016 ел өчен билгеләнгән индикатив күрсәткечләрдән (2 лагерь) шактый югары.

2016 елгы җәйге кампаниянең программа чараларын гамәлгә ашыру кысаларында барлык төрләрдәге 1 341 ял оешмасы җәлеп ителде, бу, 2015 елга караганда, 59 оешмага кимрәк (2015 елда – 1 400, 2014 елда – 1 383, 2013 елда – 1 310). Бу саннар мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьлар (51 оешмага), хезмәт һәм ял лагерьлары (6 оешмага), палаткалы лагерьлар (4 оешмага) кимүгә бәйле. Шул ук вакытта 2016 елда шәһәр яны ял лагерьларының саны (2 лагерьга) артты. 2016 елгы җәйге кампаниядә катнашкан Краснодар крае һәм Кырым Республикасы территорияләрендә урнашкан шифаханә-курорт оешмалары саны элеккеге дәрәҗәдә калды һәм 18 оешманы һәм 6 лагерьны тәшкил итте.


74 диаграмма

2013 – 2016 елларда балалар өчен ял һәм савыктыру учреждениеләре структурасы



75 диаграмма


2013–2016 елларда Татарстан Республикасында балалар өчен шәһәр яны ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы (милек төрләре буенча)



2016 елда ял итү программасы 217 981 кешегә (2015 елда – 216 685, 2014 елда – 213 862) исәпләнгән иде, бу 2015 елга караганда 1 296 кешегә күбрәк, җәйге чорда шулардан 165 508 бала ял итте, бу 2015 елгы җәйге кампаниягә караганда 4 579 кешегә кимрәк (2015 елда – 170 087, 2014 елда – 171 968).

76 диаграмма


2016 елда төрле рәвешләрдә ял иткән балалар һәм яшүсмерләр саны



Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белешмәләре буенча, балаларның җәйге ял оешмаларында ял итүенең нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгечә: 2016 елгы җәйге савыктыру кампаниясе ял итүчеләрнең гомуми санынна 94,6 %ка уңай йогынты ясаган (2015 елда – 92,5 %, 2014 елда – 92,6%, 2013 елда – 92,5%), 5,2 % балага савыктыруның файдасы аз булган (2015 елда – 7 %, 2014 елда – 7 %, 2013 елда – 7 %), 0,2 % балада файда бөтенләй сизелмәгән (2015 елда – 0,2 %, 2014 елда – 0,4 %, 2013 елда – 0,5 %).

77диаграмма

2013 – 2016 елларда җәйге ялның нәтиҗәлелеге



Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны әйбәт оештыру күп очракта профессиональ оештырылган педагогик, тәрбияви эшләргә бәйле. Балигъ булмаганнарның ял итү оешмаларыннан башбаштаклануып чыгып китү, балаларның җәрәхәтләнү очраклары, балигъ булмаганнар тарафыннан яисә аларга карата башкарылган җинаять эшләре педагогларның эше, ялны оештыру, балаларга тәрбия бирү һәм күз-колак булу сыйфатын бәяләүнең индикатив күрсәткече булып тора. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча,

2016 елгы җәйге ял кампаниясе чорында 3 очракта (2015 елда – 8 очрак) балалар ял итү оешмасын калдырып киткән: Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Чайка» балалар савыктыру лагерендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Березка» балалар савыктыру лагеренда, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Губин ис. балалар савыктыру лагеренда. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, хисап чорында балаларның җәрәхәтләнү очраклары арткан. Узган җәйге чорда ул 145 очракны тәшкил иткән (2015 елда – 32 очрак).

Әлеге хәлләр, аеруча 2016 елда балаларның җәрәхәтләнү очраклары арту балаларның ял лагерьлары өчен кадрлар составын әзерләү буенча үткәрелә торган эшнең нәтиҗәлелеген арттыру турында сөйли һәм балаларның ял оешмаларыннан башбаштакланып китүе, җәрәхәтләнү очракларын, аларның сәбәпләрен һәм бу гамәлләр мөмкин булган шартларны, алга таба шундый фактлар булмасын өчен, җентекләп анализларга кирәклеген искә төшерү өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, узган җәйге ял кампаниясе чорында күпләп йогышлы авыру таралу һәм балигъ булмаганнар тарафыннан яисә аларга карата җинаять эшләре кылу очраклары булмаган.

25 нче таблица

2013 – 2016 елларда савыктыру кампаниясе чорында балигъ булмаганнар тарафыннан җәрәхәтләнүләр, йогышлы чир белән күпләп авырулар, башбаштакланып китүләр, җинаятьләр

Җәрәхәтләр, йогышлы чир белән күпләп авырулар, башбаштакланып китүләр, җинаятьләр	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел
Җәрәхәтләр	75	72	32	145
Йогышлы чир белән күпләп авырулар	-	1	-	-
Башбаштакланып китүләр	18	10	8	3
Балигъ булмаганнар тарафыннан ял һәм савыктыру учреждениеләрендә кылынган җинаятьләр саны	-	-	-	-
Балигъ булмаганнарга карата ял һәм савыктыру учреждениеләрендә кылынган җинаятьләр саны	-	-	-	-

Җәйге савыктыру кампаниясе чорында ***күзәтчелек итү органнарының күбесендә, эшчәнлекнең өстенлекле юнәлеше буларак, балалар савыктыру лагерьларын тикшерү башлана.***

Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыруны бәяләүнең җитди критерие булып бу оешмаларның санитария-гигиена һәм санитария-эпидемиология иминлеге таләпләре һәм балаларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләре тора.

Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор белешмәләренә караганда, 2016 елгы җәйге савыктыру кампаниясе чорында 769 ял оешмасына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздырылган, бу, 2015 елның шул чоры белән чагыштырганда, 6,5 процентка артыграк (722 тикшерү), 3 408 (2015 елда – 3 972) хокук бозулар ачыкланган, бу фактлар буенча административ хокук бозулар турында 1 123 беркетмә һәм штраф салу турында карарлар (2015 елда – 1 025 беркетмә һәм карар) чыгарылган, кисәтүләр ясалган. Административ йогынты ясау чараларын куллануга түбәндәге хокук бозулар сәбәпче булды: тәүлеклек пробаны саклау шартлары һәм сроклары бозылу, ризык әзерләүнең технологик процесслары бозылу, аш бүлмәсе кирәк-яракларын, ашханә табак-савытын эшкәртү режимы бозылу; азык әзерләгәндә санитария кагыйдәләрен, технологияне үтәмәү, матди-техник җиһазлар (җайланмаларның төзек булмавы, йомшак инвентарь җитешмәү), территорияне, гомуми файдалану урыннарын, медицина хезмәте күрсәтү урыннарын карап тоту буенча кимчелекләр, эчәр су белән тәэмин итүдәге җитешсезлекләр.

Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең чистарту фильтрларын куюга рөхсәтләр бирү һәм бирелгән күрсәтмәләрен тикшереп тору буенча башкарылган эшенең нәтиҗәсе буларак, 2016 елгы җәйге ял кампаниясе вакытында эчәр суның сыйфаты яхшыруны билгеләп үтәргә кирәк.

2016 елда шулай ук бассейннардагы суларның сыйфаты яхшыру теркәлде: микробиологик күрсәткечләр буенча стандарт булмаган су пробалары 1,4 %ка кадәр (2015 елда – 3,9 %), санитар-химик күрсәткечләр буенча стандарт булмаган су пробалары 1,2 %ка кимеде (2015 елда – 2,1 %).

Балаларны тукландыруда җитешсезлекләр фактлагы рационда балык (3%), җиләк-җимеш (2%), соклар (2%) бирүнең тәкъдим ителә торган рационга туры килмәвендә һәм тәүлеклек рационның порцияләрен һәм калориясен 1 %ка киметүдә чагылды.

2016 елгы җәйге ял кампаниясендә санитария законнарын бозу сәбәпле ял итүче балалар арасында авырулар килеп чыгу һәм таралу куркынычы тууга бәйле рәвештә, суд карары нигезендә 2 ял оешмасының эшчәнлеге туктатылды, болар – «Левашово урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе тарафыннан оештырылган көндезге лагерь (Татарстан Республикасы Алексеевск районы) һәм индивидуаль эшкуар Хабаров Владислав Вениаминович

тарафыннан оештырылган 60 балага исәпләнгән «Безнең тарих» тарихи туган якны өйрәнү музее, ул Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Шуран авылында урнашкан иде.

Балаларның җәйге ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ел саен күзәтчелек ителә.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты Татарстан Республикасының 21 муниципаль районында (шәһәр округларында) урнашкан 37 (2015 елда – 30) ял оешмасын тикшерде, шул исәптән:

Саба муниципаль районында урнашкан ике савыктыру лагере («Олимп», «Солнышко» балалар савыктыру лагерьлары);

Апас муниципаль районында урнашкан «Свияга +» ҖЧҖ «Свияга» шифаханәсе;

Казан шәһәре тирәсендә урнашкан дүрт савыктыру лагере («Заречье», «Восток», «Гагарин ис. БСЛ» балалар савыктыру лагерьлары, «Ял» шәһәр үзәге» муниципаль учреждениесе, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Яшь гвардия» балалар савыктыру лагере);

«Иннополис университеты» автоном коммерциячел булмаган югары белем бирү оешмасының Югары Ослан муниципаль районында балалар лагере;

Зеленодольск муниципаль районында дүрт савыктыру лагере («Лето» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Мечта» балалар савыктыру лагере, «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесенең М.Җәлил исемендәге балалар савыктыру лагере, «Нурлат балалар йорты» ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен дәүләт белем бирү учреждениесенең «Теремок» җәйге лагере;

Алексеевск муниципаль районында «Дубок» савыктыру лагере;

Чистай муниципаль районында өч савыктыру лагере («Ровесник», «Солнышко» савыктыру лагерьлары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Березка» балалар савыктыру лагере);

Питрәч муниципаль районында «Чайка» савыктыру лагере;

Балык Бистәсе муниципаль районында «Сәйләп» савыктыру лагере;

Мамадыш муниципаль районында өч лагерь («Звездный десант» палаткалы лагере, «Кама» балалар савыктыру лагере, «Берсут» ачык акционер җәмгыятенең «Надежда» балалар савыктыру лагере);

Әтнә муниципаль районының «Чулпан» савыктыру лагере;

Балтач муниципаль районының «Романтик» савыктыру лагере;

Биектау муниципаль районында ике балалар савыктыру лагере («ЦИТО» ҖЧҖ «Байтик» балалар савыктыру лагере, «Лето» республика үзәге» дәүләт бюджет учрежденисенең «Чайка» балалар савыктыру лагере,);

Сарман муниципаль районында лагерьлар («Старт» ДЮСШ «Олимпийские надежды» лагере);

Чүпрәле муниципаль районында «Чайка» савыктыру лагере;

Буа муниципаль районында ике савыктыру лагере (Буа муниципаль районының «Чайка» савыктыру лагере, «Буа шикәр заводы» ААҖ «Бор» балалар савыктыру лагере);

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә дүрт савыктыру лагере («КАМАЗжилбыт» ЯАҖ «Крылатый» һәм «Солнечный» балалар савыктыру лагерьлары, «Фактор единства, созидания и творчества» яшьләр һәм балалар үсешенә ярдәм итү үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгының «Олимпия» балалар савыктыру үзәге, «Камдорстрой» УК ЯАҖ «Радуга» шифаханәсе каршындагы «Солнышко» балалар савыктыру лагере);

Лениногорск муниципаль районының «Дружба» балалар савыктыру лагере;

Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» балалар савыктыру лагере;

Зәй муниципаль районының «Созвездие» балалар савыктыру лагере;

Актаныш муниципаль районының «Бүләк» балалар савыктыру лагере.

Балалар сәламәтлегенә һәм иминлегенә куркыныч яный торган аеруча тупас кимчелекләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча 12 ял һәм савыктыру оешмасында түбәндәгеләр ачыкланды:

азык-төлек блоклары эшчәнлегенә, балаларны тукландыруга карата куелган таләпләрнең бозылуы (кителгән савыт-саба куллану, биналарның санитария кагыйдәләренә туры килмәве, азык-төлек продуктларын саклау шартларына, документлар тутыруга куелган таләпләрнең бозылуы, мәҗбүри документацияне алып бару (аның булу-булмавы), балаларны сыйфатлы ризык белән тәэмин итү зарурлыгы таләпләре үтәлмәү); (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Яшь гвардия» балалар савыктыру лагере, Саба муниципаль районының «Олимп» балалар савыктыру лагере, Питрәч муниципаль районының «Чайка» балалар савыктыру лагере; «Сәләт» яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учрежденисенең «Дубок» савыктыру лагере; Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» балалар савыктыру лагере; Этнә муниципаль районының «Чулпан» савыктыру лагере; «Берсут» ачык акционер җәмгыятьнең «Надежда» балалар савыктыру лагере;

Чүпрәле муниципаль районында «Чайка» савыктыру лагере; Актаныш муниципаль районының «Бүләк» балалар савыктыру лагере);

бинага, җайланмаларга, балалар яши торган бүлмәләрнең чисталыгына таләпләрнең бозылуы (Әтнә муниципаль районының «Чулпан» савыктыру лагере; «Берсут» ачык акционер җәмгыятенең «Надежда» балалар савыктыру лагере; Чүпрәле муниципаль районының «Чайка» савыктыру лагере; Питрәч муниципаль районының «Чайка» балалар савыктыру лагере;);

ял итүчеләрнең көн режимына куела торган таләпләрнең бозылуы (Саба муниципаль районының «Олимп» балалар савыктыру лагере, «Сәләт» яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Дубок» савыктыру лагере; Питрәч муниципаль районының «Чайка» балалар савыктыру лагере;);

тиешенчә рәсмиләштерелгән вазыйфаи инструкцияләрнең булмавы (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты физик культура һәм спорт комитетының «Яшь гвардия» балалар савыктыру лагере; «Берсут» ачык акционер җәмгыятенең «Надежда» балалар савыктыру лагере; Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» балалар савыктыру лагере; Лениногорск муниципаль районының «Дружба» балалар савыктыру лагере;);

балаларны сәламәтлеккә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешкә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турындагы законнар таләпләрен бозу, шул исәптән «Интернет» челтәреннән файдалана алуның сакланмаган каналлары булу («Камдорстрой» УК ЯАҖ «Радуга» шифаханәсе каршындагы «Солнышко» балалар савыктыру лагере; Актаныш муниципаль районының «Бүләк» балалар савыктыру лагере);

балаларның иминлеге һәм сәламәтлеге таләпләре, шул исәптән террорга каршы иминлек таләпләре тиешенчә тәэмин ителмәү – лагерь территориясе бүлеп алынмау анда башка затларның тоткарлыксыз керүе, балаларның контрольсез теләсә-кая чыгып йөрүләре, шулай ук балигъ булмаганнарның качып китүләре өчен шартлар тудыра («Фактор единства, созидания и творчества» яшьләр һәм балалар үсешенә ярдәм итү үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгының «Олимпия» балалар савыктыру үзәге, Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» балалар савыктыру лагере; Чүпрәле муниципаль районының «Чайка» савыктыру лагере);

медицина пунктын булдыру һәм аның эшен оештыру таләпләре бозылу (Әтнә муниципаль районының «Чулпан» савыктыру лагере; («Фактор единства, созидания и творчества» яшьләр һәм балалар үсешенә ярдәм итү үзәге», Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» балалар са-

выктыру лагере; Лениногорск муниципаль районының «Дружба» балалар савыктыру лагере; Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Яшь гвардия» балалар савыктыру лагере).

Санап кителгән фактлар югарыда телгә алынган оешмаларда балаларның санитария-гигиена һәм санитария-эпидемиология таләпләре үтәлгән уңайлы әйләнә-тирә мохиттә, гомергә һәм сәламәтлеккә зыян китерми торган шартларда ял итү һәм савыгу хокукын тиешенчә тәэмин итмәү турында сөйли.

Ачыкланган хокук бозу фактлары буенча ял оешмаларының җитәкчеләренә, гамәлгә куючыларына Балалар хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмәләр җибәрелде, аларда табылган кимчелекләрне бетерү, алга таба аларны булдырмау һәм балаларның гомере һәм сәламәтлеге өчен имин шартларда, уңайлы мохиттә ял итүгә хокукларын тиешенчә тәэмин итү турында тәкъдимнәр бирелде.

Шул ук вакытта санитария-эпидемиология таләпләрен бозуның республиканың барлык ял һәм савыктыру оешмалары өчен хас булган төрләре дә бар. Моңа азык-төлек блоклары һәм балаларны тукландыру таләпләренең үтәлмәве, шулай ук балаларның ялын һәм аларны савыктыру буенча стационар оешмаларга куелган таләпләрнең үтәлмәве керә. Шулай ук балалар оешмаларындагы җитәкчеләрнең һәм җаваплы хезмәткәрләрнең компетенциясе югары булмау игътибарны җәлеп итә.

Шул уңайдан, Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенә җәйге ял кампаниясенә әзерлек барышында лагерь җитәкчеләрен һәм җаваплы хезмәткәрләрне санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына өйрәтүне оештыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәбез.

Балаларның оештырылган ялы вакытында тәрбия һәм танып белү аспекты мөһим урын алып тора. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил лагерьлар эшчәнлеген тикшергәндә тәрбия эшчәнлеге кысаларында үткәрелә торган ***мәдәни-күңел ачу чаралары да бәяләнде***.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, тәрбия эшчәнлеге программалары күп лагерьларда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 ноябрендәге 2403-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәрге чорда Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә тәрбия эшен үстерү стратегиясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү концепциясе нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чараларын истә тоту кирәклегеннән чыгып, эшләнеп бетәргә тиеш.

Әгерҗе муниципаль районының «Алмалы» балалар савыктыру лагеренда, Лениногорск муниципаль районының «Дружба» балалар савыктыру лагеренда, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Яшь гвардия» балалар савыктыру лагеренда тәрбия эше программасы бөтенләй булмады.

Савыктыру кампаниясенең уңышлы булуында белеп һәм сайлап алынган ***кадрлар составының роле*** бик зур. Шул уңайдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларның җәйге ялын оештыру оешмаларын тикшергәндә педагогик һәм техник персоналны эшкә алганда Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331, 351.1 статьялары таләпләренең үтәлү-үтәлмәвенә, ягъни эшкә кабул иткәндә аларның хөкем ителгән булу-булмавына һәм (яки) аларга карата җинаять эзәрлекләвенең кулланылу-кулланылмавына яисә билгеле бер җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләве туктатылуына игътибар итә. 2016 елгы җәйге ял кампаниясен тикшерү күрсәткәнчә, бу таләп барлык оешмаларда да тулысынча үтәлмәде. Әлеге хокук бозулар буенча республиканың муниципаль берәмлекләре җитәкчеләренә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү зарурлыгы һәм балалар ялының һәм аларны савыктыруның куркынычсызлыгын тиешенчә тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү кирәклеге турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бәяләмәләре юлланды.

Балаларның җәйге ялын оештыру эшчәнлеген педагогик һәм тәрбия ягыннан чыгып караганда, персоналның квалификация дәрәҗәсен һәм компетентлылыгын Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 2016 елгы җәйге ял кампаниясен тикшергәндә ачыкланган түбәндәге вәзгыять бик ачык күрсәтә.

Мисал. Чаллы шәһәре «Камдорстрой» УК ЯАҖ «Радуга» шифаханәсе каршындагы «Солнышко» балалар савыктыру лагеренда, балалар дискотекасы башланыр алдыннан агрессив сексуаль характердагы җырлар яңгыраган. Очраклы рәвештә генә бу хәлләрнең шаһиты булган ата-аналар белән сөйләшкәндә ди-джей, бу җырларны ял итә торган балалар үтенече белән куелуын аңлаткан һәм аларның үтенеченнән баш тарта алмавын белдергән. Моннан тыш, лагерьда эшләү дәверендә соңгы өч елда куела торган җырларның балалар алдында тыңланырга тиеш түгеллеге хакында аңа беркем дә кисәтү ясамаган һәм ул, лагерь җитәкчеләреннән тиешле күрсәтмә булмаган очракта, традицияләренә үзгәреш кертергә җыенмый. Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан саклау буенча аңлату чаралары ди-джей белән үткәрелмәгән.

2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясен гамәлгә ашыруның «җәйге ялны оештыруга җәлеп ителә торган сертификацияле педагоглар саны» индикатив күрсәткечләрен үтәү балаларның ялын һәм аларның савыктыруны

оештыру сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерие булып тора. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча һәм спорт министрлыгы белешмәләре буенча, 2016 елда бу күрсәткеч 100 процент тәшкил итте, ул 2016 елга билгеләнгән индикатив күрсәткечкә (120%) туры килми.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча һәм спорт министрлыгына, «Лето» балаларны һәм яшүсмерләрне савыктыруны, аларның ялын һәм эш белән тәэмин ителешен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә түбәндәгеләрне тәкъдим итүне максатка ярашлы дип саный:**

1. Балаларның ялын оештыруга методик ярдәм итүне арттырырга;

2. Балаларның ялын оештыручылар өчен түбәндәгеләргә кагылышлы методик тәкъдимнәр эшләргә:

балаларны аларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында «Россия Федерациясендә балалар хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законда, «Балаларны аларның сәламәтлегенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән таләпләрне үтәү;

тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә заманча норматив хокукый базаны исәпкә алып, балаларның ялын оештыруны камилләштерү;

3. Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләрне балаларның ял оешмаларында эшләү өчен педагогик персонал әзерләгәндә үткәрелә торган өйрәтү семинарларына кертергә, «Әйдәман мәктәбе», лагерь башлыклары, балаларның ялын оештыру буенча район һәм шәһәр ведомствоара комиссияләр, мәгариф, яшьләр эшләре буенча һәм спорт идарәләре (бүлекләре) югары уку йортлары вәкилләре өчен ел саен семинар-киңәшмәләр үткәрергә.

4. Балалар ялын оештыруны җайга сала торган норматив хокукый документлар таләпләрен үтәү мәсьәләләрен балалар ялын оештыручылар белән җентекләп эшләргә, бу документларга түбәндәгеләр керә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331, 351.1 статьялары (эшкә урнаша торган педагогик һәм техник персоналның хөкем ителгән булу-булмавына һәм аңа карата җинаять җаваплылыгы булу-булмау йә аерым төр җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгы туктатылу фактлары буенча үзвакытында һәм тиешенчә тикшерү өлешендә);

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 212 статьясы (хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау өлешендә);

Россия Федерациясе Су кодексы, «Су объектын кулланылышка тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында» 2006 елның 30 декабрендәге 844 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында халыкның гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары таләпләре;

балаларның ял һәм савыктыру лагерьларын оештыруга, карап тотуга һәм эшчәнлеген оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре (СанПиН 2.4.4.3155-1);

балаларның палаткалы лагерьларын оештыруга, карап тотуга һәм эшчәнлеген оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре (СанПиН 2.4.4.3048-13);

Россия Федерациясе ГХМ 2009 елның 25 мартындагы 179 номерлы боерыгы белән расланган Кагыйдәләр җыелмасы «СП 9.13130.2009. Кагыйдәләр җыелмасы. Янгын сүндерү техникасы. Янгын сүндергечләр. Куллану таләпләр»

5. Татарстан Республикасына югары белем бирүче уку-укыту оешмаларына өстәмә белем бирү мөмкинлекләрен, иҗтимагый һөнәрләр факультетларын, студентларның тиешле белгечлекләр буенча үтәлә торган мәҗбүри педагогик практикаларын файдалану аша студентларны балаларның ял итү оешмаларында эшләргә әзерләү мәсьәләсен карауны тәкъдим итәргә;

6. Педагогик һәм профильле һөнәри белем бирү оешмаларының махсус әзерлек үткән студентларын каникул чорында балалар белән эшләүгә күбрәк һәм активрак җәлеп итәргә.

2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең илкүләм стратегиясендә балаларның ялын һәм савыгуын оештыруның заманча модельләрен булдыру чараларының берсе буларак ***балаларның барлык категорияләре өчен аларның индивидуаль ихтыяҗларыннан чыгып ял итү һәм савыгу мөмкинлегенең булуы, инвалид балаларның һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ялы һәм савыгуы программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру*** билгеләнгән.

Әлеге принциплар 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясендә дә чагылыш тапты.

Әйтелгәннәрне истә тотып, балаларның ялы һәм аларны савыктыру кампаниясе йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ел саен сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ял һәм са-

выктыру системасын үстерү буенча алынган йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итү чараларын күрү кирәклеге турындагы мәсьәләне күтәрә.

Шулай булуга карамастан, соңгы елларда бу өлкәдәге хәлләр түбәндәгечә:

гамәлдәге лагерьларның булган инфраструктурасы торышы һәм штатта кирәкле белгечләрнең булмавы ишетү, күрү, сөйләм бозылу, терәк-хәрәкәт функцияләре бозылган, акылга зәгыйфь балаларның ялын, шул исәптән инклюзия принципларында сәламәт балалар белән бергә оештырырга мөмкинлек бирми;

республикада инвалид балалар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен бер генә лагерь да юк;

инвалид балаларга һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларга җайлаштырылган шәһәр яны ял итү лагерьларының саны дүрт ел дәвамында өч булып кала.

Шулай итеп, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча һәм спорт министрлыгы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Социаль ярдәм министрлыгы белән берлектә сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ял итүгә хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү мәсьәләсен карарга, өйрәнергә һәм чаралар күрергә тиеш дип саный.

3.3. Баланың гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукын тәэмин итү

Иң төп һәм иң нигези бала хокукларының берсе аның яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукы. Бала хокуклары турында БМО конвенциясенә кушылып, безнең ил түбәндәгеләрне бурыч итеп алды: «баланың, аның ихтыярына каршы килеп, үз ата-анасыннан аерылуын булдырмауны тәэмин итәргә тиеш моңа кулланыла торган законга һәм процедураларга ярашлы рәвештә суд карары буенча компетентлы органнар тарафыннан мондый аеруның баланың уңай мәнфәгатьләрен кайгырту йөзеннән кирәк булуы билгеләнгән очраклар керми». Россия Федерациясе гаилә законнары нормалары һәр балага гаиләдә яшәү һәм тәрбияләнү хокукын, үзенең ата-анасын белү хокукын, аларны кайгырту хокукын, аларның мәнфәгатьләренә каршы килмәгән очракта, бергә яшәү хокукын гарантияли. Бу хокукны үтәмәү бала өчен фаҗига булып тора, чөнки аларны үтәмәү аеруча тупас хокук бозуларга керә һәм катгый рәвештә җайга салу чараларын күрүне һәм профилактикалауның, торгызуның нәтиҗәле механизмнарын таләп итә.

3.3.1. Начар гаилә проблемалары

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил фикеренчә, балачакны яклауның иң актуаль заманча бурычларының берсе гаилә бәхетсезлеген җиңү буенча гамәли чаралар күрүдән һәм нәтиҗәле механизмнарны гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

Гаиләнең уңышсызлыгы бүген ятимлекнең, балигъ булмаганнар арасындагы җинаятьчелекнең һәм балигъ булмаганнарга карата җинаять кылуларның, үз балаларын тәрбияләү, тоту һәм карау буенча ата-ана вазыйфаларын тиешенчә башкармаганлыктан балаларның физик һәм психик сәламәтлегенә зыян салуның төп сәбәбе булып тора. Шуны исәпкә алып, гаиләдә балалар проблемаларын профилактикалау һәм җиңү эшчәнлеге тиешле органнар тарафыннан актив ведомствоара хезмәттәшлек белән максатчан оештырылырга тиеш.


Формаль яктан уңышсыз гаиләләргә балигъ булмаган балалары булган һәм профилактик ведомство йә ведомствоара исәпнең бер яисә берничә төрендә торучы гаиләләр керә.

Ведомство исәбе социаль яклау органнары, ТР буенча ЭЭМ балигъ булмаганнарның эшләре бүлекчәләре тарафыннан алып барыла. Ведомствоара исәп балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм аеруча проблемалы социаль гаиләләр белән профилактик эш алып баруны күздә тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 ел ахырына социаль яклау органнарында ведомство исәбенә алынган, балигъ булмаган балалары булган һәм төрле авыр яшәү шартларына юлыккан гаиләләрнең саны артты һәм 5 963 гаилә тәшкил итте. Мондый гаиләләрдә 2016 елда барлыгы 9 693 бала яшәгән, бу 2015 ел белән чагыштырганда 682 кешегә ким. Мондый балалар гомуми балалар санының 1,2% алып тора (2015 елда 1,3% иде) .

78 нче диаграмма


2013–2016 елларда социаль яклау органнарының ведомство исәбендә торган гаиләләрнең һәм аларда тәрбияләнүче балаларның саны



Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ статистика мәгълүматлары 2016 елда балигъ булмаганнарның эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торучы гаиләләр саны 16,2% ка артты һәм аларда яшәүче балалар саны 16,7% ка артты. Мондый балалар гомуми балалар санының 0,9% ын тәшкил итә. (2015 елда бу күрсәткеч 0,5% тәшкил иткән иде).

79нчы диаграмма


2011–2016 елларда балигъ булмаганнарның эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торган гаиләләр һәм аларда яшәүче балалар саны



«Социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне исәпкә алу һәм мониторинглау» бердәм мәгълүмат банкында ведомствоара исәптә торучы гаиләләр аеруча борчый. Кызганычка каршы, социаль куркыныч шартларда яшәүче балаларның саны 2015 ел белән чагыштырганда 27% булды һәм 1 353 гаиләне тәшкил итте. Социаль куркыныч халәттә яшәүче балалар саны 2016 елда 2 584 булды, 2015елдагы күрсәткечкә карата 27% ка кимрәк. Мондый балалар гомуми балалар санының 0,3% ын тәшкил итә (2015 елда – 0,4%).

80 нче диаграмма

2011–2016 елларда социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрнең һәм аларда тәрбияләнүче балаларның саны



Шулай итеп, 2016 ел ахырына Татарстан Республикасында:

9 905 гаилә төрле төрдәге исәпләрдә торган;

16 087 бала, яки балаларның гомуми санының 2%, төрле дәрәҗәдәге начар гаиләләрдә яшәүләрен дәвам иткән. Соңгы ике елдагы начар гаиләләр мониторингы төрле рәсми исәпләрдә торучы гаиләләрнең гомуми саны 361 гаиләгә яисә 3,5%, ка кимүне, ә шундый шартларда яшәүче балалар санының 1900 га яисә 10,7% кимүен күрсәтә.

Органнарның – балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларының (алга таба – профилактика субъектларының) гаиләләрнең начар яшәү шартларын иртә ачыклау эшчәнлегенә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2013 елдан бирле аерым игътибар бирә. Бу эшнең күпмедер дәрәҗәдә нәтиҗәсе бар, 2014 – 2016 еллар дәвамында профилактика субъектлары эшендә уңай үзгәрешләр күзәтелде:

тулаем республикада законнарда билгеләнгән очракларда ата-аналардан балаларын тартып алу процедурасын үткәрү тәртибе билгеләнде;

начар гаиләләрне тернәкләндерү сроклары кыскартылды;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең һәм муниципаль ведомствоара социаль-тернәкләндерү консилиумнарының вәкаләтләре төгәлләштерелде һәм эшчәнлеге активлаштырылды;

2013 елдан «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» ведомствоара мәгълүмат системасы кертелде;

балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр һәм балалар белән эшләүгә юнәлдерелгән эшен координацияләүне камилләштерү максатларында Республика мәгълүмат-методика үзәге белән берлектә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы тарафыннан төрле категориядәге гаиләләр һәм социаль куркыныч хәлдәге балалар белән эшләү буенча балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары эшчәнлегенең алгоритмнары эшләнде:

1) гаиләнең алкоголизациясе очрагында;

2) бала белән кырыс аралашканда;

3) балигъ булмаганнар хокук бозганда;

4) бала суицидка омтылганда.

Алгоритмнар Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең 2016 елның 13 июлендәге 18-16 номерлы карары белән расланды.


Шуның белән бергә, гаиләләрнең һәм балаларның начар яшәү шартларын профилактикалау системасы субъектлары эшчәнлеге һаман да тиешле дәрәҗәдә алып барылмый һәм камилләштерүне сорый.

Беренчедән, начар гаиләләрне тернәкләндерү эшчәнлегенең сыйфатын билгели торган төп критерий – ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар санының кимүе мондый эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген күрсәтә.

Ләкин 2014 елдан ачыкланган ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар санының арту тенденциясе күрсәтелә. 2016 елда абсолют ачыкланган социаль ятимнәрнең саны 885 гә җитте, бу 2015 ел белән чагыштырганда 12%ка артык (2014 елда – 781 бала, 2015 елда – 791).

81нче диаграмма

2008 –2016 елларда ачыкланган ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның саны



Бу күрсәткечләр 2016 елда гаилә бәхетсезлеген профилактикалау эшчәнлегендә формасы һәм эчтәлеге буенча да уңай үзгәрешләр бар дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Икенчедән, органнар – профилактика субъектлары эшчәнлегендә начар гаиләләрне үз вакытында ачыклап өлгермәү һәм ата-аналарга авыр тормыш хәленнән чыгу буенча индивидуаль тернәкләндерү ярдәмен күрсәтүне үз вакытында оештырмау тәҗрибәсе дәвам итә.

2016 елда мәгълүмат системасы ярдәмендә 3 729 гаиләгә сигнал карталары җибәрелде, шуның 1 157се социаль куркыныч хәлдәге гаилә буларак ведомствоара исәпкә куелды (җибәрелгән сигнал карталарының 31%ы), шул исәптән:

эчке эшләр органнары – 1 653 сигнал картасы (җибәрелгән сигнал карталарының 44,3%), 504 гаилә исәпкә куелды (җибәрелгән сигнал карталарының 30,5%);

социаль яклау органнары һәм учреждениеләре – 958 сигнал картасы (җибәрелгән сигнал карталарының 25,7%), 310 гаилә (32,3% җибәрелгән сигнал карталарының);

мәгариф идарәсе органнары – 359 сигнал картасы (9,6%), 102 гаилә исәпкә куелды (28,4%);

сәламәтлек саклау идарәсе органнары – 322 сигнал картасы (8,6%), 75 гаилә исәпкә куелды (23,3%);

опека һәм попечительлек органнары – 220 сигнал картасы (5,9%), 68 гаилә исәпкә куелды (31%);

җинаятькә каршы-башкарма инспекциясе – 44 сигнал картасы (1,2%), 32 гаилә исәпкә куелды (72,7%);


авыл җирлекләре башлыклары (хезмәткәрләр) – 34 сигнал картасы (0,9%), 11 гаилә исәпкә куелды (32,3%);

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр – 120 сигнал картасы (3,2%), 39 гаилә исәпкә куелды (32,5%);

башка оешмалар (башка муниципаль берәмлекнең муниципаль социаль-реабилитация консилиумы, ведомствоара рейдлар һ.б.) – 19 сигнал картасы (0,5%), 16 гаилә исәпкә куелды (84,2%).

82 нче диаграмма

2016 елда «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына органнарга – профилактика субъектлары җибәргән сигнал карталары саны



Шуның белән бергә, гаилә бәхетсезлеген алданрак профилактикалау эшчәнлеге активлыгының түбән булуын, беренче чиратта авыл җирлекләре башлыкларының (вазыйфаи затларның), шулай ук мәгариф, сәламәтлек саклау, опека һәм попечительлек органнарының активлыгы түбән булды.

2016 елда түбәндәгеләр тарафыннан бер генә дә сигнал картасы җибәрелмәде:

сигез муниципаль районның мәгариф идарәсе органы тарафыннан: Әлки, Апас, Чүпрәле, Мөслим, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Сарман, Теләче;

ундүрт муниципаль районның (шәһәр округы) опека һәм попечительлек органнары тарафыннан: Әгерҗе, Әлки, Апас, Әтнә, Чүпрәле, Зәй, Лениногорск, Яңа Чишмә, Саба, Сарман, Тукай, Теләче, Чаллы шәһәре, Казан шәһәре (Вахитов районы);

дүрт муниципаль районның (шәһәр округы) эчке эшләр органнары тарафыннан: Кама Тамагы, Яңа Чишмә, Ютазы, Казан (Авиатөзелеш районы);

тугыз муниципаль районның сәламәтлек саклау идарәсе органнары: Аксубай, Әлки, Апас, Буа, Кама Тамагы, Мөслим, Тәтеш, Теләче, Ютазы.

Алай гына да түгел, органнар – профилактика субъектлары профилактикалау системасы субъектларының (алга таба – профилактика субъектларының) гаиләләрнең начар яшәү шартларын иртә ачыклау эшчәнлегенә карата битарафлык, эшлексезлек күрсәтә.

Тиешле органнарның – профилактика субъектларының актив гражданардан, туганнардан, башка чыганаклардан гаиләдәге тавыш турында җиткерелгән мәгълүматка игътибар итмәү фактлары бар.

Мисал. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына инвалид бала И.ның әбисе баланың начар гаиләдә тәрбияләнүе турында хәбәр итте, баланың анасы Я. аны тәрбияләү белән шөгыльләнми ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәми. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инвалид баланың яшәү шартларын тикшерү һәм аның мәнфәгатьләрен яклау буенча җитди чаралар күрү турында Яңа Чишмә муниципаль район органнарына мөрәҗәгать итте. Ләкин гаиләдәге хәлләрне өйрәнү һәм инвалид бала файдасына берәр төрле чара күрү турында хәбәр ителмәде. Эш визиты кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Я. гаиләсендә булды. Баланың начар шартларда яшәве ачыкланды, шуңа күрә социаль хәтәр хәлдә булганлыктан гаилә ведомствоара исәпкә куелды. Берникадәр вакыттан соң баланың гомеренә куркыныч яный торган вәзгыять барлыкка килде, шунлыктан бала анадан тартып алынды һәм тәрбиягә әбисенә бирелде. Анасына карата опека һәм попечительлек органнарына ана хокукларын чикләү турында судка дәгъва гаризасы җибәрелде. Гаилә проблемаларын вакытында ачыкламау, органнар – профилактика субъектлары тарафыннан тиешле реабилитация чаралары күрмәү баланы туган гаиләсеннән мәхрүм итүгә китерде.

Бала яши торган гаилә белән тиешле профилактик эшләр оештырмыйча ата-аналар яисә балалар гаризасы буенча йә тиешле органнар карары белән балаларны проблемалы гаиләләрдән тартып алу практикасы дәвам итә. Республика социаль приютларын тикшерүләр барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил социаль приютларга дәүләт кайгыртуына вакытлыча урнаштырылган балаларны яши торган гаиләләрнең исәпкә куелмавын һәм шундый гаиләләргә реабилитация чараларының күрелмәвен билгеләп үтте. Мондый очраклар 2016 елда түбәндәге районнарның органнарында – профилактика субъектларында ачыкланды:

Алексеевск муниципаль районы;
Апас муниципаль районы;
Аксубай муниципаль районы;
Биектау муниципаль районы;
Буа муниципаль районы;
Чүпрәле муниципаль районы;
Алабуга муниципаль районы;
Зеленодольск муниципаль районы;
Кама Тамагы муниципаль районы;
Лаеш муниципаль районы;
Менделеевск муниципаль районы;
Нурлат муниципаль районы;
Балык Бистәсе муниципаль районы;
Чирмешән муниципаль районы;
Чистай муниципаль районы;
Тукай муниципаль районы;
Казан шәһәренең Совет районы.

Һәр шундый очрак буенча адекват йогынты ясау чаралары күрелде.

2016 елда гаиләләрдә проблемаларны ачыклау буенча кайбер органнарның – профилактика субъектларының эше тиешенчә куелмаганлыктан балаларга карата җинаять очраклары урын алды.

Мәсәлән, 2016 елның июлендә Алексеевск муниципаль районында Ч. гаиләсендә этил спирты белән агуланып ике айлык бала үлгән. Шуның белән бергә ана кешенең гаризасы белән ике балигъ булмаган (2005 һәм 2015 елгы балалар) баласы, авыр тормыш сәбәбенә бәйле рәвештә «Кайгырту» ГКУ яшүсмерләр өчен социаль приютка» һәм Сабыйлар йортына урнаштыра, 2014 елда Ч.гаиләсендә 2 айлык бала шулай ук вафат була. Ләкин 2016 ел дәвамында гаиләне исәпкә куярга һәм авыр тормыш хәлен җиңеп чыгу буенча эш оештырырга бөтен нигезләр дә була: 2016 елда ике өлкән баласы социаль приютка җибәрелә, ләкин гаилә профилактика субъектлары тарафыннан контрольгә алынмый; сабый туганнан соң аңа медицина хезмәткәре тарафыннан өйдә патронаж оештырылган булса, балага карата даими рәвештә алкоголь куллану сизелмичә калмаган булыр иде.

Ләкин социаль яклау органнары да, сәламәтлек саклау органнары да бу гаиләне күрми һәм аның белән профилактик реабилитация чаралары үткәрелми. Гаиләдәге вәзгыять баланың агуланып һәлак булуы белән тәмамлана. Безнеңчә, мондый очракларда органнарның – профилактика субъектларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә җинаятьчел битарафлык күзлегеннән караганда кузгатылган җинаять эшләре кысаларында бәя бирү өчен барлык нигезләр дә бар.

Шушы уңайдан, балалар проблемаларын профилактикалау органнарының – субъектларының гаиләләрдәге проблемаларны вакытында ачыклаган һәм аларны җиңеп чыгу буенча нәтиҗәле эш оештырган өчен җаваплылыгын арттыру зарурлыгына игътибар итте.

Өченчедән, *балаларны гаиләдән тартып алу вәзгыятен* мониторинглау бу өлкәдәге эшнең җитәрлек булмавын дәлилли.

Гаиләләрдән балаларны тиеш булмаган органнар тарафыннан һәм билгеләнгән тәртипне бозып:

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр карарлары нигезендә, опека һәм попечительлек органнары, башка органнар – профилактика субъектлары үтенечнамәләре нигезендә.

Федераль законнар нигезендә балаларны гаиләдән тартып алу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы нигезендә опека һәм попечительлек органнары карары белән;

Эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрнең балигъ булмаганнарның сукбайлыгы һәм күзәтүчесез калуы турындагы актлар буенча ачыкланулары;

Авыр тормыш хәленә бәйле ата-аналар гаризасы буенча институциональ учреждение биналарына (социаль приютларга, балалар йортларына, сабыйлар йортына) урнаштыру;

Балигъ булмаган бала гаризасы буенча институциональ учреждение биналарына (социаль приютларга, балалар йортларына, сабыйлар йортына) урнаштыру.

Ләкин республика социаль приютларында тәрбияләнүче балаларны өйрәнү барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан социаль приютларга балаларны тиешсез органнарның (вәкаләтләрне арттырып) һәм билгеләнгән тәртипне бозып тартып алу очраклары барлыгы ачыкланды. Шуларның иң таралганнары:

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр карарлары нигезендә – алар түбәндәге муниципаль комиссияләр эшчәнлегендә очрады:

Алексеевск муниципаль районы ;

Аксубай муниципаль районы ;

Буа муниципаль районы ;

Биектау муниципаль районы;

Чүпрәле муниципаль районы;

Алабуга муниципаль районы;

Зеленодольск муниципаль районы;

Нурлат муниципаль районы;

Кама Тамагы муниципаль районы;

Чистай муниципаль районы;

Балык Бистәсе муниципаль районы;

опека һәм попечительлек органнары карарлары буенча – алар түбәндәге опека һәм попечительлек органнарында очрады;

Балык Бистәсе муниципаль районы;

Алабуга муниципаль районы;

Менделеевск муниципаль районы;

Чистай муниципаль районы;

Чирмешән муниципаль районы.

Асылда, күрсәтелгән органнарның гаиләдән балаларны алуның һәр очрагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан акланды һәм балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатында дип табылды. Ләкин аларны юридик яктан рәсмиләштерү законга таянып эшләнмәгән иде.

Кызганычка каршы, 2016 елда гаиләдән балаларны алу очракларын гомумиләштерү тартып алу буенча билгеләнгән тәртипнең системалы рәвештә бозылуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. 2016 елда законнарда билгеләнгән тәртиптә гаиләләрдән 1 022 бала тартып алынды:

63 бала Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы нигезендә;

362 бала – сукбай һәм күзәтүчесез балигъ булмаган бала гаризасы буенча;


517 бала – ата-ана гаризасы буенча;

80 – балалар гаризасы буенча.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 елда социаль приютлар барлыгы 1993 балага (ә бу гаиләләрдән тартып алынган балаларның гомуми саны) хезмәт күрсәткән. Гомуми алганда кимүгә таба барса да, приютларның социаль-реабилитация хезмәтләренә ихтыяҗ бар, ел саен 2 меңгә якын бала аларда тәрбияләнә.

83 нче диаграмма

2011 - 2016 елларда социаль приютларда (социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә) хезмәт күрсәтелгән балалар саны динамикасы



Шулай итеп, 900 гә якын бала гаиләдән законсыз нигездә тартып алынган: балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр карарлары нигезендә һәм үтенечнамәләре буенча; опека һәм попечительлек органнары үтенечнамәләре буенча, сәламәтлек саклау, мәгариф органнары учреждениеләре, һәм башкаларның үтенечнамәләре буенча.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күзәтчелек эшчәнлеге практикасыннан күренгәнчә, бу эшләрнең күпчелеге нигезле рәвештә башкарылса да, юридик яктан дөрес рәсмиләштерелмәгән.

Баланы гаиләдән законсыз нигездә тартып алу фактларына (вәкаләтләрне арттырып яисә билгеләнгән тәртипне бозып) юл куелмаска тиеш һәм аларга карата йогынты ясау чаралары күрелергә тиеш.

Дүртенчедән, хәтәр төркемгә керүче гаиләләр белән эшләү сыйфатына, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр тарафыннан әлеге эшне оештыруда тулы контрольнең булмавы җитди кимчелекләр булуын дәлилли.

1) кызганычка каршы, элеккечә, индивидуаль тернәкләндерү программаларын (алга таба – ИТР) төзегәндә һәм чараларын үткәргәндә билгеле бер калыплардан чыгып кына эш йөртелә), бу балалар өлкәсендә эшләүче белгечләрнең квалификациясе түбән булуны һәм үз вазыйфаларына салкын карауны раслый. Мәсәлән, гаиләләрнең начар тормышлы булу сәбәпләренә ясалган анализ начар гаиләләрнең авыр һәм куркынычлы яшәү шартларында калуның төп сәбәбе – ата-аналарның алкогольле эчемлекләр белән мавыгуы. Начар гаиләләрне тернәкләндерү эшенең индивидуаль программасына алкоголизм бәйлелегеннән дәвалауның кермәве дә гаҗәп тоела. Ә бу программаның башка тернәкләндерү чараларын үткәрүнең мәгънәсезлек икәнен раслый торган позициясе. Иң төп проблема эшсезлек булган очракта да , эшкә урнаштыру турында бер генә пункт та юк.

> ***Мисал.*** *Менделеевск муниципаль районындагы» «Камские зори» социаль приюты» ГКУ да тәрбияләнүчеләрнең шәхси эшләрен өйрәнгәндә, тәрбияләнүчеләр ИТРтөзүгә формаль якын килделәр, балигъ булмаганнарга һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) авыр тормыш хәленнән котылу өчен социаль, психологик һәм башка ярдәм күрсәтү буенча ведомствоара эшнең алып барылмавын күрсәтәләр. ИТР чаралары социаль яклау органнары үткәрә торган, күбесенчә лекция уку, нигездә алар әңгәмә, алкоголь турында, ата-ана алкоголизмы, аларның эшкә урнашулары турында сөйләшүләр алып баралар.*

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр эшчәнлегендә ведомствоара исәптә торучы уңышсыз гаиләләрнең нәтиҗәле адекват ИТРларын төзү эшенең җитәрлек булмавын билгеләп үтәргә кирәк:

Алексеевск муниципаль районы;
Актаныш муниципаль районы;
Югары Ослан муниципаль районы;
Алабуга муниципаль районы;
Мамадыш муниципаль районы;
Менделеевск муниципаль районы;
Яңа Чишмә муниципаль районы;
Спас муниципаль районы;
Балык Бистәсе муниципаль районы;
Теләче муниципаль районы;
Чирмешән муниципаль районы.

2. Проблемалы гаиләләрне тернәкләндерү эшенең тиешле дәрәҗәдә оештырылмавы турындагы нәтиҗәне гаиләләрнең социаль авыр хәлдә буларак ведоствоара исәптә торуына анализ ясаудан да күрергә мөмкин. Мәсәлән, тикшерү барышында ел дәвамында социаль авыр хәлдә буларак тернәкләндерү эше 1-2 ел алып барылган гаиләләр барлыгы ачыкланды.


Социаль приютларда тәрбияләнүче балалар белән тернәкләндерү эшенең ай саен ясала торган мониторинг йомгакларыннан күренгәнчә, балигъ булмаганнарны социаль тернәкләндерүнең уртача срогы, 2015 ел белән чагыштырганда кимүгә һәм 5,4 айга калуга карамастан, приютта 474 бала 6 айдан алып бер елга кадәр, 80 бала елдан артык яшәгән (2015 елда – 63 бала). Безнең фикеребезчә, социаль приютларда яшәүче балигъ булмаганнарның тормышларын алга таба урнаштыру бурычларын тиз арада хәл итүгә комачаулый торган төп сәбәпләргә, элеккечә, гаиләдә тернәкләндерү чараларын оештыруның һәм уздыруның нәтиҗә бирми торган һәм һөнәри дәрәҗәдә булмаган алымнарын куллануда керә.

3. Начар гаиләләрне тернәкләндерү эшчәнлегенең сыйфатын билгели торган төп критерийны мондый эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге күрсәтә.

2013 – 2016 еллардагы ведомствоара мәгълүмат системасындагы исәптән төшерүнең нигезләрен анализлау һәр елны, уртача алганда, гаиләләрнең якынча 81,5% ның, тернәкләндерү уңай барганга күрә, исәптән төшерелүен күрсәтте. калган очракларда исәптән төшерү гаиләгә карата ата-аналарның ата-ана хокукларын чикләү яисә аларны ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында карарлар кабул ителүгә бәйле. 2015 ел белән чагыштырганда 2016 елда уңай тернәкләндерү нигезендә исәптән төшерелгән гаиләләр саны 84,7% тан 82,2% ка кадәр кимегән. Димәк, уңай тернәкләндерүгә ирешмичә исәптән төшерелгән гаиләләр саны арткан.

84нче диаграмма

2013-2015 елларда гаиләләрне ведомствоара исәптән төшерү нигезләре динамикасы



Монда социаль куркыныч хәлдә булган гаилә буларак 2016 елда кабат ведомствоара исәпкә куелган гаиләләрнең саны игътибар җәлеп итә. Әгәр 2015 елда 73 гаилә кабат исәпкә куелган булса (143 бала), 2016 елда 71 шундый гаилә теркәлгән (147 бала).

Шул ук вакытта бала өчен «туган» гаиләсен саклап калу күзлегеннән караганда, тернәкләндерүнең төп бурычы , балаларның мәнфәгатьләрен яклау ысулы буларак, институциональ учреждениеләрдән балаларны үз гаиләсенә кайтару. Соңгы өч елда махсуслаштырылган учреждениеләрдән уртача 70% тәрбияләнүче гаиләсенә кире кайтарыла.

4) Элеккечә ата-ана хокукларына чикләүләр бетерелгән ата-аналар санының 2014 ел белән чагыштырганда тагын 2 тапкырдан артыгракка кимүе һәм мондый ата-аналар санының аз булып калуы начар гаиләләрне тернәкләндерүнең начар оештырылуын күрсәтә торган тагын бер тискәре бәя булып тора. Шулай, 2016 елда бары тик 17 (чагыштыру өчен: 2014 елда – 35, 2015 елда – 15 кеше) ата-анага карата аларның ата-ана хокукларын чикләү суд тәртибендә бетерелгән һәм аларның үз балаларын тәрбияләү хокуклары кире кайтарылган. Икенче төрле итеп әйткәндә, ата-ана хокукларын чикләүнең алты айлык гамәлдә булу срогы профилактика субъектлары тарафыннан файдаланылмый.

2016 елда ата-ана хокукларына чикләү чарасы бөтенләй кулланылмады һәм түбәндәге муниципаль район органнары – профилактика субъектлары тарафыннан ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турындагы мәсьәлә куелды:

Әлки (9 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Апас (2 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Чүпрәле (5 кеше ата-ана хокукыннан

мәхрүм ителде), Кайбыч(9 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Лениногорск (2 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Тәтеш (5 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде), Тукай (9 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде). Бу чара Әгерҗе, Бөгелмә, Биектау, Зеленодольск, Түбән Кама, Нурлат, Чистай районнарында, Чаллы шәһәрендә актив кулланыла.

Шулай да аерым очракларда , ата-ана хокукыннан мәхрүм ителеп, ата-ана үз балаларын мәңгегә югалту куркынычы янауны кабул иткәнлектән башта ата-ана хокукларын чикләү процедурасын куллану балалар хакына, гаилә хакына уңай үзгәрешләргә дә китерергә мөмкин.

5) Гаиләләрне авыр яшәү шартларыннан чыгару буенча тиешле хезмәтләрнең эше торышына бирелгән тискәре бәяләмәнең тагын берсе балаларны ата-аналарыннан тартып алу очракларына анализ ясау нәтиҗәләреннән чыгып төзелде.

Баланың тормышына яки сәламәтлегенә җитди һәм чын куркыныч янаганда опека һәм попечительлек органының баланы тиз арада ата-анасыннан тартып алу мөмкинлеге, ә ул Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясында каралган, баланың гаиләгә хокукы аның башка нигез хокуклары белән каршылыкка килгәндә балаларның хокукларын яклауның иң соңгы чарасы буларак кулланыла. Билгеле ки, мондый чиккә җиткән хәлләр балалар һәм гаилә проблемаларын профилактикалау муниципалитетта оештырылган эшкә бәя булып тора.

2016 ел йомгаклары буенча шуны танырга кирәк: гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда ата-аналарыннан тартып алынган балалар саны, 2015 ел белән чагыштырганда, якынча ике тапкырга (48,4% ка) артты һәм 63 кә җитте, шулардан 23 бала (36,5%), социаль-тернәкләндерү чаралары үткәрелгәннән соң, ата-аналарына кире кайтарылган (чагыштыру өчен: 2015 елда – 122 баладан 24 (19,6%). Бу уңай тенденция органнар – профилактика субъектлары эшчәнлегенә уңай бәя бирүне таләп итә.


Шулай итеп, соңгы өч елда проблемалы гаиләләр белән эшләүне камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар күрелә дип танырга кирәк. Шулай да республикада начар гаиләләр белән индивидуаль профилактика һәм тернәкләндерү эшенең оештырылуы дәрәҗәсен канәгатьләндерерлек дип бәяләргә мөмкинлек бирми һәм **гаиләләрне һәм балаларны начар тормыштан чыгару буенча профилактика системасының законнарда билгеләнгән эшчәнлеген көчәйтү, камилләштерү, активлаштыруның өстәмә чараларын күрүне** һәм инновацион эш модельләрен билгеләүне **таләп итә**.

3.3.2. Социаль ятимлек проблемалары

Ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның гомуми санында ятимнәр 2015 елда 20,5% тәшкил итте.

85 нче диаграмма


2008 – 2016 елларда ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар саны



2016 елда әлеге категориядәге беренче тапкыр ачыкланган балаларның гомуми санында ятим балалар 19% яки 207 бала тәшкил итте (2015 елда – 25%, яисә 266 кеше).

86 нчы диаграмма

2008 – 2016 елларда ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар саны




Шулай итеп, гаилә мохитеннән мәхрүм ителгән балаларның иң зур өлешен, гадәттәгечә, ата-ана каравыннан мәхрүм ителгән балалар, икенче төрле әйткәндә, **социаль ятимнәр** алып тора. 2016 ел йомгаклары буенча ул 81% тәшкил итте.

2014 елдан алып ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм ителгән балаларның саны арту тенденциясе дәвам итә. Абсолют

күрсәткечләрдә исә, 2016 елда ачыкланган социаль ятимнәр саны шулай ук 885 балага артты, бу 2015 ел белән чагыштырганда 12% ка артык (2014 елда – 781 бала, 2015 елда – 791).

87 нче диаграмма


2008 – 2016 елларда ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар саны



Социаль ятимлекнең төп сәбәпләреннән берсе булып ата-аналарның яңа туган үз балаларын медицина оешмаларыннан алып чыгудан ***баш тартуы*** кала. Ата-аналары гаиләгә алудан баш тарткан яңа туган сабыйлар санының кими бару тенденциясе игътибарны җәлеп итә. Соңгы тугыз елда бу иң түбән күрсәткеч.

88нче диаграмма

2008 – 2015 елларда ата-аналары гаиләгә алудан баш тарткан балаларның саны



Баш тартуның сәбәпләре, элеккечә, баланың авыруында һәм гаиләнең финанс-матди яктан авыр тормышка юлыгуында күренә.

Үз балаларын медицина оешмаларыннан алып чыгудан ***баш тартуны профилактикалау максатларында*** авыр тормыш хәлендә калган хатын-кызларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән органнарның һәм хезмәтләрнең эшчәнлеген популярлаштыру эшен дәвам итәргә кирәк.

Мондый балаларны алга таба гаиләгә урнаштыру хәле тотрыклы булып кала, якынча 90% бала яңа гаиләгә урнаша. 2016 елда бу күрсәткеч кимеде, 70 «баш тартылган» яңа туган баланың 57 (яки 81,4%) ел дәвамында гаиләләргә урнаштырылды (2015 елда бу күрсәткеч 89,6% тәшкил итте).

Шулай да ***ата-аналарының ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүенә*** бәйле рәвештә балаларның тулы булмаган гаиләдә атасының яки анасының яисә ата-анасының икесенең дә тәрбиясеннән мәхрүм калуы социаль ятимлекнең төп сәбәбе булып кала бирә. 2016 елда 630 бала, яки 71,2%, тулы булмаган гаиләдә атасының яки анасының яисә ата-анасының икесенең дә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе сәбәпле ятим булып калды.

Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүнең төп сәбәпләренә ата-аналарның үз балаларын тәрбияләү вазыйфаларын үтәүдән качулары, үз гамәлләре белән яки гамәл башкармаулары белән балаларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган шартлар тудыру, ата-аналарның үз балаларына карата рәхимсезлек кылу яисә аларга карата җинаять башкару керүдән күренгәнчә, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү һәрвакытта да балаларның һәм гаиләнең начар тормышлы булуын аңлата. Шуңа күрә **Татарстан Республикасында ятимлекнең төп сәбәбе булып начар гаилә кала**.

Шулай итеп, социаль ятимлекне профилактикалауның бүгенге көнгә булган төп бурычы начар гаиләләрне башлангыч вакытында ук ачыклау һәм тернәкләндерү буенча эшчәнлекне тиешенчә оештырудан гыйбарәт(әлеге мәсьәлә буенча вәзгыятькә бәя 3.3.1 бүлегендә бирелде).

Республикада социаль ятимлекнең тагын бер проблемасы ***ата-аналарны ата-ана хокукларында чикләү тәҗрибәсенең тиешле дәрәҗәдә үсеш алмавында*** күренә.

Шул ук вакытта бала өчен «туган» гаиләсен саклап калу күзлегеннән караганда, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүгә караганда ата-ана хокукларын чикләүне кулланга, балаларның мәнфәгатьләрен яклау ысулы буларак, һичшиксез, өстенлек бирелергә тиеш.

2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләр кылуның илкүләм стратегиясендә ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүнең ата-ана хокукларын чикләүгә алмаштырылуының (бу чорда гаиләләр белән тернәкләндерү эшләре оештырылган булырга тиеш) максатка ярашлы булуы балаларга сакчыл булу гаилә сәясәтенең өстенлекле өстенлекле юнәлеше буларак каралган.

Закон чыгаручы, ата-ананың балаларны тәрбияли алуы мәсьәләсен караганда, опека һәм попечительлек органнарына ата-аналарны ата-ана хокукларында чикләү аркылы кисәтү рәвешендә тәэсир итү чараларын куллану хокукын бирә. Аны куллану суд тикшерүен алып баруны, суд

хөкемен чыгаруны күз алдында тотканны һәм чыннан да, ә кемдер тарафыннан кайчандыр ышандырылган түгел, үз балаңны югалту куркынычы булуны исәпкә алсак, ата-ана хокукларын чикләү билгеле бер этапта, күндерү белән ярдәм тәкъдим итүгә караганда, ваемсыз ата-аналарга йогынты ясауның күбрәк эшли торган чарасы булып тора. Әлеге механизмның бала өчен гаиләне коткарып калуның тагы бер мөмкинлеге буларак кулланылуы зарур.

Кызганычка каршы, 2016 елда ата-ана хокукларын чикләүне куллану тәжрибәсе яхшырмады, 2015 ел белән чагыштырганда, хәтта начарланды да: 2016 елда ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнарның саны 226 граждан тәшкил итте, бу 2015 елның шундый ук күрсәткечләренә караганда 72,5% ка артыграк.

26 нчы таблица

2010-2016 елларда ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән һәм шул хокуклары чикләнгән гражданнар саны

Гражданнар категориясе	**2010 ел**	**2011 ел**	**2012 ел**	**2013 ел**	**2014 ел.**	**2015 ел**	**2016 ел**
Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән йә ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнар	1230	1134	994	971	990	915	935
Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән гражданнар	1135	1030	902	876	849	784	709
Ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнар	95	104	92	95	141	131	226
Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән йә ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнарның гомуми санынннан ата-ана хокуклары чикләнгән гражданнар өлеше	7,7	9,2	9,3	9,8	14,2	14,3	24,2


Ата-аналарны ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүгә кадәр ата-ана хокукларын чикләүгә өстенлек бирү практикасын файдалануны дәвам итәргә кирәк дип саныйбыз.

Татарстан Республикасында социаль ятимлекнең ***дүртенче проблемасы*** итеп ата-ана хокукларын кире кайтару һәм аларга карата чикләүне бетерү институтының үсеш алмавын күрсәтергә кирәк дип уйлыйм.

Кызганычка каршы, ата-ана хокуклары кире кайтарылган ата-аналарның саны хәзер дә зур түгел. Моннан бигрәк, соңгы елда аларның саны бераз артты. 2015 елда үзләренең ата-ана хокукларын суд аша 37 кеше кире кайтарган булса, 2016 елда андыйларның саны 54 булды.

89 нчы диаграмма

2010–2015 елларда гражданнарның ата-ана хокукларын кире кайтарулары



Ата-ана хокукларын чикләү кире алынган ата-аналарның саны бик аз санда кала бирә. Шулай, 2016 елда суд аша бары тик 17 ата-ананың ата-ана хокукларын чикләү кире алынды һәм алар үз балаларын тәрбияләү хокукларын кире кайтардылар (чагыштыру өчен: 2014 елда – 35 кеше, 2015 елда – 16 кеше).

Гаилә проблемаларын һәм социаль ятимлекне анализлауга йомгак ясап, бу юнәлештәге эшне оештыру түбәндәге төп принципларга нигезләнергә тиеш дип саныйбыз:

ата-ананың башка барлык затларга караганда үз балигъ булмаган балаларын тәрбияләүгә өстенлекле хокукы;

дәүләт тарафыннан баланың һәрьяклап үсеше һәм тәрбиясе өчен мәҗбүри шарт буларак ата-анасыннан аерылмауга һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын тәэмин итү өстенлеге;

ата-аналар тарафыннан балигъ булмаган балаларны тулысынча тоту, укыту, тәрбияләү, ял иттерү һәм савыктыруны, аларның хокукларын яклауны, җәмгыятьтәге тулы канлы тормышка әзерлекне тәэмин итү максатларында гаиләгә бөтен яктан дәүләт ярдәме;

балигъ булмаган балалары булган гаиләләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган өчен вазыйфаи затларның катгый җаваплылыгы.

3.3.3. Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру

Татарстан Республикасында 2016 ел ахырына ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның саны 11 717 тәшкил итте, бу барлык балаларның гомуми санынннан 1,5% тәшкил итә (индикаторның чик күрсәткече – 1,5%).

Ятим баланың тормышын урнаштыруда өстенлек, һичшиксез, алмаш гаиләне эзләп табуга бирелә. Татарстан Республикасында, максатчан эш алып барылганга күрә, ятимнәрне гаиләгә урнаштыру мәсьәләсендә вәзгыятьнең тотрыклы булуы билгеләнә. Хисап елы ахырына республи-

када алмаш гаиләләрдә 11 150 бала яшәде. Ул ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның (алга таба – ятим балалар) гомуми санынна 95,2% тәшкил итә.

Ятим баланың тормышын урнаштыруда өстенлек, һичшиксез, алмаш гаиләне эзләп табуга бирелә. Татарстан Республикасында, максатчан эш алып барылганга күрә, ятимнәрне гаиләгә урнаштыру мәсьәләсендә вәзгыятьнең тотрыклы булуы билгеләнә. Хисап елы ахырына республикада алмаш гаиләләрдә 11 150 бала яшәде. Ул ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның (алга таба – ятим балалар) гомуми санынна 92,5% тәшкил итә. Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының эш нәтиҗәсен билгеләү күрсәткече буенча «Ата-ана каравыннан мәхрүм калган, шул исәптән туган булмаган кешеләргә тапшырылган (бала алучы гаиләләргә, уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), барлык типтагы (муниципаль) дәүләт учреждениеләрендә урнашкан гаилә балалар йортларына, патронат гаиләләргә) балалар өлеше 2016 елда 98,88% тәшкил итте, бу индикаторның иң чик күрсәткеченнән артып китә. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең ун алдынгы регионына керә.

90 нчы диаграмма

2008–2016 елларда ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны урнаштыру



2016 елда ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар категориясеннән булган 1 192 бала гражданнар гаиләләренә тапшырылды (2015 елда – 120 бала).

2016 елда ятим балалар өчен дәүләт учреждениеләрендә тәрбияләнүче балаларның санының кими баруы дәвам итте: 55 балага яки 10,2% ка.

Статистика хисапларына ясалган анализ шуны күрсәтә: узган елда 1192 ятим бала гаиләләргә тәрбиягә урнаштырылды, шул исәптән 798 (67%) түләүсез нигездә опекага (попечительлеккә) тапшырылды, 302 (25%) бала алучы гаиләләргә, 92(8%) уллыкка алынды. Шул ук вакытта ятим бала опека һәм попечительлек органнары тарафыннан гаиләгә урнаштырылган очракта, 67% ятим баланың якын туганнарына опекага (попечительлеккә) бирелүеннән чыгып әйткәндә, якын туганнарының бала тәрбияләүгә хокукларына өстенлек бирүе сакланып кала.

91 нчы диаграмма

2016 елда гражданнар гаиләләренә тәрбиягә ятим балаларны урнаштыру



Опеканың (попечительлекнең) түләүсез рәвешенә тапшырылган балалар саны;

Опеканың (попечительлекнең) түләүле рәвешенә тапшырылган балалар саны;


Уллыкка (кызлыкка) тапшырылган балалар саны.

Республикада ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны тәрбияләүнең гаилә формалары үсеше динамикасы 81 – 83 диаграммаларда күрсәтелде.

Балаларны гаиләгә урнаштыруның иң таралган рәвеше баланы туганнар гаиләсенә тәрбиягә бирү. 2017 елның 1 гыйнварына 4 526 опекун гаиләсендә 5 383 бала тәрбияләнде. Ләкин опекун гаиләләр санының да (2015 елда аларның саны 4 610), туган кешегә опекага тапшырыла торган балаларның да саны кими.

92 нче диаграмма


2008-2016 елларда опекада (попечительлектә) тәрбияләнүче балалар саны



Ел саен тәрбиягә бала алучы гаиләләр саны арта: 2015 елда 1 491 гаиләдән 2016 елда 1 513 балага кадәр. 2016 елның 1 гыйнварына 1 513 шундый гаиләдә 2 907 бала тәрбияләнде, шуның 5 һәм аннан күбрәк бала алган – 84 гаилә, 3 – 4 бала алган – 215 гаилә, 1–2 бала алган – 1 214 гаилә теркәлде.

93нче диаграмма


2008-2016 елларда бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар саны



2017 елның 1 гыйнварына 2 691 гаиләдә уллыкка алынган 2 859 бала тәрбияләнде. Шулардан: уллыкка алынган 5 бала тәрбияләүче гаилә – 3; уллыкка алынган 3–4 бала тәрбияләүче гаилә – 9; уллыкка алынган 1–2 бала тәрбияләүче гаилә – 2 679.

94 нче диаграмма


2008-2016 елларда уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны



2016 елда ятим балаларны тәрбияләүнең балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен иң яхшы гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган рәвеше буларак уллыкка алуга кызыксыну тенденциясе югалу сакланды**. 2016 елда уллыкка тапшырылган балалар саны 43 кешегә (30% ка) артты: 2015 елда – 135 тән 2016 елда 92 балага кадәр**. Уллыкка алу күрсәткече 2016 елда – соңгы тугыз ел эчендә иң түбән күрсәткеч.

95 нче диаграмма

2008–2016елларда балаларны уллыкка (кызлыкка) алу




Мондый хәл ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның балалар мәнфәгатьләренә иң туры килә торган өстенлекле юнәлеше буларак уллыкка алу институтын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне таләп итә.

Балаларны уллыкка тапшырганда Россия гражданнары гаиләләренә урнаштыруга өстенлек бирелә. 2016 елда уллыкка алынган 92 баладан 90 бала Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан, 2 бала – чит ил гражданнары тарафыннан алынды. 2 бала да Италия гражданнары тарафыннан уллыкка алынды, икесенең дә сәламәтлегендә тайпылышлар булып, аларны Россия гражданнары гаиләләренә урнаштыруның өстенлекле вариантларын карау тәэмин ителде.

96 нчы диаграмма

2008–2016 елларда балаларны уллыкка (кызлыкка) алу



Урнашкан хәлнең уңай ягы буларак 2016 елда гаиләгә тәрбиягә 39 инвалид баланың тапшырылуы дип билгеләргә мөмкин. Аерым алганда, 2 инвалид бала Татарстан гражданнары тарафыннан уллыкка алынды, 36 – опекага (попечительлеккә) тапшырылды, шул исәптән 27 – гаиләгә бала турында шартнамә буенча.

2017 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында яшәгән ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның тормышларын урнаштыру 97 нче диаграммада күрсәтелде.

97нче диаграмма

2017 елның 1 гыйнварына ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның тормышларын урнаштыру



Кызганычка каршы, ата-ана каравыннан мәхрүм калган барлык балаларга да тиз арада гаилә табып өлгереп булмый. Уллыкка алучылар һәм бала алучы ата-аналар булырга әзерләнгән кандидатларның саны шактый булганга күрә, республикада башлангыч вакытында ук «ятимнәр» өчен булган дәүләт учреждениеләренә җибәрелгән яңа ачыкланган балалар саны ел саен кими бара. 2016 елда яңа ачыкланган балалардан 948 бала, ягъни 87%, гаиләгә тәрбиягә бирелде һәм 144 бала гына ятимнәр өчен булган оешмаларга беренче тапкыр билгеләнгән иде.

2016 елның уңай нәтиҗәсе буларак, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен булган оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең саны ел дәвамында 540 баладан 485 балага кадәр кимеде, 2016 ел ахырына түбәндәгеләрдә тәрбиядә булдылар:

сабый йортында – 49 бала;

балалар йортларында – 144 бала;

ятим балалар өчен VIII төрдәге мәктәп-интернатларда – 81 бала;

балалар өчен интернат йортларда – 211 бала.

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында региональ белешмәләр банкында исәптә торучы балалар саны кимү тенденциясе сакланып калды. Мәсәлән, 2016 елның 1 гыйнварына ата-ана каравыннан мәхрүм калган 662 бала исәптә торса, 2017 елның 1 гыйнварына аларның саны 567 тәшкил итте (14,4% кимеде). Аларның яшь составы таблицада китерелде.

27нче таблица

2017 елның 1 гыйнварына ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүматлар банкында булган балаларның яшь составы

Балаларның яше	Балаларның гомуми саны	Шуның		инвалидлыгы бар	Үсешендә тоткарлык булганнар
		ир балалар	кыз балалар		
0 – 3 яшь	45	27	24	14	14
3 – 5 яшь	17	10	8	9	9
5 – 7 яшь	26	16	10	22	17
7 – 10 яшь	61	23	38	47	52
10 – 14 яшь	166	57	108	115	131
14 – 18 яшь	252	165	85	113	135
барлыгы	567	298	273	320	358

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында белешмәләр банкын анализлау шуны күрсәтә: 56,4% бала – инвалид, 63,1 % бала – акыл ягыннан зәгыйфь. Аерым алганда, мәктәпкәчә яшьтәге 88 баладан 45 баланың (51,1%) инвалидлыгы бар, мәктәп яшендәге 479 кешедән 275 кеше (57,4%) инвалид бала категориясенә керә, 318 баланың (66,4%) акылында зәгыйфьлек бар. Эш тәжрибәсеннән күренгәнчә, мондый балаларның авырулары булу сәбәпле һәм аерым тәрбия кирәк булганда күрә, кагыйдә буларак, гаилә табу бәхетенә ирешә алмыйлар.

2016 ел ахырына опека һәм попечительлек органнарында уллыкка алучыларга, тәрбиягә бала алучыларга кандидатлар әзерлеген узган, опека һәм попечительлек органнарының уңай бәяләмәсен алган 444 гаилә исәптә торды, шулардан 188 гаилә исәптә елдан артык тора. Ләкин бу кандидатларның 2016ел дәвамында тәрбиягә бала ала алмаган уллыкка алучылар, тәрбиягә бала алучылар контингентын анализлау теләк белдерүчеләрнең 100% диярлек тәрбиягә I яки II сәламәтлек группасына караган балага өстенлек бирүләрен һәм 86% гаилә 7 яшькә кадәрге баланы тәрбиягә алырга теләүләрен күрсәтте.

Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру барышын активлаштыру, позитив иҗтимагый фикер тудыру максатларында **Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә республика гражданнарын гаиләгә инвалид балаларны, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һәм яшүсмер яшендәге балаларны алуны кызыксындыра торган өстәмә механизмнар уйлап табарга, региональ ярдәм чараларын күрү мөмкинлеген карарга тәкъдим итәбез.** Шундый ук тәкъдимнәр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2015 елгы докладында урын алган иде. Ләкин бу мәсьләләр буенча реаль тәкъдимнәр алынмады.

Әлеге бурычны хәл итү өчен гамәлгә ашырыла торган проектларның берсе – республикада «БАЛАНЫҢ ВИДЕОПАСПОРТЫ» Гомумроссия мәгълүмат-эзләү системасы кысаларында оештырылган эш. Әлеге проект Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов йөкләмәсе буенча һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең турыдан-туры катнашында 2011 елдан башлап эшли.

Әлеге проект кысаларында региональ мәгълүматлар банкындагы балаларның 40 минутлык фильм рәвешендәге видеопаспортлары уллыкка алучыларга, тәрбиягә бала алучыларга кандидатларга алдан ук бала белән танышып куярга, алар белән шәхсән очрашканда, күңел кайтуларны булдырмаска һәм баланың психикасын җәрәхәтләмәскә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, «ВИДЕОПАСПОРТ» проекты балаларны гаиләләргә урнаштыру эшендә федераль мәгълүмати ресурстан файдалануны күздә тота, ә бу исә ата-аналарга һәм балаларга бер-берсен табу мөмкинлеген киңәйтә: видеопаспортларны Интернетта WWW.BIDEOPASPORT.RU сайтына урнаштырырга, «Пока все дома» программасының «У вас будет ребенок» рубрикасында ятим балалар турында сюжетлар күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Алты ел дәвамында гына да 364 баланың видеопаспорты төзелде (2011 елда – 32, 2012 елда – 31, 2013 елда – 43, 2014 елда – 56, 2015 елда – 94, 2016 елда – 108 видеопаспорт). Барлык видеопаспортлар тиз арада һәркем таныша алырлык итеп урнаштырыла («Усыновитель» сайты). Бүгенге көндә 244 бала (73%) бала әлеге проект нәтиҗәсендә үз гаиләләрен тапты яки дәүләт учреждениеләреннән китәргә әзерләнә.


Әлеге проектны гамәлгә ашыруда нигездә зур гаиләдән (3 бала һәм күбрәк) булган балалар, өлкән яшьтәге балалар (9 – 11 яшь), сәламәтлегендә тайпылышлар булган балалар ата-аналарын таптылар. Ә бит нәкъ аларга сөекле ата-аналарын һәм яраткан гаиләләрен табу кыен.

Опека һәм попечительлек органнарының, алмаш ата-аналарга кандидатлар эзләп табу һәм ятим балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә булышлык күрсәтү хезмәтләренең уңай һәм мөһим эш нәтиҗәләре **икенчел ятимлекне анализлаудан** – баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында карарларның гамәлдә булуы туктатылган балаларның саны кинәт кимүендә күренә. Әгәр 2014 елда гаиләгә тапшыру турында карар 66 балага кагылышлы кире кайтарылса, 2015 елда –29, 2016 елда – 28 балага кагылышлы гамәлдә булуы туктатылды, шул исәптән 1 балага кагылышлы уллыкка бирү турында суд хөкеме көчен югалтты. Монда шуны билгеләп үтәргә кирәк: 28 очракның 24 ендә карарларның көче уллыкка алучылар, опекуннар һәм тәрбиягә бала алучылар инициативасы буенча туктатылды: Түбән Кама муниципаль районында – 4 очрак, Әлки, Зеленодольск муниципаль районнарында – 3 очрак, Бөгелмә, Алабуга муни-

ципаль районнарында – 2 очрак, Мамадыш, Менделеевск, Биектау, Лениногорск, Минзәлә, Питрәч, Спас, Чирмешән муниципаль районнарында, Казан шәһәренең Идел буе районында - 1әр очрак.

98 нче диаграмма

2011-2016елларда гаиләгә тапшыру турында карарлар көчен югалткан балалар саны



Соңы еллар мониторингы баланы алмаш гаиләләргә тапшыру турындагы карарларны юкка чыгару очраклары санының кимүгә таба баруын чагылдыра. Шулай да, мондый фактлар очраганда вәзгыятьне уңай дип бәяләп булмый. Икенчел ятимлек баланың аннан башка да киренке психикасына тирән җәрәхәт ясый. Алмаш гаиләләрдән балаларны кире кайтару баланы җәрәхәтләү белән бергә әхлакый һәм психологик деградациягә китерә. Икенче тапкыр ташланганнан соң, бала өлкәннәргә ышанычын югалтырга мөмкин. Ахыр чиктә ул кешеләргә, башкаларга карата һәм үз баласын тәрбияләүдә чагылырга: баласын тәрбияләүдән баш тартырга, тулы гаилә кормаска мөмкин.

2016 елда баладан баш тартуның сәбәпләре:

баланың физик һәм акыл үсеше үзенчәлекләрен җитәрлек белмәү;

баланың ата-ана көткәнне акламавы, ата-ананың аны идеаллаштыруы;

баланың авыруы – өлкәнрәк яшьтә килеп чыккан психиатрик авырулары;

темпераментларның төрле булуы, аралашу һәм тәртип проблемалары, аңлашылмаучылык.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, 2016 елда гаиләгә тәрбиягә бала тапшыру турында карар юкка чыкканнан соң барлык балалар да (27 бала) республиканың төрле ведомство учреждениеләренә җибәрелде (2015 елда – 24 һәм 2014 елда – 31).

Гаиләгә бала тапшыру турындагы карарны юкка чыгару хакында опека органнары тарафыннан карар чыгарылган ата-аналарның 30 %ы тиешле әзерлек үтүне исәпкә алсак, шундый ата-аналарга кандидатларны әзерләү сыйфаты турындагы мәсьәлә актуаль булып тора.

4 очракта карарларны юкка чыгару бала тәрбияләү вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгәнлектән (6 балага карата) булу факты, шул исәптән 1 очракта гаиләгә тәрбиягә алган балага карата җинаять эшенә тартылуга бәйле булу факты борчу уята. Мондый фактлар опека һәм попечительлек органнарының ата-ана булу өчен кадрлар сайлау һәм гаиләләрдә баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларының сыйфаты турындагы мәсьәләне куярга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, гаиләгә бала тапшыру турындагы карарны юкка чыгару фактларын һәм балаларны ятимнәр өчен дәүләт учреждениеләренә кире кайтаруны минимальләштерү максатында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне үтәргә кирәк дип саныйбыз:

опека һәм попечительлек органнарының ата-ана булу өчен кандидатлар әзерләүдә нәтиҗәле һәм профессиональ эшли торган систему булдыру һәм ятим баланы тәрбиягә алган гаиләне күзәтеп тору эшчәнлеген камилләштерү буенча чаралар күрергә;

бала алучы ата-аналарның, опекуннарның (попечительләрнең), гаилә әгъзаларының психологик-педагогик компетенцияләрен күтәрү буенча системалы эшоештыру мәсьәләсен карарга;

ата-ана булу өчен кандидатларның әзерлегенә һәм сәләтенә мәҗбүри психологик бәя бирү өлешендә гамәлдәге федераль законнарга үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау инициативасы белән чыгарга.

3.3.4. Баланың гаиләгә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары һәм, гаиләдә каршылыклар булганда, гаилә эчендәге бәйләнешләр

Гражданнар мөрәҗәгатьләренең еллык мониторингы гаилә эчендәге конфликтларда балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауның актуальлеген дәлилли.

Бүген гаилә законнарына гаиләнең үзенең эчке яшәешенә карата карарлар кабул итүдә ирекле булуы, ата-аналарның ата-аналар хокукларын гамәлгә ашырганда ихтыярыйлык презумпциясе, һәр гаиләнең бала тәрбиясе, белеме һәм үсеше өчен һәм дә сәламәтлеге саклану өчен җаваплылыгы кебек принциплар кертелә. Гаилә җәмгыятьнең төп социаль институты һәм, гадәттәгечә, баланың үсү һәм социальләшү процессын тәэмин итә торган табигый мохит булып тора. Баланың шәхес булып җитлегүе, аның билгеләнгән кыйммәтләре һәм куелган максатлары нинди булу тәрбия бирү шартларына, бала-ата-ана арасындагы һәм ир белән хатын арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә нык бәйле. Нәкъ шуңа күрә гаилә балачакның социаль хәлләрен төп җайга салучы булып тора.

Баланың гаилә бәйләнешләренә шәхси һәм мөлкәткә бәйле хокуклары бозылуның төп сәбәбе ата-аналарның аерылышуы аркасында каршылыклы очракларның килеп чыгуында күренә. «Каршылыклар белән аерылышу», балалар мәнфәгатьләре күзлегеннән чыгып караганда, бик мөһим мәсьәләләрне хәл иткәндә түбәндәге бәхәсле хәлләр тууга сәбәп була:

баланың яшәү урынын билгеләү;

балаларны ата-ананың икесе тарафыннан да тәэмин итеп тору тәртибен (алимент йөкләмәләрен) билгеләү;

баладан аерым яшәүче ата яки ананың бала белән аралашу тәртибен билгеләү;

баланың башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү.

Аерылышуларның саны күп булу борчу уята: продуктив яшьтәге өйләнешкән яшьләрнең (25-40 яшьлекләр) яртысы диярлек аерылыша, ә мондый гаиләләрнең күбесендә балалар була. 2016 елда Татарстан Республикасы ЗАГС органнары тарафыннан 25 778 язылышу теркәлгән, бу 2015 ел белән чагыштырганда, 4 794 (15,7%) язылышуга кимрәк. Аерылышу белән тәмамланган өйләнешүләр саны, элеккечә, югары булып кала һәм узган елда мондыйлар 13 450 булды. Бу 1000 өйләнешкән парның 522 се дигән сүз.

99 нчы диаграмма

2009–2016 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән язылышулар һәм аерылышулар динамикасы



2016елда ата-аналарының аерылышуы ачысын **9 511 бала** татыды, бу 2015 елга караганда 1478 гә артык 12015 елда – 8033 бала). Бу балалар алар өчен табигый булмаган, психик яктан зыян китерә торган шартларга юлыккан балалар төркемен тәшкил итәләр. Мондый шартлар аларның психик-эмоциональ торышларына, тәртибенә һәм бөтен алдагы тормы-


шына тискәре йогынты ясавы белән куркыныч. Мондый балаларга үз вакытында психологик ярдәм күрсәтү һәм тормышларына үзгәрешләр кертү таләп ителә. Кызганычка каршы, ата-аналар балаларына нинди көчле психик зарар китүләрен, кагыйдә буларак, тиешенчә аңлап бетермиләр һәм профессионал психологлар ярдәмен сорап мөрәҗәгать итүне кирәксенмиләр.

Ата-аналар аерылышуны тыныч кына һәм җайлап кына хәл итә алмаган очракта, аларның балалары психикасына тагын да көчлерәк зыян килә. Еш кына аерылышулар «сугыш кырын» хәтерләтә, монда ир белән хатын бер-берсен гаеплиләр, еш кына мондый көрәшкә, кайсының булса да ягына чыгарга мәҗбүр итеп, балаларын да катнаштыралар. Төп тавыш баланың яшәү урынын һәм аерым яшәүче ата-анасының һәм башка туганнарының бала белән аралашу тәртибен билгеләү мәсьәләләрен хәл иткәндә чыга.

2016 елда балаларның гаиләгә һәм гаилә эчендәге бәйләнешләргә булган мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләрен үз эченә алган 433 мөрәҗәгатьтә 174 кеше (41,1%) баланың яшәү урынын һәм аралашу тәртибен билгеләү буенча туа торган гаилә эчендәге каршылыклы хәлләрне җайга салуда ярдәм күрсәтүләрен сорап язган.

100нче диаграмма

2012–2015 елларда балаларның гаиләгә һәм гаилә эчендәге бәйләнешләргә булган мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре буенча граждannар мөрәҗәгатьләре динамикасы



Аерылышканнан соң баланың яшәү урынын билгеләү соңгы вакытта балалар артыннан куу һәм аларны урлау, баланың теләк-кызыксынулары белән уйнау сюжетларына корылган криминаль детективларны хәтерләтә. Ата-ананың һәркайсы нәкъ менә аның балага иң әйбәт тәрбия бирәчәгенә ышандыра. Мондый очракларда эш якларның җитди каршылыкка килүе белән төгәлләнә, бу җирлектә баланың проблемалары һәм мәнфәгатьләре бөтенләй күләгәдә кала. Баланың яшәү урынын билгеләү хәзер күп очракта суд хөкеменә тапшырыла. Шулай,

Татарстан Республикасы Югары суды мәгълүматларына караганда, 2016 елда гомуми юрисдикция судларында 339 балигъ булмаган балага кагылышлы әлеге категориягә кергән 257 эш каралган.

Аерым яшәүче атасы яки анасы һәм башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү мәсьәләсе буенча судка бирелгән дәгъвалар һәрвакытта диярлек ата-ананың берсе тарафыннан гаилә законнары нормаларының да, шулай ук үз баласының законнарда гарантияләнгән хокукларының һәм мәнфәгатьләренең бозылуын да аңлата. Татарстан Республикасы Югары суды мәгълүматларына караганда, 2016 елда гомуми юрисдикция судларында 475 балигъ булмаган балага кагылышлы әлеге категориягә кергән 435 эш каралган.

Россия Федерациясе Гаилә кодексының 66 статьясы нигезендә баладан аерым яшәүче ата-ана бала белән аралашырга, аны тәрбияләүдә һәм баланың белем алуы мәсьәләләрен хәл итүдә катнашырга хокуклы. Бала белән бергә яши торган ата-ана баланың алар белән бергә яшәми торган ата-анасы белән аралашуына каршы килергә тиеш түгел, тик мондый аралашуның баланың психик һәм физик сәламәтлегенә, аның әхлакый үсешенә зыян китермәве шарт. Бала исә, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 55 статьясында каралганча, ата-анасының икесе белән дә аралашырга хокуклы. Ата-анасы аерым яшәгән очракта, баланың һәркайсы белән аралашырга хокукы бар. Шул ук вакытта, ата-аналарының аерылышуы яки аерым-аерым яшәүләре бала хокукларына берничек тә йогынты ясамый. Россия Федерациясе Гаилә кодексының 67 статьясы нормаларында бабайларының, әбиләренең, абый-апаларының һәм башка туганнарының бала белән аралашуга хокуклары гарантияләнгән. Бала исә шулай ук бабайлары, әбиләре, абый-апалары һәм башка туганнары белән аралашырга хокуклы. Шул ук вакытта, ата-аналарының аерылышуы яки аерым-аерым яшәүләре бала хокукларына шулай ук берничек тә йогынты ясамый.

Әлеге тематика буенча гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләрне карау тәжрибәсен, шулай ук Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында 2016 елда узган суд тәҗрибәсен гомумиләштерүдән чыгып, тиешле органнарның баланың яшәү урынын һәм аралашу тәртибен билгеләү буенча каршылыклы очракларны балалар мәнфәгатьләреннән чыгып хәл итү буенча эшен камилләштерү максатларында **түбәндәге тәкъдимнәргә** игътибар бирергә кирәк дип уйлыйм:

Татарстан Республикасы Югары судына, гомуми юрисдикциядәге район (шәһәр) судларына балалар турындагы мәсьәләләрне караганда ата-аналарның (ата-ананың берсенең) таләбе буенча һәм опека һәм попечительлек органнарының мәҗбүри катнашында алдан үткәрелә торган суд утырышында балалар турында бәхәсләрне карап тикшергәндә

суд карары үзенең законлы көченә кергәнчегә кадәрге чорга балаларның яшәү урыннарын һәм (яки) ата-ана хокукларын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү практикасын (Россия Федерациясе Граждан кодексының 152 статьясында һәм Россия Федерациясе Гаилә кодексының 65 статьясындагы 3 пунктында каралган) киңәйтүне тәкъдим итәргә. Балаларның мәнфәгатьләрен яклауның мондый чарасы, ул 2011 елда кертелде, гаиләнең кризислы, каршылыклы хәлдәге очракларында балалар юлыккан хәлне тотрыкландыруны һәм җайга салуны максат итеп куя, чөнки яшәү урынын һәм аралашу тәртибен билгеләү буенча суд процесслары озак вакытларга сузылырга мөмкин;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә Россия Федерациясендә Административ хокук бозулар Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясындагы 2 пункты нигезендә баланы ата-аналары белән һәм якын туганнары белән аралашудан мәхрүм иткән өчен каралган административ җаваплылыкка тарту практикасын киңәйтергә һәм активлаштырырга. Әлеге норманың гамәлдә булуы шулай ук балаларны, аларның ирегенә каршы килеп, тору урынын махсус яшерү, балаларның яшәү урыннарын билгеләү турында суд карарын үтәмәү очракларына һәм башка очракларга карый. Ләкин тәжрибә баланың тәрбия алуга хокукын гамәлгә ашыруга комачаулыклар тудыра торган затларга күрсәтелгән административ йогынты ясау мөмкинлегенең җитәрлек дәрәҗәдә киң кулланылмавын күрсәтә;


судларга һәм опека һәм попечительлек органнарына аерылышкан очракта бала тәрбияләү буенча бәхәсле мәсьәләләргә бәйле эшләрне караганда, республика психологик хезмәтләрен җәлеп итеп, медиатив технологияләр практикасыннан актив файдалануны тәкъдим итәргә. Балаларның яшәү урыны һәм аралашу тәртибе турындагы бәхәсләрне хәл итү хокукый җайга салу яссылыгында гына хәл итүне таләп итеп кенә калмыйча, аннан бигрәк психологик бәя бирүне һәм булышуны таләп итә. Гаилә конфликтларын хәл иткәндә, процесста юристлар белән беррәттән социаль әзерлекле психолог-медиаторлар да катнашса, күп кенә кыенлыкларны читләтеп узып булыр иде. Аларның эшчәнлегенең төп максаты каршылыкка килгән якларның бер-берсен ишетүләренә ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт. Һәр кеше теге яисә бу очракны субъектив кабул итә бит. Каршылыкны җиңү өчен арадашчы ярдәме кирәк. Медиатор, аралашудагы киртәләрне һәм психологик киеренкелекне бетерү буенча ярдәм күрсәтеп, каршылыкта катнашучы яклар арасындагы арадашчы функциясен үти. Шулай итеп, юрист белән психолог бергә эшләсә, каршылыклар судка кадәрге тәртиптә яки суд процессы кысаларында каралганда, каршылыкка килгән яклар арасында үзара килешүгә тыныч кына ирешү ихтималы зуррак булыр иде.

Гаиләдәге бәйләнешләрдә балаларның хокукларын яклауда гражданнарның соңгы еллардагы мөрәҗәгатьләрен анализлаудан күренгәнчә, **чит ил гражданнары белән аерылышканда яисә аерым торганда балаларның яшәү урынын** һәм ата-ана хокукларын һәм бурычларын билгеләгәндә бәхәсле, конфликтлы хәлләр килеп чыккан очракта балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең актуаль була бара.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС идарәсе белешмәләре буенча, 2011 елдан чит ил гражданнары белән өйләнешүне теркәү турындагы актларның саны тотрыклы рәвештә арту тенденциясе саклана. 2016 елда Татарстан Республикасында чит ил гражданнары белән өйләнешү турында 1350 акт теркәлә, бу 2011 ел белән чагыштырганда 2 тапкырга артык.

101 нче диаграмма

Чит ил гражданнары белән теркәлгән өйләнешүләр саны



2016 елда баланың яшәү урынын билгеләү, Төркия, Франция, Австрия, Германия, Греция, Испания, Малайзия гражданнары белән өйләнешкән гражданнар яисә аларның якын туганнары – барлыгы 17 граждан баланы Россия Федерациясенә кире кайтару тәртибен хәл итүне (барлык мөрәҗәгатьләрнең 4%ы гаиләгә һәм гаилә бәйләнешләренә хокукны яклау проблемасы турында), 2015 елда мондый мөрәҗәгатьләр ике тапкыр азрак иде (8 мөрәҗәгать, бу темага барлык мөрәҗәгатьләрнең 2%ы).

Әлеге мәсьәләләрне хокукый җайга салу үзенчәлеге – аларны хокукый регламентацияләүнең Россия Федерациясе законнары белән дә, халыкара хокук нормалары белән дә (Халыкара балалар урлауның граждани-хокукый аспектлары турында конвенция 25.10.1980, Ата-ана җаваплылыгы һәм балаларны яклау чараларына карата юрисдикция, кулланылу хокукы, тану, башкару һәм хезмәттәшлек турында конвенция, 19.10.1996) һәм икенче як яисә бала яши торган илнең милли законнары белән дә гамәлгә ашырылуы. Һәр конкрет очракта илнең милли законнары хокукый нормаларының һәм халыкара хокук нормаларының нисбәте

индивидуаль карала. Бәхәс килеп чыккан очракта хокукый җайга салуның катлаулылыгы төрле ил гражданнары булган ир белән хатынны һәм балаларны кыен хәлгә куя.

Шушы уңайдан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС идарәсенә Россия Федерациясе гражданнарының чит ил гражданнары белән өйләнешүләрен теркәгәндә гаилә мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салу үзенчәлекләре мәсьәләсе буенча яшь өйләнешүчеләргә консультатив ярдәм күрсәтү турындагы мәсьәләне карау максатка туры килә дип уйлыйбыз.

3.4. Мәгариф өлкәсендә баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау

Белем алуга хокук баланың мәдәни хокукларыннан иң мөһимнәреннән санала, кешенең киләчәктә уңышка ирешә алу-алмавы да әлеге хокукларны бала вакытта гамәлгә ашыру мөмкинлекләре һәм шартлары нинди булуга бәйле була. Төрле категориядәге балаларның Россия Федерациясендә һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар нормаларында гарантияләнә һәм әлеге хокукка тигез мөмкинлекләргә таянып ирешүне максат итеп куя.

3.4.1. Мәктәпкәчә белем

2017 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү системасында 1 856 мәгариф оешмасы эшли, аларда 217 599 бала тәрбияләнә, шул исәптән:

1 836 муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасы (аларда 210 274 бала);

20 дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмасы (аларда 2 170 бала).

Татарстан Республикасында соңгы елларда республиканың иң яшь халкын һәркем файдалана алырлык мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итү өчен күп эшләр башкарыла. 2011 елдан башлап республикада мәктәпкәчә өстәмә урыннар булдыру буенча президент программасы гамәлгә ашырыла, ул мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә чиратны бетерү һәм балалар бакчаларында урыннарга кытлык проблемасын хәл итү өчен кертелде. 2013 елдан алып 2016 елга кадәрге чорда гына да республикада яңа 162 балалар бакчасы төзелде, 28 725 мәктәпкәчә урын булдырылды, гомуми суммасы 13 386,78 млн. сум тәшкил итте. 2016 елда әлеге программаны гамәлгә ашыру кысаларында барлыгы 700

урынлык яңа 4 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төзелде. Моның белән бергә, яңа балалар бакчалары төзүдән тыш, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен капиталь ремонтлау (реконструкцияләү) программасы эшләп килә. 2013 елдан алып 2016 елга кадәрге чорда 118 балалар бакчасы, шулардан 53 – 2016 елда капиталь төзекләндерелде.


Мәктәпкәчә белем бирүнең традицион рәвешләре белән берәттән вариатив рәвешләре дә үсә. Республикада гаилә балалар бакчалары челтәре (мәктәпкәчә гаилә төркемнәре) эшләп килә, гомуми белем бирү мәктәпләрендә мәктәпкәчә төркемнәр ачыла. 2016 елда 25 гаилә балалар бакчасында, 195 мәктәпкәчә төркемнәрдә һәм мәктәпкәчә тәрбияләүнең башка рәвешләрендә, гомумән алганда, 5 230 бала мәктәпкәчә белем алган.

Моның белән бергә, төрле чаралар күрелүгә карамастан, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннарга кытлык проблемасы сакланып кала.

Туучылар саны арта бару сәбәпле республика балалар бакчаларына гомуми чират ел саен зурая бара һәм 2016 ел ахырына анда 119 473 кеше исәпләнде. 2015 ел белән чагыштырганда, артым 4% (4 629 кеше) тәшкил итә.

102 нче диаграмма


2013-2016 елларда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында чиратлылык



Яңа мәктәпкәчә урыннар булдырылуга карамастан 2012 елдан алып республикада балаларны мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итү колачының тараюы күзәтелә, һәм 2016 елда ул соңгы тугыз ел эчендә иң түбән күрсәткечкә – 70,2% ка тигез булды.

103 нче диаграмма

2008-2016 елларда мәктәпкәчә белем бирү колачы (%))




Республиканың 12 муниципаль берәмлегендә (шәһәр округында) мәктәпкәчә белем бирү дәрәҗәсе белән тәэмин ителеш республика буенча уртача күрсәткечтән югарырак, алар арасында Азнакай (78%), Әлмәт (73,2%), Бөгелмә (77,6%), Югары Ослан (77,8%), Алабуга (82%), Зеленодольск (72,9%), Лениногорск (71,5%), Түбән Кама (81,1%), Саба (85%), Чистай (71,5%) муниципаль районнары, шулай ук Чаллы шәһәре (70,9%), Казан шәһәре (70,9%) бар.

Республиканың 33 муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү дәрәҗәсе белән тәэмин ителеш республика буенча уртача күрсәткечтән түбәнрәк, шулардан иң түбәне Аксубай (46,5%), Кайбыч (50%), Балык Бистәсе (48,9%), Тукай (44,7%) муниципаль районнарында.

Россия Федерациясе Президентының «Мәгариф һәм фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 599 номерлы Указында мәктәпкәчә белем бирүдән файдалануны тәэмин итүдә өстенлек өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балаларга бирелде. Татарстан Республикасында 2016 елда әлеге категориягә караган балаларның саны арту шартларында өч яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итү 96% тәшкил итте. 3 яшьтән өлкәнрәк балалар чираты, 2015 ел белән чагыштырганда, 2% ка кимеде. Казан шәһәрендә балалар бакчаларына чират көтүче 3 яшьтән өлкәнрәк 3 388 баладан 2553 бала (75,4%), Чаллы шәһәрендә 229 бала (6,8%), Арча муниципаль районында 127 бала (3,8%) мәктәпкәчә белем алу хокукын гамәлгә ашыра алмый. Аксубай, Әлки, Апас, Балтач, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч һәм Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Спас муниципаль районнарында балалар бакчаларына 3 яшьтән өлкәнрәк балалар чираты юк. 18 муниципаль районда балалар бакчаларына чират көтүче балаларның саны 10нан ким. Калган муниципаль районнар буенча белешмәләр диаграммада китерелде.

104 нче диаграмма

2016 елда Татарстан Республикасы районнары буенча 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларның балалар бакчаларына чираты



Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, балалар бакчаларына урнашуга ихтыяҗы булган һәм электрон чиратта торучы 3 яше тулган балаларны урыннар белән тәэмин итү ре-

спубликада 99% тәшкил итте, бу Балалар мәнфәгатендә гамәлләрнең республика стратегиясенең пландагы индикатив күрсәткечләреннән 1% ка азрак (2016 ел план күрсәткече 100% иде).

Муниципаль мәктәпкәчә оешмаларда 3 яше тулган балаларга балалар бакчаларына юлламаны өстенлекле бирү фонында ясле төркемнәре саны кими һәм, моңа бәйле рәвештә, 0 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итү дә кими. 2016 елда 0 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү белән тәэмин итү 15% тәшкил итте, Балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең республика стратегиясенең индикатив күрсәткече чиге 21% билгеләнгән иде.


1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләр өчен балалар бакчаларында урыннарның җитмәве аеруча актуаль проблема булып тора. Мәктәпкәчә мәгариф системасында ясел төркемнәре җитмәү мәсьәләсенең киеренке булуын 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә балалар бакчасына урын алу мәсьәләсе белән 63 мөрәҗәгать алыну (2015 елда – 48), шуның 55 очрагында гражданнарның 1,5 алып 3 яшькә кадәрге балаларын бакчага урнаштыру өчен юллама алуда булышлык күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүләре раслый. Тикшерүләр барышында, шул исәптән күчмә рәвештә, «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләренә (балалар бакчаларына) гаризалар алу, исәпкә кую һәм балаларны урнаштыру» муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы электрон базасында балалар бакчаларын комплектлаганда чират өлешендә хокук бозу очраклары табылмады.

2016 ел ахырына (2015 елдагы кебек үк) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына урын көтүче 0 яшьтән алып 1,5 яшькә кадәрге балалар 64 709 кешене тәшкил итте (чиратта торучыларның гомуми саныннан 54,2%). 1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балалар чираты 50 201 кеше, ягъни чиратта торучыларның гомуми саныннан 42%.

1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балаларны балалар бакчаларына урнаштыру буенча иң зур чират (1 000 кешедән артык) Казан шәһәрендә (24 430 бала), Чаллы шәһәрендә (11 151 бала), Әлмәт (3 196 бала), Түбән Кама (2 117 бала), Зеленодольск (1 564 бала) муниципаль районнарында сакланып кала. Дүрт муниципаль районда бу төркем балалар чираты 20 кешедән кимрәк: Апас (11 бала), Чүпрәле (11 бала), Кайбыч (6 бала), Яңа Чишмә (16 бала). Калган муниципаль районнар буенча белешмәләр диаграммада китерелде.

105 нче диаграмма

2016 елда Татарстан Республикасы районнары буенча 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балалар бакчаларына чират



Шулай итеп, балалар бакчаларында өстәмә урыннар булдыру буенча Татарстан Республикасында шактый чара күрелсә дә, якын киләчәктә балалар туу арта барачак дип фаразланганга күрә, 1,5 яшьтән алып 3 яшькәчә балаларны мәктәпкәчә белем бирү хокукы белән тәэмин итү мәсьәләсе актуаль булып кала.

Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә четерекле мәсьәләләрнең тагын берсе – балаларның балалар бакчаларында ***булу шартларының куркынычсызлыгын тәэмин итү***. 2016 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан үткәрелгән, шул исәптән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау кысаларында үткәрелгән тикшерүләр барышында Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2013 елның 15 маендагы 26 номерлы карарында билгеләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына урнаштыру, аларда карап тору һәм эшләү режимын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләренең бозылуы (СанПиН 2.4.1.3049-13) ачыкланды.

Җитәкчелекнең һәм хезмәткәрләрнең үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәве аркасында балалар бакчаларында балаларның сәламәтлеген һәм иминлеген саклауга юнәлдерелгән таләпләрнең җитди бозуылуына юл куелган. Кайбер очракларда реаль вәзгыять тәрбияләнүчеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә җитди зыян янавын күрсәтте. СанПиН кагыйдәләренең иң еш бозылу очраклары учреждениеләр биналарының һәм территорияләренең торышы канәгатьләндерәмүгә, санитария-эпидемиология законнары таләпләренең үтәлмәвенә, туклану оештырылуга туры килә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан, шул исәптән Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасында идарәсе белгечләрен җәлеп итеп үткәрелгән тикшерү чаралары йомгаклары буенча өч мәгариф оешмасында хокук бозу очраклары ачыкланды:

Нурлат муниципаль районының «Пчелка» балалар бакчасы» МБМББУ;

Чаллы шәһәренең «Чулпан» Балалар үстерүнең сәнгати-эстетик һәм социаль-шәхси юнәлешләренә өстенлек бирелгән 89 нчы гомуми үсеш балалар бакчасы» МБМББУ;

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Тәрбияләү һәм укыту татар телендә башкарыла торган 341 нче балалар бакчасы» МАМББУ.

Ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрелде һәм балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында бәяләмәләр аларны гамәлгә куючыларга җибәрелде.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә «балаларны карап тору һәм тәрбияләү» функцияләрен башкарганда ***мәктәпкәчә оешмалар җитәкчелегенең һәм хезмәткәрләренең*** компетентсыз һәм профессионал булмаган ***гамәлләренә (яки гамәл кылмавына) карата*** шикаятьләр алынды. Ата-аналар шикаятьләренең күбесендә тәрбиячеләрнең балалар үз-үзен тотышларын карап җиткермәүләренә һәм тәрбия алымнарының рөхсәт ителмәгән чараларын куллануга карата ризасызлык белдерелгән.

2016 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында югарыда күрсәтелгән хокук бозуларның булуын ачыклады:

Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге 293 нче балалар бакчасы» МАМББУ;

Казан шәһәре Вахитов районының «Тәрбияләү һәм укыту татар телендә башкарыла торган катнаш төрдәге 273 нче балалар бакчасы» МАМББУ;

Казан шәһәре Идел буе районының «Катнаш төрдәге 17 нче балалар бакчасы» МБМББУ.

Моңа бәйле рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны укыту, тәрбияләү, карап тору һәм карау өчен тиешенчә куркынычсыз шартлар булдыру өлешендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында бәяләмәләрне Чаллы һәм Казан шәһәрләре шәһәр округлары башлыклары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре исеменә юллады.

2016 елда мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә тагын бер четерекле мәсьәлә калыкты. Бу – ***гаилә мәктәпкәчә төркемнәренең эшчәнлеге***. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2016 елда гаилә балалар бакчаларының саны шактый кимегән: 2015 елда 45 булса, 2016 елда – 25. Республикада мәктәпкәчә гаилә төркемнәре 2010 елда, бер яктан, балалар бакчаларында урыннар кытлыгы мәсьәләсен хәл итүдә ярдәм булырга тиешле мәктәпкәчә белем бирүнең вариатив рәвешләре буларак, икенче яктан, күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәме чарасы буларак төзелә башлаганнар иде. 2016 елда күзәтчелек органнары мәктәпкәчә гаилә төркемнәре эшчәнлегенә, аерым алганда, аларда алып барыла торган белем бирү эшчәнлегенең лицензия таләпләренә җавап бирмәвенә карата шикаятьләр белдерде. Әлеге таләпне үтәү бик катлаулы, шуңа күрә күп кенә мәктәпкәчә гаилә төркемнәре ябылды. Әмма хәзерге шартларда мәктәпкәчә белем бирүнең әлеге вариатив рәвешен үстерү, иң күп урыннар соралган 3 яшькәчә һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итү вазыйфасын үз өстенә алып, балалар бакчаларында урыннар җитмәү мәсьәләсен хәл итүдә күпмедер ярдәм итә алыр иде. Моннан тыш, мәктәпкәчә гаилә төркемнәрен үстерү күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең нәтиҗәле чарасы буларак һәм күпбалалы тәрбияче аналарны эш белән тәэмин итүнең үзенчәлекле төре буларак каралырга тиеш. Мәктәпкәчә белем бирүне оештыруның вариатив рәвеше буларак мәктәпкәчә гаилә төркемнәренә ярдәм итәргә кирәк, ә аларның эшчәнлеген федераль законнар таләпләренә туры китереп уңай тәртипкә салу чараларын күрүгә һәм аның буенча карарларга кабул итүгә лаек, дип уйлыйбыз.

3.4.2. Гомуми белем

2016/2017 уку елына республикада 1419 гомуми белем бирү оешмасы эшләде:

дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр – 1339, шулардан: 239 (17,9%) югары дәрәҗәдә белем бирү программаларын гамәлгә ашыралар (169 144 кеше);

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус (коррекция) мәктәпләре һәм интернат мәктәпләр – 52 (6 631 кеше);

шифаханә тибындагы интернат мәктәпләр – 2 (240 кеше);

девиант холыклы балалар өчен махсус мәктәпләр – 1 (57 кеше);

кичке мәктәпләр – 12 (2 146 кеше);

дәүләткә карамаган мәктәпләр – 11 (1 597 кеше);

башка министрлыкларга караган мәктәпләр – 2 (159 кеше).

Статистика хисабы белешмәләре буенча, агымдагы уку елында демографик үсешкә бәйле рәвештә дәүләт (муниципаль) көндезге гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның саны, 2016 елда көтелгәнчә, артуын дәвам итте, укучылар саны 388 921 җитте.

106 нчы диаграмма


Татарстан Республикасы көндезге дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санының үзгәрүе динамикасы (кеше)



Мәгариф учреждениеләре челтәрен оптимальләштерү барышы һәм халык миграциясе фонында республикада авыл мәктәпләренең кимүе дәвам итә. 2016 елда аларның саны 12 гә кимеп, 877 гә калды, ә шәһәр мәктәпләре саны 532 булды.

107 нче диаграмма


Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл мәктәпләре нисбәте



Шул ук вакытта авыл мәктәпләрендә укучылар саны кимү, ә шәһәр мәктәпләрендә укучыларның арту тенденциясе тагын да ныгыды. Быелгы уку елында укучыларның гомуми санының 80% ын шәһәр укучылары тәшкил итә.

108 нче диаграмма


2016/2017 уку елында шәһәрләрдәге һәм авыллардагы гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны



Гомуми белем бирү оешмалары челтәренең алга таба үсүе дәвам итә, төп мәктәпләрнең саны арту һәм башлангыч һәм урта мәктәпләрнең саны кимү күзәтелә.

109 нчы диаграмма

Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмалары челтәре



2016/2017 уку елында гомуми белем бирү мәктәпләре структурасында башлангыч мәктәпләр өлеше 7,6% (102 мәктәп) тәшкил итә, анда барлык укучыларның 1,3% (4 915 кеше) исәпләнә. Башлангыч мәктәпләрнең гомуми санының 89,2% (91 мәктәп) авыл җирлегенә туры килә. Шул ук вакытта ***башлангыч мәктәпләр ябылуның тискәре тенденциясенә*** игътибарны юнәлтәсе килә. Чагыштырма анализдан күренгәнчә, 2016 елда биш башлангыч авыл мәктәбе ябылган (2015 елда аларның саны 96 иде). Башлангыч мәктәпләрне япкан очракта, мәгариф органнары, балалар мәнфәгатен кайгыртып, аларның башлангыч белемне яшәү урыны буенча алуын тәэмин итүне уйларга тиеш (мәсәлән, укытучылар йорты рәвешендә). Әлеге таләп һәрвакытта да үтәлми, бу исә, җавап итеп, тиешле чара күрү өчен нигез булып тора.

Моңа бәйле рәвештә, **Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары балаларның башлангыч белемне яшәү урыны буенча алуын тәэмин итү буенча чаралар күрергә тиеш**, дип уйлыйбыз.

Төп мәктәпләр барлык мәктәпләрнең гомуми санының 26,4% (354 мәктәп) тәшкил итә, анда барлык укучыларның 4,8% (18 073 кеше) белем ала.

Урта мәктәпләр өлеше 646% (883 мәктәп) тәшкил итә, шуның 50,6% (447 мәктәп) авыл мәктәпләренә туры килә. Республиканың урта мәктәпләрендә барлык укучыларның 93,8%ы (354 568 кеше), шуның шәһәр җирлегендәге укучыларның гомуми санының 95,2% (295 483 кеше) шәһәр мәктәпләрендә, авыл җирлегендәге укучыларның гомуми санының 75,2% (59 085 кеше) авыл мәктәпләрендә укый.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә ***мәктәпләрне ябу яисә үзгәртү процессына*** комачаулау үтенече белән

Казан шәһәреннән һәм Питрәч муниципаль районыннан мөрәҗәгатьләр алынды. Мөрәҗәгатьләрне өйрәнү барышында Казан шәһәре Яңа Савин районы «30 нчы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе буенча үзгәртеп төзелү факты расланмады.

Питрәч муниципаль районының «Белкино төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең үзгәртеп төзелүе турындагы мәсьәләне өйрәнгәндә, 5 – 9 сыйныф укучыларын Питрәч муниципаль районының «Ленино-Кокушкино урта гомуми белем бирү мәктәбе»нә мәктәп автобусы белән йөртү, ә Белкино авылындагы мәктәпнең Питрәч муниципаль районының «Ленино-Кокушкино урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең башлангыч мәктәбе филиалына үзгәртелүе билгеләнде. «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 пункты нигезендә мәктәпләрне үзгәртү бәяләү комиссияләренең уңай бәяләмәсе нигезендә башкарылган. Үзгәртеп төзү турындагы карар гамәлдәге законнар кысаларында кабул ителгән.

Белем бирү процессының укучыларның сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны тәэмин итәрлек ***куркынычсыз шартларын оештыру*** мәсьәләләре мөһим булудан туктамый.

Гомуми белем бирү оешмаларына һәр баруда һәм һәр тикшерүдә санитария-эпидемиология куркынычсызлыгы таләпләренең шул вакытта бозылуы йә һәрдаим бозылуына тап булдык.

Шулай, озак вакытлы дәваланыга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы «Болгар шифаханә интернат мәктәбе» дәүләт бюджет сәламәтләндерү гомуми белем бирү учреждениесенә килгәч, гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларның туклануын оештыруга карата «Санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар»дагы (алга таба – СанПиН 2.4.5.2409-08) санитария-эпидемиология таләпләренең тупас бозылуы ачыкланды. Мәктәптә эчү режимын оештыру, белем алучыга тәкъдим ителә торган суның сыйфаты мәсьәләсе аеруча борчу тудырды (суны күз белән караганда гына да савыттагы суның куе яшел төстә (сазлык төсендә) булуы, савытның эчке ягында яшел кунык, ә суда нинди дер кушылмаларның (утырымның) булуы күренде һәм аның куллану өчен яраксыз булуы шиксез иде). Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил баруының нәтиҗәләре буенча учреждениенең гамәлгә куючысы буларак Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бәяләмә юлланды.

2016 елның декабрендә Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәр тибындагы поселогының А.М. Булатов исемендәге күппрофильле

белем бирү лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә 15 укучының һәм бер укытучының кискен эчәклек йогышлы авыруы белән күпләп авыру очрагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте һәм Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан уртак тикшерелде. Эпидемиологик тикшерү барышында санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы режимның күпсанлы бозылуы ачыкланды. Һәр очрак буенча, җавап итеп, чаралар күрелде.

Моннан тыш, республиканың прокуратура органнарының Әгерҗе, Лениногорск, Түбән Кама муниципаль районнарының, Казан шәһәре Идел буе, Вахитов районнарының мәгариф оешмаларындагы ел дәвамында уздырылган тикшерүләре нәтиҗәләре буенча педагогик хезмәткәрләрнең медицина тикшерүләре узмыйча хезмәт эшчәнлеген башкарулары билгеле булды. Әлмәт, Биектау муниципаль районнарының, Чаллы шәһәренең мәгариф оешмалары һәм ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларында хезмәткәрләргә туберкулез авыруы булу-булмауга тикшерү узмаган көе эшләргә рөхсәт бирелгән.

Әлеге фактлар **гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең һәм җитәкчелегенең компетенция дәрәҗәсен күтәрүнең һәм республика мәктәпләре эчендә белем бирү процессының куркынычсыз шартларын тәэмин итү өчен җаваплылыкны арттыруның зарур булуын күрсәтә.**

Укучыларны гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру мәсьәләләре актуаль булып кала.

Шулай, Аксубай муниципаль районында шәхси кабул итү барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә балаларны баз мәктәпкә алып бару һәм аннан алып кайту буенча транспорт хезмәте күрсәтелмәү мәсьәләсе буенча Ерепкино авылының бер кешесе мөрәҗәгать итте. Әлеге мөрәҗәгать буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Аксубай муниципаль районының башкарма комитеты белән тыгыз элемтәдә эшләве нәтиҗәсендә яңа мәктәп автобус маршруты ачылды һәм Ерепкино авылында яшәүче укучыларны «Яңа Тимошкино төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә бушлай йөртү оештырылды.

Әлеге мәсьәлә буенча 2016 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан ясалган мониторинг 13 муниципаль районда һәм Казан шәһәренең 2 районында 54 торак пунктттан укучыларны транспорт белән китерү оештырылмаган йә оештырылган булуын, әмма тиешенчә башкарылмавын күрсәтте. Мондый хәлләр балаларның – гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның һәркем файдалана алырлык белемгә хокукы бозылуны һәм аларның тормышына, сәламәтлегенә һәм иминлегенә куркыныч янауны күрсәтә.

Югарыда күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетлары акчалары укучыларны транспорт белән йөртүне тиешенчә тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җитәрлек булмаганга күрә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил юл өслеген норматив хәлгә китерү һәм өстәмә рәвештә мәктәп автобуслары сатып алу эшләрен республика бюджетыннан финанслау (финанслашу) мөмкинлеген табу турындагы мәсьәләне карау үтенече белән Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы 2017 елга эш планына төзәтүләр кертте.

Республиканың прокуратура органнары тикшерүләре нәтиҗәсендә шулай ук Казан шәһәренең Совет районында, Әгерҗе, Азнакай, Биектау, Чүпрәле, Мамадыш, Кама Тамагы, Бөгелмә, Түбән Кама, Мөслим, Нурлат, Питрәч муниципаль районнарында балалар йөртүне оештыруны регламентлаштыра торган законнар бозылу очраклары ачыкланды.

Укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне муниципаль берәмлектән, Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясеннән ***читкә алып чыгуны оештыруга карата*** гамәлдәге законнарда куелган таләпләрнең дәүләт (муниципаль) оешмалар тарафыннан үтәлүе мәсьәләсенә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аерым игътибар бирде.

Шулай, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чараларыннан 2016 елның 29 июнендә Стамбул шәһәре (Төрек Республикасы) аэропортында булган теракт вакытында Татарстан Республикасыннан балалар төркеменең дә шул аэропортта булуы турында хәбәрдар булды. Әлеге очрак буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз тикшерүен үткәрде. Тикшерү барышында Чаллы шәһәренең «Балалар хореография мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесенең «Бисеринки» халык ансамблен «Дөнья, Сәнгать һәм Диңгез» V Күпжанрлы фестиваль-конкурсында катнашу өчен Варна шәһәренә (Болгария) алып баруны оештырганда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләренең тупас бозылуы билгеле булды. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча Чаллы шәһәре мэры Н.Г. Мәһдиев исеменә балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында бәяләмә җибәрелде, аны караганнан соң дисциплинар акча түләтүнең тиешле чаралары күрелде һәм алга таба мондый очракларны булдырмауга юнәлтелгән берничә чара үткәрелде.

Мәгариф оешмаларында белем алучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне башка җиргә алып чыгуны оештырганда балаларның иминлеген тәэмин итүне көчәйтү максатларында Татарстан Республикасында Бала хокукла-

ры буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саный:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек Саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына **алар карамагындагы дәүләт (муниципаль) оешмалар тарафыннан укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне муниципаль берәмлектән, Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясеннән читкә алып чыгуны оештыруга карата гамәлдәге законнарда куелган таләпләрне берсүзсез үтәүләрен тәэмин итәргә**.

Мәктәпләрдә уку процессында катнашучылар арасында конфликтлы хәлләр барлыкка килү мәсьәләләре буенча ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алынган мөрәҗәгатьләрнең саны Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдә шактый зур борчу уята. 2016 елда шундый 75 шикаять керде, алар балаларның белем алуга хокукын яклау темасы буенча мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 20,7% тәшкил итте. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: мәктәпләрдә конфликтлы хәлләр проблемасы инде берничә ел рәттән үзенең актуальлеген югалтмый. Шулай, 2015 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан шундый 75 шикаять каралды, бу мәгариф тематикасы буенча мөрәҗәгатьләрнең гомуми санының 36% тәшкил итте.

Гражданнарның мәктәпләрдәге конфликтлы хәлләргә зарларын караганда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ата-ананың (законлы вәкилнең) шикаять белән мөрәҗәгать итүе мәгариф учреждениесендә балалар йә бала катнашында конфликтлы хәл тууга дәлил булып тора. Берсүзсез, мәктәптәге теләсә-нинди каршылыклы очрак – тискәре, психикага зыян китерә торган фактор, ул баланың (балаларның) шәхесе формалашуның һәм белем, һәм тәрбия ягына да йогынты ясый. Мәктәп конфликтлары барлыкка килү белем алучыларның хокуклары бозылуны китереп чыгара һәм теләсә нинди очракта аларның мәнфәгатьләренә каршы килә. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон нигезендә мәгариф оешмасында белем һәм тәрбия алуның физик һәм психик сәламәтлек өчен уңай һәм куркынычсыз булган шартлар тудырылырга тиеш. Мондый мохитне тудыру законда мәгариф оешмасының педагоглар коллективы һәм җитәкчелеге компетенциясенә кертелгән, ә җаваплылык мәгариф оешмасы администрациясенә беркетелгән.

Бәян ителгән хокукый позициягә нигезләнеп, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мәктәптә теләсә-нинди каршылыклы очрак барлыкка

килү балаларның – мәгариф оешмасында укучыларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылуга китерә, дип саный, шуңа күрә конфликтка ризасызлык белдерелгән мөрәҗәгатьнең һәр очрагы буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең тиешле бәяләмәсе җибәрелә, аларда барлыкка килгән вәзгыятьне балалар мәнфәгатьләрендә хәл итү, киләчәктә мондый очракларны булдырмау чараларын күрүне һәм, кирәк булган очракта, аның барлыкка килүендә йә аны хәл итү буенча чаралар күрелмәүдә гаепле вазыйфаи затларны законнарда каралган җаваплылыкка тарту таләп ителә.

Моның белән бергә гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча үткәрелгән тикшерү гамәлләре буенча 2016 елда белем бирү процессының тиешенчә оештырылмавы, педагогик булмаган тәрбияләү алымнарын кулланылу, балигъ булмаганның конфликтның аның сәламәтлегенә зыян китерә торган, психик җәрәхәт сала торган хәлдә калуы белән бәйле хокук бозуларның түбәндәге мәгариф оешмаларында булуы ачыкланды:

«Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадет интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә;

Биектау муниципаль районының «Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «5 нче Арча гимназиясе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Яңа Савин районының «165 нче инглиз телен тирәнтен өйрәнү урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесендә;

Балтач муниципаль районының «Смәил урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Ютазы муниципаль районының «4 нче Урыссу төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Чистай муниципаль районының «Кызылъяр төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Идел буе районының «6 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Вахитов районының «1 нче аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учрежденисендә;

Казан шәһәре Идел буе районының «114 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Мәскәү районының «120 нче аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Совет районының «159 нчы лицей» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Идел буе районының «Татар телендә укыту белән 18 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Казан шәһәре Совет районының «166 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Чаллы шәһәренең «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Чаллы шәһәренең «78 нче Пушкин пролицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;

Түбән Каманың «28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә;.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында бәяләмәләр мәгариф оешмаларының гамәлгә куючылары булган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Арча, Биектау, Балтач, Чистай, Ютазы муниципаль районнарының, Чаллы һәм Казан шәһәрләре шәһәр округлары җирле үзидарә органнары башлыклары һәм җитәкчеләре исеменә бәяләмәләр юлланды.

Мисал. *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә элек Казан шәһәре Идел буе районының «6 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең 4 нче сыйныфында укыган М. исемле балигъ булмаганның ата-аналарыннан мөрәҗәгать алынды: сентябрь аенда М., үзенең сыйныфташлары К., Г. һәм А. тарафыннан кыйналганнан соң, «ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең нейрохирургия бүлегенә салына. Гариза бирүчеләр үз мөрәҗәгатьләрендә барлыкка килгән каршылыклы хәлне объектив анализлау һәм аны хәл итү өчен Т. исемле сыйныф җитәкчесенең чаралар күрмәвен күрсәтәләр. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьне карап тикшергәннән соң, балигъ булмаганның хокуклары бозылу турында бәяләмә гамәлгә куючы исеменә юлланды.*


Мисал*. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә Ютазы муниципаль районының «Урыссу 4 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең 1 нче сыйныфында балигъ булмаган улы уку мәсьәләсе буенча Н. мөрәҗәгате керде. Башлангыч сыйныфлар укытучысы, укыту-тәрбияләү процессын оештырганда, улының сыйныфташлары алдында аңа карата аны түбәнсеткән сүзләр белән мөрәҗәгать иткән, тәрбия бирүнең педагогик булмаган алымнарын кулланган. Моңа бәйле рәвештә бала аның сәламәтлегенә зыян китерә торган психикасын бозарлык хәлдә калган. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаганның хокуклары бозылу турында бәяләмәне Ютазы муниципаль районы башлыгы исеменә юллады.*

Мисал. *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә Түбән Кама шәһәренең «28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең 5 нче сыйныфында белем алучы балигъ булмаган З. әнисе юллаган мөрәҗәгать мәктәптә укыту-тәрбияләү процессын оештырганда балигъ булмаган З. хокукларының бозылуы турында иде. Шулай, З. физкультура укытучысы, сыйныфташлары алдында баласына мөрәҗәгать иткәндә, тиешле булмаган сүзләрне кулланган, ә Х. тарих укытучысы дәрес вакытында тәрбияләүнең педагогик булмаган алымнарына юл куйган (ташланган кәгазьне укучының якасы эченә салган). Сыйныф җитәкчесе дә, мәгариф оешмасы директоры да мәктәптәге каршылыклы хәлне бетерү өчен тиешле чаралар күрмәгәннәр. Шуңа күрә конфликтка З. сыйныфташлары да һәм аларның ата-аналары да килеп кушылган, шуңа күрә бала аның сәламәтлегенә зыян китерә торган психикасын бозарлык хәлдә калган. Мөрәҗәгатьне карап тикшерү йомгаклары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Түбән Кама шәһәре башлыгы исеменә балигъ булмаганның хокуклары бозылу турында бәяләмә юллады, аны карауның дәвамы буларак, мәктәп буенча боерык белән Х. исемле укытучыга вазыйфа кулланмасында каралган хезмәт бурычларын үтәмәгән, балага карата рәхимсезлек кылган өчен шелтә белдерелгән. Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсе Л. исемле мәктәп директорына белем алучыларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуга киләчәктә юл куймау максатларында закон таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны көчәйтергә тәкъдим ителде.*

Мәгариф өлкәсендә конфликтларны профилактикалау мәсьәләләренең актуальлеге сакланып калганга күрә, мәктәпләрдә квалификацияле психологик ярдәм хезмәтләрен оештыру мәсьәләләре аерым әһәмият ала. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта республикадагы 1 419 учреждениенең 383 гомуми белем бирү оешмасында гына психолог педагоглар эшли.

110 нчы диаграмма

2011-2015 елларда гомуми белем бирү оешмаларында психологик ярдәм структурасы



Квалификацияле психологлар кадрларына кытлык булуны исәпкә алып, 2014 елда республика районнарында һәм шәһәрләрендә грант

ярдәме белән муниципаль психологик-педагогик хезмәтләр төзелә башлады. Бүгенге көндә психологик-педагогик үзәкләр һәм хезмәтләр республиканың 25 районында эшли. Аларның эшчәнлеге кысаларында 345 белгеч тарафыннан балаларга һәм балалы гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтелә.

Әлеге хезмәтләр Азнакай, Балтач, Биектау, Алабуга, Нурлат, Тәтеш, Әгерҗе, Буа, Менделеевск, Әлки, Актаныш, Апас, Югары Ослан, Зәй, Ютазы, Минзәлә һәм Саба муниципаль районнарында шактый уңышлы эшләп килә. Аларны Зеленодольск һәм Түбән кама муниципаль районнарында алга таба үстерү һәм камилләштерү өчен мөмкинлекләр туплангган. Лаеш, Бөгелмә муниципаль районнарында һәм Чаллы шәһәрендә хезмәтләрнең эше нәтиҗәле оештырылмаган.

Моннан тыш, мәктәп конфликтларын профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерүнең тагын бер ысулы буларак мәгариф оешмаларында уку-укыту мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында низагларны җайга салу комиссияләрен оештыруны карарга кирәк.

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада уку-укыту мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында низагларны җайга салу комиссиясен (алга таба – Комиссия) «Россия Федерациясендә мәгариф турында Федераль законның 45 статьясында каралган. Мондый Комиссия уку-укыту мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында белемгә хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча низагларны җайга салу максатларында, шул исәптән педагогик хезмәткәр мәнфәгатьләрендә каршылык барлыкка килгән, локаль норматив хокукый актлар кабул ителгән, белем алучыларга карата дисциплинар акча түләтүне куллану турындагы карарларга шикаять белдерелү очракларында һәр мәгариф оешмасында төзелергә тиеш. Комиссия тигез сандагы балигъ булмаган белем алучылар вәкилләреннән, балигъ булмаган белем алучыларның ата-аналарыннан, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма хезмәткәрләреннән төзелә. Төзү, эшне оештыру, Комиссия тарафыннан карарлар кабул итү, аларны үтәү тәртибе мәгариф оешмасының локаль норматив акт белән билгеләнә, ул белем алучылар советлары, ата-аналар советлары, шулай ук әлеге оешма хезмәткәрләренең һәм (яки) анда белем алучыларның вәкиллекле органнары фикерләрен исәпкә алып кабул ителә. Әлеге Комиссиягә белем алучылар, балигъ булмаган белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре), үз хокукларын яклау максатларында, мөстәкыйль яки үзләренең вәкилләре аша мөрәҗәгать итә алалар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдә республика мәктәпләрендә мондый Комиссияләрнең эшчәнлеге турында мәгълүмат юк. Ә бит алар мәктәп конфликтлары вәзгыятенә уңай йогынты ясауның чын коралы була алыр иде.

Республика мәктәпләрендәге конфликтларның психикага зыян салырлык очраклары барлыкка килүне профилактикалау максатларында **системалы рәвештә түбәндәге профилактика чараларын күрергә кирәк дип саныйбыз**.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мәгариф оешмаларының, муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген бәяләү критериеләренә мәгариф оешмаларының эшчәнлегенә карата ата-аналар тарафыннан бирелгән, шул исәптән прокуратура, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, башка контроль-күзәтчелек органнары исеменә җибәрелгән нигезләнгән шикаятьләрнең булуы белән бәйле күрсәткеч кертергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән берлектә:

муниципаль берәмлекләрдә психологик-педагогик хезмәтләр төзү эшен дәвам итәргә;

мәгариф оешмалары каршында уку-укыту мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында низагларны җайга салу буенча комиссияләр төзелүне тәэмин итәргә;

педагогларның үз-үзләрен конфликтсыз тоту күнекмәләрен булдыру өчен өстәмә рәвештә социаль-психологик һәм оештыру-идарә чаралары комплексын күрергә.

2016 елда республиканың ***мәгариф оешмаларына балаларның укырга керүенә*** кагылышлы гражданнар мөрәҗәгатьләре аерым игътибарга алынды. Шулай, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә балигъ булмаганнарны 1 һәм 10 сыйныфларга укырга алуда мәктәп администрацияләренең баш тартуына кагылышлы 16 мөрәҗәгать керде.

Казан шәһәре мәктәпләрендә белем алучы балаларның ата-аналарыннан – 10, Чаллы шәһәрендә - 4, Баулы районында – 1 мөрәҗәгать, Кама Тамагы муниципаль районыннан ата-аналар исеменнән 1 күмәк мөрәҗәгать алынды, аларда, шул исәптән, түбәндәге мәгариф оешмаларына кабул итү мәсьәләләре күтәрелгән иде:

Баулы муниципаль районының «Ю.А.Гагарин исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Вахитов районының «18 нче инглиз телен тирәнтен өйрәнү урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Совет районының «159 нчы лицей» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә (3 мөрәҗәгать);

Казан шәһәре Совет районының «90 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Совет районының «93 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Мәскәү районының «94 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «145 нче лицей» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәренең «166 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

«Советлар Союзы Герое Чирков Михаил Алексеевич исемендәге Кама Тамагы кадет интернат мәктәбе дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Вахитов районының «96 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге кадет мәктәбе дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә.

Гомуми белем бирү оешмасының ***1 нче сыйныфына кабул итүдә баш тарту*** турындагы мөрәҗәгатьләрне карау барышында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясы һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы белән расланган башлангыч, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибе (алга таба – Кабул итү тәртибе) бозылу очраклары билгеле булды.

Кабул итү тәртибе түбәндәгечә бозылган:

1. Аерым мәгариф оешмаларының педагоглары булачак беренче сыйныф укучыларын сыйныфларны туплау өчен баланың мәктәпкә әзерлек дәрәҗәсен тикшергәннәр;

2. Гаризалар кабул итү журналында кайбер ата-аналарның гаризалары теркәлмәгән;

3. Беркетелгән территориядә яшәмәгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмасының беренче сыйныфына гаризалар кабул итү шул елның 1 июленә кадәр үк башланган.

Моның белән бергә гражданнар шикаятьләрен карау барышында беренче сыйныфка гаризалар бирүнең электрон системасы эшенең тиешле дәрәҗәдә оештырылмау очраклары ачыкланды. Мәгълүмат сервисы эшендәге өзеклекләр балаларның белемгә хокуклары кысылуга китергән.

10 нчы сыйныфка кабул итүдә баш тарту турындагы мөрәҗәгатьләргә анализ әлеге баш тартуларның сәбәпләрен билгеләргә мөмкинлек бирде. Әйтик, алар нигездә урта гомуми белем баскычында профильле белем бирүне башкаруга, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Аерым уку предметлары тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яки профильле белем алу өчен Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул иткәндә йә күчергәндә белем алучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 27 февралендәге 1156/15 номерлы боерыгы белән расланган Аерым уку предметлары тирәнтен өйрәнелә торган төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен яки профильле белем алу өчен Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул иткәндә йә күчергәндә белем алучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибен гамәлгә ашыруга бәйле булган.

10 нчы сыйныфка кабул итүдән баш тарту мәсьәләләре буенча түбәндәге мәгариф оешмаларына кагылышлы шикаятьләр керде:

Баулы муниципаль районының «Ю.А.Гагарин исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Вахитов районының «18 нче инглиз телен тирәнтен өйрәнү урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Совет районының «159 нчы лицей» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Совет районының «90 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Совет районының «93 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «145 нче лицей» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә;

Казан шәһәренең «166 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

«Советлар Союзы Герое Чирков Михаил Алексеевич исемендәге Кама Тамагы кадет интернат мәктәбе дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном мәгариф учреждениесенә;

Чаллы шәһәренең «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә.

Мөрәҗәгатьләрне карап тикшергәннән соң, 11 мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләр уңай хәл ителде, балигъ булмаганнар элек аларны кабул итүдән баш тарткан гомуми белем бирү мәктәпләренә кабул ителделәр. Өч очракта балигъ булмаганнар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гозернамәсе белән, мөрәҗәгать итүчеләрнең теләкләрен исәпкә алып, башка гомуми белем бирү оешмаларына кабул ителделәр.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү барышында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законы таләпләре нигезендә мәгариф оешмалары сайтларына гамәлгә ашырыла торган уку-укыту программалары турында, һәр уку-укыту программасы буенча кабул итү (күчерү) өчен вакантлы урыннар саны турында мәҗбүри мәгълүматны, оешмага белем алучылар кабул итү кагыйдәләрен регламентлаштыра торган локаль норматив актлар күчермәләрен урнаштыру һәм яңартуның үз вакытында башкарылмавы, йә кабул итү кагыйдәләрендә белем алучыларның укырга керү регламенты турында мәгълүматның ачык бирелмәве, белем алучыларны индивидуаль сайлап алу критерие булмавы, шул сәбәпләр аркасында ата-аналарның белем алучыларны 10 нчы сыйныфка кабул итү кагыйдәләре белән танышу мөмкинлекләре булмавы ачыкланды.

1 нче һәм 10 нчы сыйныфларга кабул иткәндә балаларның белем алуга хокуклары бозылуга юл куймау максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип уйлыйбыз:

расланган кабул итү тәртибе бозылуга юл куймау максатларында закон таләпләренең үтәлешенә контрольне көчәйтергә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законы таләпләре нигезендә мәгариф оешмалары сайтларына мәгълүматны үз вакытында урнаштыру һәм яңарту буенча чаралар күрүне тәэмин итәргә;

мәгариф оешмасына кабул итү турында гариза бирү электрон сервисының тиешенчә эшләвен тәэмин итәргә;

оешмага белем алучылар кабул итү кагыйдәләрен регламентлаштыра торган локаль актларны аларның законнарга туры килү-килмәвен тикшерергә, туры килмәү ачыкланган очракта, аларга тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы икенче өлешенең өченче абзацында һәм 351.1 статьясында ***педагогика эшчәнлеге белән һәм*** балигъ булмаганнар катнашында мәгариф, тәрбия,

балигъ булмаганнарның үсеше, аларның ялын һәм сәламәтлөнүен оештыру, медицина, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итү, балалар-яшүсмерләр спорты, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә ***теләсә нинди башка төр эшчәнлек белән шөгыльләнүне*** шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм вөҗданына каршы (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан, яла ягудан һәм хурлаудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгы һәм җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, дәүләтнең конституциячел төзелеш нигезләренә һәм иминлегенә, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаять өчен элек хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвендәге кешеләргә (реабилитация нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш) ***тыю*** мәсьәләсе Татарстан Республикасы Прокуратурасы һәм мәгариф органнарының махсус контролендә кала.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җитәкчеләре исеменә берничә тапкыр мөрәҗәгать итсә дә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2016 елдагы эш тәҗрибәсе һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре күрсәтелгән закон таләпләре үтәлмәүнең аерым очраклары булуны раслады.

Татарстан Республикасы прокуратурасы үткәргән тикшерү чаралары йомгаклары буенча, элеккечә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы икенче өлешендәге һәм 351.1 статьясындагы закон таләпләренең бозылу очраклары булу ачыкланды. Шулай, Тукай, Сарман районнарында, Чаллы, Лениногорск шәһәрләрендә, Казан шәһәренең Совет, Вахитов районнарында мәгариф оешмаларына педагогик хезмәткәрләрне кабул итү, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясын бозып, хөкем ителү (ителмәү) турында белешмә тапшырылмыйча башкарылган.

Бу уңайдан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары республикада балаларны тулаем Татарстан Республикасында төрле балалар учреждениеләре хезмәткәрләре тарафыннан җинаять кылулардан һәм тәрбия бирүнең педагогик булмаган алымнарын кулланудан яклау мәсьәләсен хәл итүгә зур игътибар бирергә тиеш, дип саныйм.

2016 елда, гражданнардан мөрәҗәгатьләр алыну сәбәпле, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***кайбер башлангыч сыйныф***

укытучыларының аерым дәресләр буенча дәреслекләргә һәм уку әсбапларына өстәмә рәвештә эш дәфтәрләрен үзлектән сатып алуны белем алучыларның ата-аналарыннан хаксыз таләп итүләре мәсьәләсен карап тикшерде.

Россия Дәүләт стандартының 2003 елның 25 ноябрендәге 331-ст номерлы карарында каралганча, «уку басмалары»на түбәндәгеләр керә:

дәреслек – уку дисциплинасын, аның бүлеген, өлешен системалы бәян иткән, уку программасына туры килгән һәм әлеге төр басма буларак рәсми расланган уку басмасы;

уку әсбабы – әлеге төр басма буларак рәсми расланган дәреслеккә өстәмә булган яки аны өлешчә яисә тулысынча алыштыра торган уку басмасы;

эш дәфтәре – укучыны уку предметын үзләштерү өчен үзлектән эшләргә өйрәтә торган аерым дидактик аппараты булган уку әсбабы. Эш дәфтәрләре дәреслеккә өстәмә дә түгел һәм аны өлешчә яки тулысынча да алыштырмый, ә мөстәкыйль басма булып торалар.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның (алга таба – Закон) 28 статьясындагы 2 өлеше нигезендә мәгариф оешмалары белем эчтәлеген билгеләгәндә, уку-методика тәэминатын сайлаганда, алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган белем бирү технологияләрен сайлаганда ирекле була, уку-методика һәм дидактика материаллары укытучы теләге белән эш программасына кертелергә мөмкин. Законның 47 статьясындагы 3 өлешенең 4 пунктында каралганча, педагогик хезмәткәрләр мәгариф оешмасының уку-укыту программасына туры килә торган дәреслекләрне ирекле сайлап алырга һәм кулланырга хокуклы һәм уку материалларын сайлап алу иреген нинди дә булса чикләргә тырышулар рөхсәт ителми.

Укытучы предмет буенча эшләү программасын мәктәп китапханәсе фондына Законның 28 статьясындагы 3 өлешенең 9 пункты нигезендә оешма җитәкчесе тарафыннан расланган дәреслекләр исемлегенә туры китереп кайтартылган дәреслекләрдән чыгып төзи. Ул шулай ук укыту-методика комплектына керә торган теләсә нинди уку материалыннан файдалана ала.

Законның 35 статьясындагы 1 пункты нигезендә белем алучыларга дәреслекләр һәм уку әсбаплары, шулай ук укыту-методика материаллары, укыту һәм тәрбияләү чаралары аларның белем алу чорына файдалануга бушлай бирелә, моннан чыгып, белем алу чорына файдалануга бушлай бирелгән дәреслекләр һәм уку әсбаплары мәгариф оешмасына кире кайтарылырга тиеш.

Эш дәфтәре уку әсбабыннан аерып чыгарылган һәм бер тапкыр индивидуаль файдалана торган уку басмасы булып тора, мәктәп китапханәсе


фондына ул кире кайтарыла алмый. Уку процессында эш дәфтәреннән файдалану мәҗбүри түгел. Ата-аналарны эш дәфтәрләрен үз акчаларына сатып алырга мәҗбүр итүгә рөхсәт юк.

Мәгариф оешмаларында белем алмаучы (дәресләргә йөрмәүче) 7 – 18 яшьлек балаларның һәм яшүсмерләрнең булуы проблемасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибар үзәгендә. БМОның Бала хокуклары турында Конвенциясенең 28 статьясындагы 1 өлешендә мәктәпне ташлаган укучыларның мәктәпкә даими йөрүләренә булышу һәм аларның санын киметү чараларын күрү бурычына махсус басым ясалу әлеге мәсьәләнең әһәмиятен раслый. Моның белән бергә төп гомуми белемнең мәҗбүри һәм һәркем файдалана алырлык булуы Россия Федерациясе Конституциясе нормаларында гарантияләнгән.

«Мәгариф оешмаларында белем алмаучы 7 – 18 яшьлек балаларның һәм яшүсмерләрнең саны турында белешмәләр» 1-НД статистика хисабы мәгълүматларына караганда, республикада төрле сәбәпләр аркасында мәгариф оешмаларына йөрмәүче балаларның саны кими бара. Узган ел белән чагыштырып караганда, аларның саны 231 кешегә (28% ка) кимеде һәм 598 кешегә калды.

111 нче диаграмма


2013 – 2016 елларда мәктәпкә йөрмәүче мәктәп яшендәге балалар саны



Әлеге статистика хисабына ясалган анализ 598 баладан 289 яшүсмернең 14 – 17 яшьлек, 309 баланың 13 яшькә кадәрге кече яшьтәге балалар булуын күрсәтте.

112 нче диаграмма

2016/2017 уку елында мәктәпкә йөрмәүче мәктәп яшендәге балалар саны



598 баладан бары тик 491 бала (82%) сәламәтлекләре торышы аркасында мәктәпкә йөрми, шул исәптән 250 баланың сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән. Калган 107 бала укуларын бөтенләй башламаган. Шулардан 82 балигъ булмаган бала эшкә урнашу сәбәпле, ә 25 бала – башка сәбәпләр аркасында укуларын ташлаган. Шунсы игътибарны җәлеп итә: 5 – 9 сыйныфлардан 10 бала, мәҗбүри төп гомуми белем алмыйча, төшеп калган.

Моның белә бергә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның (алга таба – Закон) 3 статьясындагы 1 пункты нигезендә Россия Федерациясе мәгариф тармагын өстенлекле дип игълан итә. Дәүләт һәр кешенең белемгә хокукын гарантияли (Законның 5 статьясы). Законның 66 статьясындагы 5 пункты нигезендә башлангыч гомуми белем, төп гомуми белем, урта гомуми белем белемнең мәҗбүри баскычлары булып тора. Урта гомуми белемнең мәҗбүри булу таләбе белем алучының 18 яшенә җиткәнче үз көчен саклый. Гомуми белем алу рәвешен һәм төп гомуми белем бирүнең төгәл билгеле программасы буенча уку рәвешен балигъ булмаган белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) билгели.

Балигъ булмаган белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) гомуми белем алу рәвешен һәм төп гомуми белем бирүнең төгәл билгеле программасы буенча уку рәвешен сайлап алганда бала фикерен исәпкә алалар. Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, белем алу өчен тиешле социаль-икътисадый шартлар булдырып, төрле баскычлардагы һәм юнәлешләрдәге белемне бөтен гомер дәверендә алу мөмкинлекләрен киңәйтеп, һәр кешенең белем алуга хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары гомуми белем алуга хокуклары булган һәм тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче балаларның һәм балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) билгеләнгән белем алу рәвешләренең исәбен алып бара (Законның 63 статьясындагы 5 пункты). Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр мәгарифкә идарә итү органыннан тулаем белем бирүгә кагылышлы керә торган мәгълүматны анализлыйлар, профилактика субъектлары белән берлектә балигъ булмаганнарның дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында йөрмәүләренә сәбәп булган шартларны бетерү буенча чаралар күрәләр.

Алга таба шәхес булып җитешүдә һәм баланың үсешендә төп гомуми белем алуның әһәмиятен аңлап, балигъ булмаганнар белән эшләүне оештыруның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында **тәкъдим итәм**:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, нинди ведомствога каравына бәйсез рәвештә, барлык типтагы һәм төрдәге мәгариф оешмаларына дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында (системалы рәвештә) йөрми торган балигъ булмаганнарны ачыклау һәм исәпкә кую буенча методик тәкъдимнәр эшләргә;

балигъ булмаганнарның эшләре буенча муниципаль комиссияләргә, нинди ведомствога каравына бәйсез рәвештә, барлык типтагы һәм төрдәге мәгариф оешмаларына дәресләргә җитди сәбәпләрсез озак вакыт дәвамында (системалы рәвештә) йөрми торган балигъ булмаганнарны ачыклау һәм исәпкә кую буенча эшнең оештырылуы өлешендә мәгариф оешмаларында, мәгарифкә идарә итү органнарында тикшерүләр оештырырга;

Әлеге эшне 2017 елда үткәрү йомгакларын Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе утырышында карарга.

3.4.3. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү

Балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруда иң проблемалы мәсьәләләрнең берсе сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларның әлеге хокукны гамәлгә ашыруны оештыруның гамәлдәге системасын модернизацияләү (реформалау) зарурлыгыннан гыйбарәт.

Халыкара хокук, федераль законнар нигезендә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү рәвеше буларак инклюзив белем бирү – белем алуга булган махсус ихтыяҗларның һәм индивидуаль мөмкинлекләрнең күптөрлелеген исәпкә алып, барлык белем алучыларның белемне тигез ала алуын тәэмин итү билгеләнергә тиеш (Законның 2 статьясы). Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирүне оештыруның Законда билгеләнгән системасы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү башка белем алучылар белән дә, аерым сыйныфларда, төркемнәрдә дә яисә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган аерым оешмаларда да оештырылырга мөмкин булган белемне күз алдында тота (Законның 2 статьясындагы 4 өлеше). Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы белән расланган 2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең илкүләм стратегиясендә, инвалид балаларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга дәүләт ярдәме буларак каралган чараларга өстәп, аларның барлык баскычларда сыйфатлы белемне тигез дәрәҗәдә алу мөмкинлеген тәэмин

итү кертелгән, аларның инклюзив белем алуга хокукларын яшәү урыны буенча гамәлгә ашыру, шулай ук ата-аналарның балалары өчен мәгариф оешмасын һәм белем алу рәвешен сайлап алу хокукы гарантияләнгән.

2016 елның 1 сентябрендә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2014 елның 19 декабрендәге 1598 номерлы боерыгы белән расланган Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт мәгариф стандарты (алга таба– Стандарт) үз көченә керде. Стандарт ишетмәүче, начар ишетүче, соңрак чукракланган, сукыр, начар күрүче, авыр сөйләшүче, начар хәрәкәтләнүче һәм психик үсеше тоткарланган, аутистистик спектрлы, катлаулы дефектлары булган укучыларны үз эченә алган төркемнәрнең белем алуы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала. Стандарт мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы барлык оешмаларда да башлангыч белем бирүнең яраклаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда бердәм мәҗбүри таләпләр җыелмасын тәшкил итә. Бу программаларны гамәлгә ашыру башка белем алучылар белән дә, аерым сыйныфларда, төркемнәрдә дә яисә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган аерым оешмаларда да оештырылырга мөмкин. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирүнең бердәм алымнарын, шартларын һәм нәтиҗәләрен билгеләп, Стандарт мондый үзенчәлекле балаларга белем бирү өлешендә Россия Федерациясенең барлык мәктәпләре өчен дә бердәй белем бирү киңлеген булдырачак. Бу сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга яшәү урынына һәм укыту төренә карамастан белем алуда тигезлекне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Шулай итеп, Стандарт инклюзив белем бирү мохитендә балага белем бирүне оештыру механизмы булып тора.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф (алга таба – ФДМ) стандартын һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) белем алучыларга белем бирү ФДМ стандартын Татарстан Республикасында кертү буенча региональ координатор итеп «Татарстан Республикасы мәгарифен үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе билгеләнде.


Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, инвалидларны реабилитацияләү буенча чараларны гамәлгә ашыручы учреждениеләр белән берлектә үзара хезмәттәшлеккә нигезләнеп, инклюзив үзәкләр төзелгән мәгариф оешмаларын билгеләгән.

Гомуми белем бирү оешмасы	Социаль партнерлар
Казан шәһәре Идел буе районының «78 нче мәктәп» МБМУ	«Солнечный» сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе
Казан шәһәре Мәскәү районының «75 нче мәктәп» МБМУ	«Апрель» сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге
Казан шәһәре Совет районының «156 нчы мәктәп» МБМУ	«2 номерлы Казан балалар психоневрология шифаханәсе» ДАССУ
Зеленодольск муниципаль районының «А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» МБМУ	Зеленодольск муниципаль районының «Доверие» сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге

Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы белешмәләре буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (алга таба – СМЧ) балаларның гомуми саны ел саен арта бара.

113 нче диаграмма

2013 - 2016 елларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (СМЧ) балалар саны



2016/2017 уку елында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп балаларының саны 18 040 бала яисә республикадагы барлык балаларның 2,3% тәшкил итте. Алар арасында мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны 4 216 кеше, мәктәп яшендәге балалары саны 13 824 кеше тәшкил итте. Узган ел белән чагыштырганда аларның саны 1,7% ка яисә 306 балага артты.

114 нче диаграмма


2016/2017 уку елында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар саны



Мәгарифкә идарә органнарында исәптә торган сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән **мәктәпкәчә яшьтәге** 4 216 баланың иң зур өлешен сөйләмнәре бозылган (34,8%) һәм терәк-хәрәкәт системасында тайпылышлары булган (21,7%) балалар алып тора. Узган ел белән чагыштырганда, күрү сәләте бозылган (4,6% ка күбрәк), сөйләме бозылган (13,7 % ка күбрәк) һәм ДЦП булган (5,2% ка күбрәк) балаларның саны арта бара, ә акыл үсешендә тоткарлыклар булган балалар саны 2015 елга караганда 2,3% ка кимеде.

115 нче диаграмма


2015 – 2016 елларда авыру төрләре буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны



2016/2017 уку елында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәгарифкә идарә органнарында исәптә торган балаларның гомуми санының 84% тәшкил итте (2015 елда – 82,5%). Авыру төрләре буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны 116 нчы диаграммада күрсәтелде.

116 нчы диаграмма


2016 елда авыру төрләре буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү



Белем бирүнең аерым шартларда алып барылуы таләп ителгән мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирүгә ясалган анализ быелгы 2016/2017 уку елында махсуслаштырылган мәктәпкәчә учреждениеләргә яки төркемнәргә йөрүче балалар санының 8,3% артуын күрсәтте (2015 елда 1 821 бала булса, 2016 елда 1 972 бала булды).

117 нче диаграмма

2012 – 2016 елларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның мәктәпкәчә белем белән тәэмин ителүе



Шулай итеп, бүген республикада сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләнә алган учреждениеләр челтәре булдырылган. Алар арасында 21 махсуслаштырылган балалар бакчасы, 481 мәктәпкәчә мәгариф оешмасында 826 махсус төркем эшләп килә. Шулай да булдырылган челтәр Татарстандагы гаиләләрнең ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә дип әйтеп булмый. 2016 елда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 676 балага мәктәпкәчә белем бирелмәде. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга яшәү урыны буенча балалар бакчасына юллама бирүдән баш тартуның төп сәбәбе

– дефектолог белгечләрнең булмавында. Бүген республика мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында дефектология буенча белеме булган 104 педагог һәм 882 логопед эшли.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән ***мәктәп яшендәге*** балаларның белемгә хокукын гамәлгә ашыру өлешенә караган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгълүматларына ясалган анализ сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 13 824 баладан 98,6% балага (2015 елда 93,5%) мәктәп белеме бирелүне күрсәтте. 2013 – 2017 елларга Балалар мәнфәгатьләрендә республика стратегиясен гамәлгә ашыруның индикатив күрсәткеченең 2016 елга чик күрсәткече 99% тәшкил итә.

Бүгенге көндә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгариф кырына түбәндәгеләр керә:

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 52 гомуми белем бирү учреждениесе, аларда ишетү, күрү сәләте, сөйләме, терәк-хәрәкәт аппараты һәм интеллекты бозылган 6 631 бала укый;

инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы 153 гомуми белем бирү оешмасы (яки гомуми мәктәпләр);

инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга башлангыч гомуми белем бирүнең ФДМС һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) белем алучыларга белем бирүнең ФДМС кертүне тәэмин итүче база гомуми белем бирү оешмалары булып торучы 153 гомуми белем бирү мәктәбе (яки гомуми мәктәпләр), аларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 189 бала укый;

12 муниципаль район һәм Казан шәһәре шәһәр округы (Аксубай, Әлмәт, Апас, Буа, Биектау, Түбән Кама, Нурлат, Балык Бистәсе, Сарман, Тәтеш, Теләче, Чирмешән һәм Казан шәһәре Идел буе районы) мәктәпләрендә гомуми белем бирү оешмалары базасында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән - ишетү, сәләте, сөйләме, акыл үсеше һәм психик үсеше бозылган балалар өчен 89 сыйныф, аларга 532 бала йөри;

озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы 2 учреждение, аларга 200 кеше йөри.

Уку барышында озатып йөрүче булган махсус шартларга мохтаҗ балалар өчен махсус (коррекцияле) белем бирүне тәэмин итүдә республиканың әлеге баскычта республиканың гамәлдәге коррекцияле белем системасын саклап кала алуы зур әһәмияткә ия. Бүгенге көндә эшли торган махсус (коррекция) учреждениеләр базасында инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы мәктәпләргә методик ярдәм күрсәтү өчен укыту-методика ресурс үзәкләре төзелә.

Шулай итеп, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалы гаиләгә баланың уку маршрутын сайлап алу мөмкинлеге бар: коррекцион юнәлешле мәгариф оешмасын (республикада алар 52), гадәти мәктәпне, ләкин коррекция юнәлешен алган программа буенча укытыла торган сыйныфны (республикада 89 шундый сыйныф бар), шулай ук үзлегеннән инклюзив белем алуны (республикада инклюзив белем бирүне 153 мәгариф оешмасы гамәлгә ашыра).

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәп яшендәге балаларга белем бирү колачы авыру төрләре буенча 118 нче диаграммада күрсәтелә.

118 нче диаграмма

Авыру төрләре буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (СМЧ) мәктәп яшендәге балаларга белем бирү колачы (2016 ел)




Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, быелгы уку елында психологик-медик-педагогик комиссиянең тиешле рекомендацияләре бирелгән 6 631 (48%) бала махсус (коррекция) мәгариф оешмаларында; 6 943 (50,2%) бала гомуми мәктәптә белем ала.

Моңа бәйле рәвештә шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы күрсәткечләрен күтәрү буенча чаралар планы («юл картасы») (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 28 сентябрендәге 716 номерлы карары белән расланган) нигезендә 2016 елда «Белем алучы инвалид балаларның, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гомуми санының гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирүнең җайлаштырылган программалары буенча белем алучы инвалид балалар, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өлеше» күрсәткеченең план исәбе 51,8% тәшкил итә. Чынбарлыктагы күрсәткеч пландагыдан 1,6% ка кимрәк.

119 нчы диаграмма

2013 – 2016 елларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (СМЧ) балаларның мәктәп белеме белән тәэмин ителүе



2012 елдан башлап республикада ел саен гомуми белем бирү оешмаларында уңайлы мохит тудыру буенча чаралар күрелә. «Уңайлы мохит» программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә узган чорда 309 гомуми белем бирү оешмасы инвалидларның һәм үсешләрендә тайпылышлар булмаган затларның бергә укуын тәэмин итү өчен җайлаштырылды, алар мәктәпләрнең гомуми санының 21,8% тәшкил итә (2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы күрсәткечләрен күтәрү буенча чаралар планының («юл картасы»ның) 2016 елда индикатив күрсәткеченең чик зурлыгы 24% тәшкил итә).

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, быелгы уку елында инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы 309 мәктәптә (2015 елда – 299) сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 1 967 бала белем ала.

28 нче таблица

Инклюзив белем бирү турында мәгълүмат

Күрсәткеч исеме	***2011 ел***	***2012 ел***	***2013 ел***	***2014 ел***	***2015 ел***	***2016 ел***
Инклюзив белем бирү өчен каршылыклар булмаган мохит тудырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны	4	35	56	154	299	309
Аларда белем алучы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар саны	51	449	718	928	1 516	1 967


Каршылыклар булмаган мохит өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән гомуми белем бирү оешмаларының саны шактый артса да, өйдә белем алучы балаларның санының арта гына баруы игътибарны җәлеп итә. Чыннан да, соңгы дүрт елда өйдә индивидуаль белем алучы

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны белем алуның барып уку рәвешенә күчерү тенденциясе күзәтелми.

Инвалид балаларның күбесе, элеккечә, индивидуаль программалар буенча өйдә укуларын дәвам итәләр. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 елда мәктәп белеме бирелә торган сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 13 824 баладан 2 225 кеше (16,1%) мәктәп коллективыннан читтә укытыла. 2015 елда бу күрсәткеч 14,5% иде.

120 нче диаграмма


2011 – 2016 елларда өйдә укый торган СМЧ балалар саны



Өйдә белем алучы балаларның саны ел саен артып торганда, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның дистанцион уку рәвеше буенча да белем алуга хокукының үтәлүе буенча хәлнең торышы борчый. Һичшиксез, өйдә укытуның мондый рәвеше балаларның белем алу процессына кереп китүенә ярдәм итә, ягъни алар өчен инклюзив белем бирүне оештыру идеясенә туры килә. Моның белән бергә соңгы җиде елда өйдә дистанцион уку технологияләрен кулланып укучы балаларның җиде тапкырга кимүе күзәтелә. Мондый хәлнең сәбәбе әлеге уку рәвешенә мохтаҗ балаларның саны кимүдә дә, ерактан торып укуның техник чаралар белән җитәрлек тәэмин ителмәве дә була алганга күрә, әлеге мәсьәлә тирәнтен өйрәнүне, тиешле чаралар уйлап табуны һәм гамәлгә ашыруны таләп итә.

121 нче диаграмма

2011 – 2016 елларда дистанцион укучы балалар саны



Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, республикада инклюзив белем бирү буенча күрелгән чараларга карамастан, шул исәптән инвалид балалар өчен гомуми мәктәпләр ачылып торса да, барлык төр махсус (коррекция) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны кимеми, киресенчә, арта бара (2013 елда – 5 929 кеше, 2014 елда – 6 016 кеше, 2015 елда – 6 297 кеше, 2016 елда – 6 631 кеше). Аерым алганда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, махсус (коррекция) мәктәпләрдә укучылар саны түбәндәгечә артты:

ишетү сәләте бозылганнар – 373 (2013 елда) булып, 403 (2016 елда);

күрү сәләте бозылганнар – 520 (2013 елда) булып, 576 (2016 елда);

сөйләме бозылганнар – 139 (2013 елда) булып, 199 (2016 елда);

таяну-хәрәкәтләнү аппараты бозылганнар – 383 (2013 елда) булып, 412 (2016 елда);


акылына зәгыйфьләр – 4514 (2013 елда) булып, 5 041 (2016 елда).

Бу хәл бер яктан, коррекцияле белем бирелүгә мохтаҗ һәм махсус шартлар үтәлүне таләп иткән ата-аналарның, элеккечә, балаларының традицион коррекцион белем алуны хуплауларын расласа, икенче яктан, балаларның яшәү урыны буенча мәктәпләрдә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирү буенча күрелә торган чараларның җитәрлек булмавын аңлата.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәп яшендәге балаларга белем бирү колачы авыру төрләре буенча 112 нче диаграммада күрсәтелә.

122 нче диаграмма

2016 елда авыру төрләре буенча сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән мәктәп яшендәге балаларны укыту колачы



Статистика белешмәләреннән күренгәнчә, яшәү урыны буенча гомуми мәктәпләрдә белем бирү буенча коррекция юнәлешендәге хезмәт күрсәтүләрдән нигездә акылга зәгыйфь балалар файдалана алмый. Моның белән бергә, үсешләрендә мондый үзенчәлекләр булган балаларга белем

бирүне оештыру иң чыгымсыз һәм катлаулы булмаган эш. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә балаларын республиканың ераkта урнашкан коррекция интернат мәктәпләренә җибәрергә теләмәгән ата-аналардан мөрәҗәгатьләр даими алына. Вәкаләтле вәкил барлык очракларда да «үзенчәлекле» баланың белем алуын, аның мәнфәгатьләренә туры килә торган иң уңай юл буларак, яшәү урыны буенча оештыру мөмкинлеген табу үтенече белән муниципаль район башлыкларына мөрәҗәгать итте.

Аутистика спектры бозылган (алга таба – АСБ) *балаларга* белем бирү белән бәйле булган хәл Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарына алынды. Җирле үзидарә органнарыннан алынган оператив мәгълүматларга караганда, 2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче 280 баланың АСБ дип табылган, шул исәптән:

3 яшькә кадәр – 1 бала,

3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр – 147 кеше; шулардан 122 бала (83%) балалар бакчасына йөри; 25 бала йөрми:

Азнакай, Әлмәт, Арча, Баулы, Мамадыш, Лаеш муниципаль районнарында берәр бала;

Балтач, Кукмара, Лениногорск, Чистай муниципаль районнарында икешәр бала;

Биектау муниципаль районында өч бала;

Түбән Кама муниципаль районында, Чаллы шәһәрендә дүртәр бала;

7 яшьтән алып 18 яшькә кадәр – 132 кеше, шулардан 118 кеше (89,4%) мәктәпкә йөри, 14 кеше йөрми:

Алексеевск, Югары ослан, Кукмара, Лениногорск, Яңа Чишмә муниципаль районнарында берәр бала;

Әлмәт, Тукай, Яңа Чишмә муниципаль районнарында икешәр бала;

Баулы муниципаль районында өч бала.

Моның белән бергә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2017 елның 1 мартына биргән мәгълүматларына караганда, республикада аутистика спектры бозылган 415 бала яши. Мондый хәлнең булуы мәгарифкә идарәнең муниципаль органнары эшчәнлегенең тиешле дәрәҗәдә оештырылмавын күрсәтә, гәрчә алар мондый балаларны белем бирү белән тәэмин итү буенча эшне оештыру өчен сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре һәртөрле чикләнгән балаларның саны турындагы дөрес һәм тулы мәгълүматка ия булырга тиеш булсалар да. Моңа өстәп, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил соратуы буенча муниципаль районнар башлыклары тапшырган мәгълүмат-аналитика материаллары күпчелек муниципалитетларның мәгарифкә идарә органнарында районда (шәһәрдә) сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре төрлечә чикләнгән балаларның исәбе турындагы дөрес мәгълүматлар бөтенләй булмауны күрсәтте. Мондый шартларда әлеге категориядәге балаларны

контрольдә тоту һәм балаларның үсеш үзенчәлекләренә туры килә торган белем белән тәэмин итү буенча эшнең алар тарафыннан тиешле дәрәҗәдә оештырылуы һәм башкарылуы турында бер сүз дә әйтеп булмый. Моннан тыш, муниципалитетларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның исәбе, яшьләре, белемгә ихтыяҗлары турында хак мәгълүматның булмавы республика районнарында һәм шәһәрләрендә әлеге балаларга белем бирүне оештыруга системалы якын килүнең гамәлгә ашырылуын зур шик астына куя. Мәгарифкә идарә органнары муниципалитеттагы сәламәтлек ягыннан мөмкинлеге чикләнгән һәр бала турында тулысынча хәбәрдар булырга һәм һәркайсына белем алу маршрутын ачык төзергә тиеш.

Моңа бәйле рәвештә, муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль мәгарифкә идарә органнары әлеге категориядәге балалар буенча дөрес мәгълүмат булу мәсьәләсен һәм, шуннан чыгып, әлеге балаларга белем бирү мәсьәләсен махсус контрольгә алырга **кирәк, дип саныйм**.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруда тагын бер проблема бар, ул – *аерым ихтыяҗлары булган балаларның һөнәри белем алуы*.

Шулай, 2016 елның мартында «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Питрәч интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен тикшергәндә һәм 9 нчы сыйныфта белем алучылар белән әңгәмә вакытында мәктәп укучылары 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң һөнәри белем алуны нинди һөнәри белем бирү оешмаларында дәвам итәргә уйлауларын аңлатып бирә алмадылар. Шундый ук хәл Актаныш муниципаль районында күзәтелде, анда 2016 елның августында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең шәхси кабул итүенә Актаныш районының «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Такталачык интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен тәмамлаучыларның ата-аналары килгән иде, алар балаларының нинди һөнәри белем бирү оешмасында һөнәри белгечлек алу мөмкинлеге булу турында хәбәрдар түгел иделәр. Мәсьәләне өйрәнү барышында муниципалитетлар тарафыннан интернат мәктәпләрне тәмамлаучыларның укуны һөнәри белем бирү оешмаларында дәвам итү мәсьәләсенең уйланып бетелмәве билгеләнде. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Актаныш технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесендә элек эшләгән махсуслаштырылган төркемнең 2016/2017 уку елында интернат мәктәпне тәмамлаучылар өчен оештырылмавына юл куюы һәм интернат мәктәпне тәмамлаучылар, аларның ата-аналары белән алга таба һөнәри белем алу маршрутын төзү буенча тиешле эшнең алып барылмавы ачыкланды.

Мондый хәлнең барлыкка килүе, үз вакытында чаралар күрелмәү актаныш муниципаль районының мәгариф системасында, әйтик, мәгариф бүлеге, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, районының «Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Такталачык интернат мәктәбе» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе һәм «Актаныш технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе арасында ведомствоара хезмәттәшлекнең булмавын күрсәтә. Коррекция мәктәбен тәмамлаучылар шул сәбәпле белем алуны дәвам итү һәм белгечлек алу хокукыннан мәхрүм ителгәннәр, моның, һичшиксез, аларның олылар тормышына социаль җайлашуына һәм үзүзләрен тәэмин итү мөмкинлекләренә тискәре йогынты ясавы ихтимал.

Моңа бәйле рәвештә гомуми белем бирү оешмаларының сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән чыгарылыш укучылары белән дә, аларның ата-аналары белән дә һөнәри юнәлеш бирү эшенең тиешле дәрәҗәдә оештырылмавын күрсәтергә кирәк, дип саныйм.

Кызганычка каршы, республикабызда хәзерге кадәр сәламәтлеге төрле яклап бозылган, ***укытып булмый торган*** дип танылганга күрә, берничек тә белем бирелми торган балалары булган гаиләләр бар. Шулай, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, быелгы уку елында мәктәп яшендәге 598 балага белем бирелмәгән, шулардан 491 бала сәламәтлек торышы буенча мәктәптә укый алмыйлар, шул ук вакытта 250 бала пихологик-медик-педагогик комиссия тарафыннан укытып булмый торган балалар дип танылган.

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп, түбәндәгеләрне эшләргә кирәк дип саныйм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына

инклюзив белем бирү кысаларында сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларга башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) белем алучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән укучыларның һәм акылга зәгыйфь (интеллектлары бозылган) укучыларның белем алуын оештыруны тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын раслауны күз алдында тоткан «2017 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2016 елның 29 сентябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проек-

тын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына кертергә;

ел саен Татарстан Республикасы законы белән киләсе чорга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын расларга.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җирле үзидарә органнары белән берлектә:

өйдә белем алучы балаларның дистанцион укуларын үстерү буенча чаралар күрергә;

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның системалы белем алуларын һәм һәр баланың белем алу маршрутын төзү максатыннан барысының да исәбен алып баруны тәэмин итәргә;

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларында тәрбияләнүче сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән, һәр баланың белем алу траекториясен билгеләү һәм 9 – 10 сыйныфлар чыгарылыш укучыларының, иң элек, нинди белгечлекләргә ихтыяҗ булудан чыгып, һөнәри белем алу программаларын булдыру максатыннан, һөнәр сайлау эшен нәтиҗәле башкаруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында инвалид балаларның һөнәри белем алу мөмкинлекләре булу турында халыкка киң мәгълүмат бирү буенча өстәмә чаралар комплексын күрергә.

3.5. Социаль тәэмин ителешкә хокукны гамәлгә ашыру

Берләшкән милләтләр оешмасының Бала хокуклары Конвенциясендәге 27 статьясы нигезендә, бу норма ратификацияләнгән дәүләтләрдә һәр баланың социаль тәэмин ителешкә, моңа социаль иминләштерү дә керә, хокукы таныла һәм бу хокукны тәэмин итү өчен илкүләм законнарда каралган тәртиптә тиешле чаралар күрелә.

Бу хокукны тиешенчә гамәлгә ашыру сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен аеруча мөһим.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү торышы үзенә аерым игътибар таләп итә.

Тернәкләндерүнең техник чаралары һәм инвалидны карау чаралары белән тәэмин итү тәртибе Федераль закон нигезендә башкарыла. «Рос-

сия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 10 статьясы нигезендә дәүләт инвалид балаларга федераль бюджет акчаларын исәбеннән үткәрелә торган тернәкләндерү чаралары, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм хезмәтләр күрсәтү буенча федераль исемлеккә кертелгән тернәкләндерү чаралары үткәрүне, техник чаралар белән тәэмин итүне һәм хезмәтләр күрсәтүне гарантияли. Бу хокукны гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 7 апрелендәге 240 номерлы карары белән расланган Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән һәм ветераннар арасыннан булган гражданнарның аерым категорияләрен протезлар (теш протезларыннан кала), протез-ортопедия әйберләре белән тәэмин итү кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр) белән җайга салына. Мондый чараларның составы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 30 декабрендәге 2347-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Инвалидка бирелә торган тернәкләндерү чаралары, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләр исемлегендә (алга таба – Федераль исемлек) регламентлаштырылган.

Инвалидларны социаль яклау турында Федераль законның 11 статьясында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү тернәкләндерүнең индивидуаль программалары (алга таба – ИПР) нигезендә башкарыла дип билгеләнгән. Әлеге программалар федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре (алга таба – МСЭ) тарафыннан эшләнә һәм тиешле дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге оешмалар тарафыннан үтәлергә тиеш.

2016 елның 1 гыйнварыннан инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү (протез-ортопедия әйберләрен ясау һәм ремонтлауны да кертеп), шифаханә-курорт оешмаларында дәваланууга юллама бирү һәм шәһәрара транспортта бару-кайту буенча социаль хезмәтләр рәвешендә дәүләт социаль хезмәтләре күрсәтү яңадан Россия Федерациясе социаль иминләштерү фондының региональ бүлекчәсенә (алга таба – Татарстан Республикасы буенча Социаль иминләштерү фонды) тапшырылды.

2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары, шул исәптән протез-ортопедия әйберләре һәм инвалидны карау әйберләре белән тәэмин итүнең тиешенчә булмавы турында 25 мөрәҗәгать керде. Аларны карау барышында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге хокук бозуларны ачыклады:

инвалид балаларны индивидуаль тернәкләндерү программасында каралган кирәкле техник чаралар белән тәэмин итмәү;

инвалид балаларны техник чаралар белән үз вакытында тәэмин итмәү;

инвалид балаларны индивидуаль тернәкләндерү программасында каралган кирәкле техник чараларга туры килми торган яраксыз техник чаралар белән тәэмин итү;

тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итүче фирмаларның – аларның ясаучыларның техник чараларны тапшыру вакытында сыйфатын, шул исәптән төзек булмауга, индивидуаль тернәкләндерү программасына һәм техник заданиегә туры килүен тикшереп караудан баш тартуы.

Килеп туган сорауларны һәрбер бала мисалында (ата-аналары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән балалар) аерым һәм тулысынча хәл итү максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдиме белән Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды белән берлектә ел әйләнәсендә уртак утырышлар үткәрелде. Ләкин бу чаралар теләгән нәтиҗәләргә китермәде. Бары тик ике мөрәҗәгать итүченең проблемасы гына балалар мәнфәгатьләрендә һәм алар файдасына хәл ителде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрнең һәрбер шикаятендә инвалид балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу бәян ителүен истә тотып, балигъ булмаганнарның тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин ителеше өлкәсендә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуы турында Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды идарәчесе исеменә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмәләр җибәрелде, аларда

балигъ булмаганнарның индивидуаль тернәкләндерү программаларында каралган рекомендацияләргә туры килә торган техник тернәкләндерү чараларын һәм инвалидны карау чараларын тулы күләмдә алу хокукын гамәлгә ашыруны оештыруга юнәлдерелгән чаралар күрү;

инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары һәм инвалидны карау чаралары белән тәэмин итүнең билгеләнгән тәртибен алга таба бозуларны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар күрү;

техник чаралар белән тәэмин итүчеләр тарафыннан техник тернәкләндерү чараларын кайтаруга дәүләт контракты таләпләрен бозуларны булдырмауга юнәлдерелгән чаралар күрү, аеруча кайтарылган товарның техник заданиегә һәм балигъ булмаганның индивидуаль тернәкләндерү программасына туры килүе өлешендә.

Башкарылган эшләрнең нәтиҗәсе буларак, тагын 10 мөрәҗәгать итүченең проблемасы тулысынча хәл ителде.

Балаларның хокукларын бозу вәзгыятенә йогынты ясау чараларын арттыру максатларында, 2016 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаганнарның кирәкле техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителүгә хокуклары бозылу фактлары турында Татарстан Республикасы Прокурорына мөрәҗәгать итте һәм балигъ булмаганнар турындагы законнар үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында прокурор тикшерүе үткәрергә тәкъдим итте.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары, аерым алганда кресло-коляскалар белән тәэмин итүдәге тагын бер проблема бу чараларның сыйфатына бәйле. Инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итү йөкләмәләрен үтәү йөзеннән бирелә торган кресло-коляскалар, кагыйдә буларак, типовой, «инвалид бала» категориясе өчен һәм буй, үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып ясалган. Моннан тыш, бирелә торган колясkаларның еш кына искергән һәм таушалган булуы, авыруларга каршы көрәштә һәм организмның үз функцияләрен торгызуда ирешелгән заманча тернәкләндерү таләпләренә һәм казанышларына җавап бирмәве ачыкланды. Ләкин инвалид баланың индивидуаль тернәкләндерү программасында кирәкле кресло-колясканың параметрлары буенча тиешле рекомендацияләр булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фондының инвалид балага индивидуаль параметрларга яраклаштырылган кресло-коляска бирү буенча хокукый нигезләре юк.

«Инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү өчен күрсәтмәләр һәм каршылыклар исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының 2014 елның 9 декабрендәге 998н номерлы боерыгы инвалид баланың хәлен җиңеләйтү яисә проблемасын тулысынча хәл итү (карала торган өлештә) мөмкинлеген бирә, әлеге боерык нигезендә, индивидуаль тернәкләндерү программасына кресло-коляскага ихтыяҗ булуын теркәгәндә медик-социаль экспертиза белгечләре характеристиканы төгәлрәк язарга тиеш: кресло-коляска аркасының төре (алып куела торган, биеклеккә һәм горизонталь җайга салып була торган, авышлыгын көйли торган, төшереп куела торган), утыргычының төре (алып куела торган, биеклеккә һәм горизонталь җайга салып була торган, авышлыгын көйли торган, коксит белән авыру бала өчен, җыелып куела торган, пружиналы), терсәк кую урынының төре (бер урынга ныгытылган, төшерә торган, әйләнә торган, алып куеп була торган, биеклеге җайга салына торган), аяк кую җайланмасы (алып куела торган, әйләнә торган, биеклеге җайга салына торган, авышлыгы җайга салына торган, аяк өчен җайга салына торган терәге булган, аяк өчен җайга салына торган терәге алып куела торган), җайланмалары (креслоның аркасын зурайткыч, баш кую урыны, баш кую өчен ян-якта терәкләре,

гәүдә өчен ян-якта терәкләре, утыргычында мендәр, аркасында мендәр, билгә валик, аяк арасында бушлык калдыру өчен валик, чәлтерләрне кую өчен махсус урын, чәлтерләрне кую өчен киңлеге җайга салына торган махсус урын, аяклар өчен тоткычлар, арттан тоткычлар, саклагыч билбау, көйләнгән өстәл); утыргычның киңлеге, тирәнлеге, биеклеге, аркасының биеклеге, терсәк кую урынының биеклеге һәм билгеләнеше (балалар өчен, өлкәннәр өчен); идарә итү төре (тәгәрмәчләр кыршавы ярдәмендә кулдан, рычаглы, электроидарә, актив төр).

Әйтелгәннәрдән чыгып, шулай ук Инвалидны индивидуаль тернәкләндерү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибе нигезләмәләрен истә тотып, мөрәҗәгать итүчеләргә яңа индивидуаль тернәкләндерү программасын төзү зарурлыгы һәм яшәү урыны буенча медик-социаль экспертиза бюросында баланың шәхси ихтыяҗлары нигезендә кресло-колясканың параметрларын ачыклау буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан аңлатмалар бирелде.

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» федераль казна учреждениесе белешмәләре буенча, 2016 елда яңа индивидуаль тернәкләндерү программаларын төзү мәсьәләсе буенча инвалид балаларның законлы вәкилләреннән 642 мөрәҗәгать (2015 елда – 463) кергән, яңа индивидуаль тернәкләндерү программасы гариза бирелгән көнне ясала һәм тапшырыла, өстәмә тикшеренүләр үткәрелгән очракта 5 көн дәвамында әзерләнә. Узган хисап чорында бирелгән барлык гаризалар да канәгатьләндерелде.

Инвалид балаларны техник тернәкләндерү чаралары белән тиешенчә тәэмин итүнең төп проблемаларының берсе тапшырылган вәкаләтләрне тулысынча үтәмәүгә бәйле. Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды мәгълүматы буенча, инвалид балаларны техник тернәкләндерү чарасы белән тәэмин итү дәрәҗәсе 2016 елда 45,3 % тәшкил итте: техник тернәкләндерү чараларына мохтаҗ инвалид балаларның гомуми саны 6 028 кеше исәпләнүгә карамастан, бары тик 2 733 кеше генә үз хокукларын тормышка ашыра алды. 2015 ел белән чагыштырганда, хәл катлаулана төште (алдагы елда мондый тәэминат 72 % тәшкил иткән иде: техник тернәкләндерү чараларына мохтаҗ инвалид балаларның гомуми саны 7 559 кеше, үз хокукларын тормышка ашыра алучы – 5 449 кеше) һәм соңгы өч елда иң кечкенә күрсәткечләргә ия булды. Шулай итеп, әлеге вәзгыять инвалид балаларның яртысының диярлек 2016 елда техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителү хокукы бозылуын күрсәтә.

Шул ук вакытта, инвалид баланың законлы вәкилләренә мөстәкыйль рәвештә индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә техник

тернәкләндерү чаралары һәм протез-ортопедия әйберләре сатып алырга һәм чыгымнарны кире кайтару өчен гариза белән Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фондына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Мөстәкыйль сатып алынган техник тернәкләндерү чаралары өчен компенсация түләү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2011 елның 31 гыйнварындагы 57н номерлы боерыгы таләпләре нигезендә башкарыла. Компенсация күләме, алда телгә алынган боерык нигезләмәләренә таянып, техник тернәкләндерү чараларын сатып-алуларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә, бу хакта мәгълүмат http//:www.zakupki.gov.ru, шулай ук http://fss16.ru рәсми сайтында урнаштырыла.

Техник тернәкләндерү чараларын үзләре сатып алган өчен компенсация түләүләрен алырга хокуклы балалар саны (2017 елның 1 гыйнварына) 2 451 кешене тәшкил итә, шулай да компенсация бары тик 1 944 балага гына түләнгән, бу ихтыяҗның 80 %ы дигән сүз.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итүнең югарыда бәян ителгән торышы, әлбәттә, Россия Федерациясе чыгым йөкләмәләрен җитәрлек дәрәҗәдә финансламауга бәйле.

Инвалид балаларны тернәкләндерүнең тагын бер актуаль мәсьәләсе – аларны ***шифаханә-курортта дәвалануга юллама белән тәэмин итү***.

Инвалид балаларны шифаханә-курортта дәвалауны тәэмин итү «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләр җыелмасы кысаларында гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2004 елның 29 декабрендәге 328 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе белән җайга салына.

Шифаханә-курорт дәвалавы өчен юлламалар бирү буенча тапшырылган федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру 2016 елда Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды тарафыннан чыгым нормалары, дәүләт сатып-алулары турындагы законнар нигезендә, бу максатка бүлеп бирелгән акчалар кысаларында гамәлгә ашырылды. Финанслау социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасының бәясеннән чыгып гамәлгә ашырыла. 2016 елда шифаханә-курорт дәвалавы кертелгән социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасының бәясе аена 118,59 сум иде (2015 елда – аена 110,83 сум). Шул ук вакытта Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2015 елның 7 декабрендәге 1003н номерлы боерыгы нигезендә 2016 елда инвалид балаларның шифаханә-курорт учреждениеләрендә бер көн дәвалануы 1 109,4 сум (2015 елда – 1 028,9 сум) күләмендә билгеләнде. Юлламаның реаль бәясе күпкә артыграк.

Мондый вәзгыять инвалид балаларны шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тулысынча финансларга мөмкинлек бирми.

Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды белешмәләре буенча, 2016 елның башына шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ инвалид балаларның гомуми саны 3 843 кеше булса, бу юнәлештәге хокукларын гамәлгә ашырган балалар 1 534 кешене генә тәшкил итте. 2016 елның ахырына шифаханә-курорт дәвалавы алмаган инвалид балаларның саны 3 616 кеше булды. Шулай да бу саннар 2015 елга караганда 474 кешегә (12 %ка кимрәк) кимеде.

29 нчы таблица

2013 – 2015 елларда инвалид балаларның шифаханә-курортта дәвалану белән тәэмин ителеше

Инвалид балаларның шифаханә-курортта дәвалану белән тәэмин ителеше	**2013 ел**	**2014 ел**	**2015 ел**	**2016 ел**
Шифаханә-курортта дәвалануга мохтаҗ инвалид балалар саны (ел башына)	2495	3112	2187	3843
Шифаханә-курортта дәвалануга бирелгән юлламалар саны,	1190	1558	2002	1534
шул исәптән озата баручы затлар өчен	595	779	1001	766
Шифаханә-курортта дәвалануга юллама бирелмәгән балалар саны (ел ахырына ихтыяҗ	897	2106	4090	3616

Шулай итеп, инвалид балаларны шифаханә-курорт оешмаларына юлламалар белән ел саен тәэмин итү проблемасы кискен булып кала.

Шулай ук шифаханә-курорт шартларында сыйфатлы дәвалану проблемасы да актуальлеген югалтмый. Кызганычка каршы, финанслау җитәрлек дәрәҗәдә булмауга бәйле рәвештә «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон нигезләмәләренә таянып үткәрелә торган конкурс процедураларында иң аз бәя принцибы нигез итеп алына һәм илнең әйдәп баручы шифаханә-курорт учреждениеләренә юлламалар белән тәэмин итү мөмкинлеген бирми.

3.6. Баланың торак һәм башка мөлкәт хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү

Россия Федерациясе Бала хокуклары турында БМО конвенциясен ратификацияләп, баланың физик, акыл ягыннан, рухи, әхлакый һәм социаль үсеше өчен кирәкле тормыш дәрәҗәсенә хокукын һәм үз

мөмкинлекләре чикләрендә ата-аналарга һәм бала тәрбияләүче башка затларга балаларның лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокукын гамәлгә ашыруда кирәкле чараларның зарурлыгын таныды.

3.6.1. Ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның торак хокукларын тәэмин итү

Ярдәмгә аеручы мохтаҗ балалар категорияләре – ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруны тиешенчә тәэмин итү аеруча кайгыртылуга мохтаҗ балалар өчен тигез мөмкинлекләр булдыру өлкәсендә мөһим дәүләт бурычы булып тора.

Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нормалары нигезендә торакка мохтаҗ дип танылган ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны һәм ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны (алга таба – ятим балалар) Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан уңайлы торак урыннарны махсуслаштырылган торак урыннарга наем шартнамәләре буенча бирү рәвешендә бер мәртәбә дәүләт ярдәме күрсәтелә.

2016 елда әлеге чыгым вәкаләтен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырылды.

30 нчы таблица

2008 – 2016 елларга ятим балаларны Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән наем шартнамәләре буенча тәэмин итү

Ел	**ТР бюджеты акчалары күләме** (мең сумнарда)	**РФ бюджеты акчалары күләме** (мең сумнарда)	**Акчаларның гомуми күләме** (мең сумнарда)	**Торак урыны алган ятим балалар саны** (кеше)
2008	89 000,0	11 563,3	100 563,3	112
2009	50 000,0	11 170,1	61 170,1	70

2010	50 000,0	10 697,9	60 697,9	72
2011	106 600,0	51 795,2	158 395,2	182
2012	112 996,0	50 529,3	163 525,3	179
2013	173 942,2	72 086,4	246 028,6	265
2014	233 730,0	83 410,0	317 140,0	309
2015	269 811,0	86 610,4	356 421,4	331
2016	288 697,8	50 485,0	339 182,8	311
Барлыгы	**1 374 777,0**	**428 344,6**	**1 803 124,6**	**1 831**

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2011 елдан башлап ятим балаларны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны финанслауның Татарстан Республикасы бюджетына акчалары өлешендәге күләме ел саен арта бара.


Кызганычка каршы, ятим балаларга торак төзүне федераль финанслау күләме елдан-ел арта барып, 2016 елда, 2015 ел белән чагыштырганда, 36 125,4 мең сумга яки 41,7% ка кимеде.

Шулай, 2016 елда ятим балалар өчен торак төзүгә бүлеп бирелгән финанслар күләме 339 182,8 мең сум тәшкил итте, шуның 288 697,8 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, 50 485,0 мең сумы – федераль бюджет акчалары исәбеннән булды. Күрсәтелгән акчалар чикләрендә 2016 елда 331 бала торак белән тәэмин ителде, шуларның 18 яшьтән 23 яшькә кадәргеләре – 183 кеше һәм 23 яшьтән өлкәнрәкләр – 128 кеше.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, 2016 елга махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары алучы ятим балалар реестрына 1400 кеше кертелгән, шулардан бары тик 311 кеше генә үзләренең торак хокукларын тормышка ашырган. Шулай итеп, узган елда реестрда торучы, ягъни 2016 елда махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителү хокукына ия барлык затларның бары тик 22,2% ы гына үз хокукларын гамәлгә ашыра алганнар. Бу хәл шуны дәлилли, ел саен ятим балалар өчен торак төзелешен региональ финанслауны арттыру буенча чаралар күрелсә дә, ятим балаларның закон белән гарантияләнгән торак белән тәэмин ителүгә хокукын финанслау дәрәҗәсе, элеккечә, җитәрлек түгел. Торак тәэминаты буенча бурычларның ел саен арта баруы ятим балаларның торак көтү чорын озайта бара. Шулай итеп, 2016 ел йомгаклары буенча, ул 5 ел тәшкил итте. Өстәвенә, торак бирү буенча исәптә торучы ятим балаларның гомуми саны шулай ук ел саен арта бара: 2016 ел башына аларның саны 2 564 кеше булса, ел ахырына 3 012 кеше булды.

123 нче диаграмма

2016 ел ахырына торак урыны алу өчен исәптә торучы ятим балаларның яшьләре буенча гомуми саны



Быел Татарстан Республикасында ятим балаларны торак белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчаларның гомуми күләме 346,7 млн. сум тәшкил итте, бу сумма торак алуга хокуклары 2017 елда гамәлгә ашырылырга тиешле 1 243 ятим баладан бары тик 305 баланы гына торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә, ягъни 24,5% ятим бала торак белән тәмин ителәчәк.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, **Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә республиканың ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк, дип уйлыйбыз.**

Ятим балаларның вакытлыча яшәвен тәэмин итү мәсьәләсе актуаль булып кала. Шулай, 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, махсуслаштырылган торак фондында ятим балалар өчен буш торак урыннар булмаса, вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә ятим балаларның уңай торак урыннарда вакытлыча яшәвен тәэмин итә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2013 – 2015 елларда ясаган докладларында әлеге мәсьәләдә ачык хокукый регламентация зарурлыгы турында берничә тапкыр әйтеп узган иде. 2016 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 20 сентябрендәге 475 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 апрелендәге 239 номерлы карары чыкты. Анда, махсуслаштырылган торак фондында ятим балалар өчен буш торак урыннар булмаган очракта, аларга вакытлыча яшәп тору өчен ятим балаларның уку чорына дәүләт мәгариф оешмалары тулай торакларында йә дәүләт оешмалары тулай торакларында

яки маневр фонды торак урыннарында яшәр өчен уңайлыклары булган торак урыннар бирелә, дип каралган.

Моның белән бергә әлегә маневр торак фонды, барлык мәгариф оешмаларының да тулай тораклары булмаганга күрә, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны вакытлыча торак белән тәмин итү мәсьәләсе ачык кала. Мондый шартларда әлеге категориягә караган балалар өчен вакытлыча торак буларак республиканың халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплексы үзәкләре, балаларны гаиләгә урнаштыруда ярдәм күрсәтү үзәкләре һәм балалар йортлары каршындагы социаль кунакханәләрдән файдаланып булыр иде.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруның 2016 елдагы иң актуаль проблемасы ***аларның яшәү урыны буенча торак алуы*** булды. Гомуми кагыйдә буенча, 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы таләпләре нигезендә ятим балалар торак белән яшәү урыннары буенча тәэмин ителергә тиеш. Ятим балаларга торак урыны бирелгән вакытта махсуслаштырылган торак фондыннан тиешле торак урыны чикләрендә яшәү урыны буенча торак урыны булмаган очракта, күрсәтелгән затларга аларның теләге буенча Татарстан Республикасы чикләрендә башка торак пунктта махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны бирелә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 2016 елда республиканың Чаллы һәм Әлмәт кебек эре шәһәрләрендә ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан бер торак урын да бирелмәгән.

Ятим балалар арасыннан булган затларның тораккa хокукларын яшәү урыны буенча гына түгел, ә эшләү урыны буенча да гамәлгә ашыра алу 2016 елның яңалыгы булды. Шулай, тораклы үзе теләгән шәһәрдә яки районда алу өчен ятим балаларга үзләре сайлаган торак пунктта рәсми рәвештә эшкә урнашуын расларга кирәк иде.

2016 елда ятим балаларга, фатирлардан тыш, республиканың Актаныш, Әлки, Балтач һәм Зәй муниципаль районнарында 8 индивидуаль торак йорт бирелде.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматларыннан күренгәнчә, 2016 елда Аксубай, Алексеевск, Әлмәт, Баулы, Буа, Чүпрәле, Кама Тамагы, Мөслим, Яңа Чишмә, Спас, Тукай, Чирмешән муниципаль районнарында, шулай ук Чаллы шәһәрендә ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен махсуслаштырылган торак фондыннан торак бирелмәгән.

Моңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак белән тәэмин итү буенча алар белән эшләү буенча вәкаләтле органы буларак Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Җир

һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә ятим балалар арасыннан булган затларныяшәү һәм эшләү урыны буенча торак белән тәэмин итү тәҗрибәсен ятим балаларның мәнфәгатьләрен дә, дәүләт мәнфәгатьләрен дә канәгатьләндерә торган тәҗрибә буларак дәвам итү буенча чаралар күрергә кирәк, дип уйлыйбыз.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруның проблемалы мәсьәләләргә ***23 яшькә җиткән ятим балалар арасыннан булган затларны,*** ягъни «өлкәнрәк» затларны ***торак белән тәэмин итүне*** гамәлгә ашыруны кертергә кирәк.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны 23 яше тулганнан соң торак урын белән тәэмин ителүчеләр исемлегенә кертүдән баш тарту турында карарлар кабул итү гадәткә керде. 2013 елның 1 гыйнварыннан ятим балалар арасыннан «өлкәнрәк» затлар үзләренә торак урын бирүне сорап судка дәгъва белдереп мөрәҗәгать итәләр. Татарстан Республикасында әлеге категориядәге гражданнарны яклап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертүдән баш тарту турындагы карарны законсыз дип тану турында һәм гражданнарны күрсәтелгән исемлеккә кертүне йөкләү хакында гариза белән район прокурорлары да мөрәҗәгать итәләр. Судлар мондый дәгъваларны канәгатьләндерәләр. 2013 елның 1 гыйнварыннан бирле килгән суд практикасында судлар Россия Федерациясе Конституция судының 2009 елның 5 мартындагы № 376-О-П билгеләмәсендә күрсәтелгән хокукый позициягә таяналар, аның нигезендә ятим балаларның тораккa объектив ихтыяҗы әһәмияткә ия. Шуңа бәйле рәвештә мондый затларны әлеге исемлеккә кертү процедурасын билгеләү өлешендә республика законнарына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау максатка ярашлы булыр иде.

2016 ел йомгаклары буенча республика судлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын ятим балалар арасыннан булган затларны торак алу исемлегенә кертүне йөкләү турында дәгъвалар буенча 23 карар кабул ителде, 15 гражданга мондый дәгъваны канәгатьләндерүдә баш тартылды. Моннан тыш, ятим балалар арасыннан булган 6 затка торак урын суд карарлары буенча бирелде.

Ятим балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруда ятим балаларга файдалану яисә милек хокукында карый торган торак урыннарда ***торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен бурычның*** түләнмәве актуаль мәсьәлә булып кала. Әлеге мәсьәләне карау һәм өйрәнү барышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советында төзелгән эшче төркем (аңа Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дә керде) ятим балалар андыйлар өчен учреждениеләрдә, төзәтү учреждениеләрендә, опекун-

нар (попечительләр) гаиләләрендә, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә булган чорда ятим балалар милкендәге торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен яллаучылар яисә яллаучыларның гаилә әгъзаларының социаль наем шартнамәләре буенча түләмәүләренә бәйле күпсанлы проблемалар барлыгын ачыклады.

Торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча бурычларның ятим бала беркетелгән торак урында бер кем дә яшәмәгән очракта, шулай ук мондый торак урыннарда яшәүчеләр (мәсәлән, ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән затлар, ятим баланың күп очракта әхлаксыз тормыш рәвешен алып баручы гаилә әгъзалары) түләү буенча бурычларын үтәмәгән очракта җыелып баруы ачыкланды.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасында ятим балаларның бурыч күләмнәрен исәпләүнең төгәл механизмнары эшләнде һәм торак-коммуналь хезмәтләргә ятим балалар бурычларының кимүе буенча ай саен мониторинг оештырылды. Ятим балаларның торак-коммуналь хезмәтләргә торак урыны өчен бурычының Татарстан Республикасы буенча гомуми суммасы 2016 елның 1 гыйнварына 39 255 639 сум тәшкил итсә, 2017 елның 1 гыйнварына 20 798 832,67 сум калды.

3.6.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын тәэмин итү

Балаларның һәрьяклап үсүе һәм тәрбияләнүе өчен кирәкле уңай мохит тудыруда дәүләт ярдәменә аеруча мохтаҗ гаиләләр арасында күпбалалы гаиләләр дә бар.

Шушы максатта Татарстан Республикасы Президентының «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы нигезендә ата-анасы белән торучы, үз гаиләсен кормаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү аларга торак урын сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү юлы белән башкарыла. Торак урын сатып алу өчен субсидияләр алу хокукы сертификат белән таныклана, сертификатлар бирү һәм алардан файдалану Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү һәм алардан файдалану тәртибендә билгеләнгән.

2016 елда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 137 068,2 мең сум акча каралган иде. Бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә узган елда 42 сертификат бирелде.

31 нче таблица


2013–2016 елларда биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак сертификаты хисабына торак белән тәэмин итү

Ел	Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбендә торучы гаиләләрнең гомуми саны	ТР бюджеты акчалары күләме (мең сумнарда)	Торак сертификатларын алуга җыелма исемлектәге гаиләләр саны	Балаларның үз гаиләләре булу сәбәпле сертификат алу хокукын югалткан гаиләләр саны	Сертификат алган гаиләләр саны
2013	4626	116 191, 4	822	8	44
2014	4675	122 001,0	824	2	37
2015	4219	128 101, 0	801	3	45
2016	3921	137068,2	793	3	42

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 елда 3 921 күпбалалы гаилә торак шартларын яхшырту буенча исәптә торды, шулардан биш һәм аннан да күбрәк баласы булган 793 күпбалалы гаилә Торак сертификатларын алуга җыелма исемлектә торды.

124 нче диаграмма

2013 – 2015 елларда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр саны



«2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне

торак белән тәэмин итүгә 2017 елда 143 784,5 мең сум акча каралган, 2018 һәм 2019 елларга тиешенчә 150 254,8 мең сум һәм 156 265,0 мең сум планлаштырылган.

Югарыда китерелгән күрсәткечләргә ясалган анализ, бүлеп бирелгән финанслау күләменең торак сертификатлары белән бер елга Җыелма исемлектә торучы күп дигәндә 5,3 % гаиләне тәэмин итәргә мөмкинлек бирүен күрсәтте, әлеге күрсәткеч 2015 ел белән чагыштырганда (5,7%) 7% ка түбәнрәк. Мондый шартларда торак сертификаты алуны көтүнең уртача чоры 9 – 10 ел тәшкил итәчәк.

Һичшиксез, мондый озак вакыт эчендә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр исемлектәге статусын һәм, шуңа бәйле рәвештә, торак сертификаты алу хокукын да югалталар. 2016 елда 3 гаилә, балалары үз гаиләләрен кору сәбәпле, торак сертификатын алу хокукын югалтты. Мондый вәзгыять әлеге дәүләт яклавы чарасының хокукый мәгънәсен киметә.

Күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең, шул исәптән торак шартларын яхшырту өчен каралган дәүләт ярдәменең тагын бер чарасы – түләүсез җир кишәрлекләре бирү. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32, 32.1 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, милеккә җир кишәрлеге бирү (тапшыру) турында гариза бирү датасына унсигез яшькә җитмәгән өч һәм аннан күбрәк баласы, шул исәптән үги балалар, уллыкка (кызлыкка) алынган, опекадагы балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен 0,06га дан 0,20га.га кадәр, торглар уздырмыйча һәм объектларның урнашкан урынын алдан килештермичә, бер мәртәбә түләүсез бирелә. Күрсәтелгән җир кишәрлекләре гражданнарга һәм балаларга, тигез өлешләргә бүленеп, гомуми өлешле милек буларак бирелә (тапшырыла).

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2016 ел ахырына җир кишәрлекләрен түләүсез алучылар исемлегенә кертү турында 39 238 карар кабул ителде. Гомуми өлешле милеккә бирелгән 27 067 җир кишәрлеге, тулаем алганда, республикада исемлекләргә кертү турында кабул ителгән карарлар саныннан 69% тәшкил итә.

32 нче таблица

2016 елда күпбалалы гаиләләрнең түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукын гамәлгә ашыру (Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча)

Т/б	Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме	Җир кишәрлекләре алу өчен исәптә торучы күпбалалы гаиләләр саны	Җир кишәрлеге алу хокукы гамәлгә ашырылган күпбалалы гаиләләр саны	Җир кишәрлеге алу хокукы гамәлгә ашырылмаган күпбалалы гаиләләр саны
1	Казан ш.	9083	2907	6176
2	Чаллы ш.	5136	2596	2540
3	Әгерҗе	419	395	24
4	Азнакай	691	679	12
5	Аксубай	252	243	9
6	Актаныш	343	336	7
7	Алексеевск	363	362	1
8	Әлки	147	130	17
9	Әлмәт	2498	1580	918
10	Апас	197	190	7
11	Арча	1026	875	151
12	Әтнә	157	143	14
13	Баулы	292	278	14
14	Балтач	514	491	23
15	Бөгелмә	799	489	310
16	Буа	493	447	46
17	Югары Ослан	267	253	14
18	Биектау	471	454	17
19	Чүпрәле	263	255	8
20	Алабуга	984	976	8
21	Зәй	617	595	22
22	Зеленодольск	1547	1157	390
23	Кайбыч	233	233	0
24	Кама-Тамагы	175	160	15
25	Кукмара	1070	917	153
26	Лаеш	575	540	35
27	Лениногорск	704	582	122
28	Мамадыш	605	601	4
29	Менделеевск	295	293	2
30	Минзәлә	545	520	25

31	Мөслим	379	273	106
32	Түбән Кама	2348	1636	712
33	Яңа Чишмә	204	204	0
34	Нурлат	730	673	57
35	Питрәч	501	451	50
36	Балык Бистәсе	281	280	1
37	Саба	671	640	31
38	Сарман	648	647	1
39	Спас	271	271	0
40	Тәтеш	222	220	2
41	Тукай	649	648	1
42	Теләче	257	256	1
43	Чирмешән	115	115	0
44	Чистай	961	846	115
45	Ютазы	240	230	10
БАРЛЫГЫ		**39 238**	**27 067**	**12 171**

Югарыда китерелгән күрсәткечләргә ясалган анализ республикада буш җир кишәрлекләре җитмәү проблемасының сакланып калуы турында нәтиҗә чыгарырга нигез бирә. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, бу проблема элеккечә Казан шәһәрендә (6 176 кишәрлек җитми), Чаллы шәһәрендә (2 540 кишәрлек), Әлмәт шәһәрендә (918 кишәрлек) кискен тора.

Җир кишәрлекләре бирелүгә исәптә торучы күпбалалы гаиләләрнең 16,6% ка артуы игътибарны җәлеп итә. Шулай, 2015 ел белән чагыштырганда, җир кишәрлекләре бирелүгә исәптә торучы күпбалалы гаиләләр саны 5 594 гаиләгә артты (2015 елда – 33 644 гаилә, 2016 елда – 39 238 гаилә), әлеге хокукны гамәлгә ашырмаган гаиләләрнең саны шулай ук 2 687 гаиләгә артты (2015 елда – 9 484 гаилә, 2016 елда – 12 171 гаилә).

Шулай итеп, күпбалалы гаиләләрне җир кишәрлекләре белән тәэмин итү мәсьәләсендәге иң мөһим проблемалар түбәндәгеләр:

буш җир кишәрлекләре җитмәү, торак пунктларның чикләрен киңәйтү өчен кирәкле шартларның булмавы;

күпбалалы гаиләләрнең исәбе арту, 2014 елдан башлап аларның саны 2 745 гаиләгә артты;

күпбалалы гаиләләрнең бирелгән җир кишәрлекләреннән баш тартуы (җир кишәрлекләре урнашкан урыннар ямьсез булганга, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура булмаганга күрә);

әзерләнгән җир кишәрлекләрен инженерлык коммуникацияләре белән тәэмин итү буенча эшләрне финанслау өчен җирле бюджет акчаларының җитәрлек булмавы яисә бөтенләй булмавы.

Моның белән бергә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында яңа проблеманың барлыкка килүе ачыкланды. Шулай, М. исемле күпбалалы ананың мөрәҗәгатен караганда гамәлдәге законнар нигезендә аның гаиләсе милкенә җир кишәрлеге бирелгән булу билгеле булды, ул кишәрлеккә алар бик яхшы бүрәнә йорт салып куйганнар. Соңыннан 7 капиталь төзелеш объекты төзелгән яки төзелә торган 45 җир кишәрлегенең бәхетле хуҗаларына әлеге җир кишәрлекләренең Миңнебай – Ижевск югары басымлы магистраль газүткәргечтән рөхсәт ителгән иң якын зонада урнашуы мәгълүм булган. Әлеге шарт дәүләт күчемсез милек кадастры мәгълүматлары буенча Менделеевск шәһәре торак пункты чикләренең әлеге генераль план чиге конфигурациясенә туры килмәгәнгә күрә барлыкка килгән, чикләр арасында 30 метрдан алып 63 метрга кадәр аерма бар.

Хәзерге вакытта күпбалалы гаиләләргә Менделеевск шәһәренең Революция Тавы урамы тирәсендә җир кишәрлекләрен, кайбер өлешләре югары басымлы магистраль газүткәргечтән рөхсәт ителгән иң якын зонада урнашкан җир кишәрлекләрен алмаштырып, түләүсез тапшыру өчен аларны әзерләү эшләре алып барыла. Ләкин әле торак йортларын сала башламаган күпбалалы гаиләләргәжир кишәрлекләрен алмаштыру әллә ни авырлык тудырмаса да, җир кишәрлекләреннән билгеләнеше буенча файдаланырга өлгергән гаиләләргә нишләргә?

Барлыкка килгән вәзгыятьне хәл итү буенча суд эшләре әле хәзергә кадәр тәмамланмаган.

3.6.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокуклары

Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшырту проблемасы алар өчен, мөгаен, иң кискен проблемадыр.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль Законның 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган тәртиптә исәпкә куелалар һәм торак белән тәэмин ителәләр. 2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә баскан торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү федераль бюджет акчалары исәбеннән Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелә. Татарстан Республикасында әлеге тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган һәм югарыда күрсәтелгән гражданнарга Федераль компенсацияләр фондыннан бүлеп

бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алуга субсидияләр бирүне күз алдында тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2016 елда Федераль бюджет акчалары исәбеннән торак шартларын яхшыртуга субсидияләр алучыларның (инвалидларның) җыелма исемлегендә инвалид балалары булган 485 гаилә кертелгән. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: 2013 елдан алып 2015 елга кадәрге чорда субсидия 11 гаиләгә бирелде, торак сатып алуга субсидия алу хокукыннан 2016 елда әлеге категориягә караган 10 гаилә файдаланды.

Моның белән бергә, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына еллык субвенцияләр күләме инвалид балалары булган гаиләләргәнең иң күбе 2% на торак сатып алуга субсидияләр бирергә мөмкинлек бирә, бу исә югарыда күрсәтелгән категорияләргә Россия Федерациясе законнары белән гарантияләнгән дәүләт ярдәмен нәтиҗәле тәэмин итә алмауның объектив сәбәбе булып тора. 2009 елдан башланган чорда аларның гомуми саны 53 булды.

33 нче таблица

Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга 2013 – 2016 елларда бирелгән субсидияләр бирү

Еллар	**Россия Федерациясе бюджетыннан субвенцияләрнең гомуми күләме*** (мең сумнарда)	**Инвалид балалары булган субсидияләр алган гаиләләр исәбе** (гаилә)
2013	122202,21	1
2014	108451,2	4
2015	115317,0	6
2016	110367,9	10
БАРЛЫГЫ	**456338,31**	**21**

*Инвалидларга, инвалид балалары булган гаиләләргә һәм хәрби гамәлләр ветераннарына торак шартларын яхшыртуга субвенцияләр күләме.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалид балалары булган гаиләләр, әгәр алар 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан булсалар, торак урыннар белән Россия Федерациясе законнары нигезендә, ягъни социаль наем йә социаль файдаланудагы торак фонды торак урынына найм шартнамәсе буенча торак алуның һәркем өчен уртак булган тәртибе буенча тәэмин ителәләр.

Татарстан Республикасында инвалид балалары булган гаиләләрнең 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан аерым категорияләре өчен «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон) торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә. Шулай, Законның 8.2 статьясында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 16 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган исемлектә күрсәтелгән һәм гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә каршы килә торган авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалар тәрбияләнә торган гаиләләрнең әлеге социаль ярдәм чарасын алу хокукы бар.

63-ТРЗ номерлы Законның 8.2 статьясын үтәү максатыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясен (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү турында» 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карар кабул итте, аның белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү тәртибе расланды. Хроник авыруларның авыр төрләреннән интегүче инвалидларга торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү буенча чаралар үткәрергә вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы билгеләнде.

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер мәртәбә акчалата түләү) бирү тәртибенең II бүлеге нигезендә күрсәтелгән категориядәге гражданнарга торак сатып алуга субсидияләр бирү 2005 елның 1 гыйнварыннан соң социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының исемлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан төзелгән субсидия алучы гражданнарның җыелма исемлеге буенча чират тәртибендә башкарыла.

Ләкин шуны билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары

буенча, 2017 елның 16 гыйнварына республика муниципаль районнары башкарма комитетлары социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куелган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 16 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган исемлектә күрсәтелгән һәм гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә каршы килә торган авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалар тәрбияләнә торган гаиләләр турында мәгълүмат бирмәгән.

Моның белән бергә суд карарлары нигезендә югарыда күрсәтелгән категориягә караган ике гаиләгә гомуми суммасы 2 176,8 мең сум булган субсидия түләнгән.

«2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 63-ТРЗ номерлы Законның 8.2 статьясында билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак белән тәэмин итүгә 2017 елда 50 000 мең сум бүлеп бирелгән. 2018 һәм 2019 елларга да шундый ук сумма каралган.

3.6.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәт хокукларын яклау


Баланың тормыш дәрәҗәсен бәяләүнең билгеле бер критерие – аны карап тоту буенча ата-ана вазыйфаларын тиешенчә башкару.

Кызганычка каршы, 2016 елда ата-аналарның балигъ булмаган балаларына алимент түләү йөкләмәләрен үтәмәве турында мәсьәләсе буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә мөрәҗәгатьләрнең саны шулай ук күп булды.

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән белешмәләрдән күренгәнчә, 2016 елда балигъ булмаган балаларына алимент түләтү турындагы суд карарларының үтәлмәвенә бәйле рәвештә 16 680 суд эше кузгатылды. Гомумән алганда, республика суд приставларының территориаль бүлекләрендә ел дәвамында 38 270 үтәтү эше буенча мәҗбүри үтәтү эшләре алып барылган. Шуларның 994 үтәтү эше аларның таләпләре үтәлүгә бәйле төгәлләнде, 11 379 үтәтү эше буенча бурычлыларның эш хакыннан алиментлар тотып калу башкарыла.

125 нче диаграмма


2013 – 2015 елларда балигъ булмаган балаларны тәэмин итүгә мәҗбүри рәвештә алиментлар түләтү буенча суд карарларын үтәү торышы



Балаларны тәэмин итү өчен алиментлар түләтү турындагы суд карарлары үтәлмәвенең төп сәбәпләреннән берсе, барыннан да элек, аларның ата-аналар тарафыннан үтәлмәвенә бәйле. Күп кенә «алиментчылар» балаларын тәэмин итүгә акча түләп тору гына түгел, хәтта яшәү һәм эшләү урыннарын да яшерәләр. Алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны 2016 елда 2 816 кешене тәшкил итте.

126 нчы диаграмма

2013 – 2016 елларда алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны



Үтәтү эше турындагы законнарны бозган өчен 2016 елда 2 084 кеше административ җаваплылыкка тартылган, бу тәмамланмаган үтәтү эшләренең гомуми санының 5,45% тәшкил иткән.

2016 елда алимент түләргә тиешле затның җаваплылыгы өлешендә законнарга үзгәрешләр кертелде. Шулай, Административ хокук бозу-

лар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35.1 статьясындагы 1 өлешендә, суд карарын яки нотариаль танылганган килешүне бозып, балигъ булмаган балаларын йә унсигез яше тулган хезмәткә сәләтсез балаларын тәэмин итеп торуга җитди сәбәпләрсез акча түләмәгән өчен, әгәр мондый гамәлләр җинаять законнары буенча җәза бирүне таләп итмәсә, ата-аналарга административ җаваплылык каралган.

Күрсәтелгән норма «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексына җинаять җаваплылыгыннан азат итү нигезләрен һәм тәртибен камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 3 июлендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелде һәм 2016 елның 15 июленнән үз көченә керде. Шушы датага кадәр тиешле гамәл өчен административ җаваплылык билгеләнми иде.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Җинаять кодексындагы 157 статьяның 2016 елның 15 июленә кадәр гамәлдә булган редакциясендә суд карары буенча балаларны тәэмин итүгә акча түләүдән махсус качкан өчен җинаять җаваплылыгы каралган иде.


2016 елның 15 июленнән, суд карарын яки нотариаль танылганган килешүне бозып, балаларын яки хезмәткә сәләтсез ата-аналарын тәэмин итеп торуга җитди сәбәпләрсез акча түләмәгән өчен, әгәр әлеге гамәлне берничә тапкыр кылган булса, мондый зат административ җаваплылыкка тартылган дип саналган чорда охшаш гамәл өчен административ җаваплылыкка тартылган затка җинаять җаваплылыгы каралган.

Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2016 елда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан алимент йөкләмәләре буенча 2 084 бурычлы административ җаваплылыкка тартылды, бу 2015 ел белән чагыштырганда (554), 3,7 тапкырга күбрәк.

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 157 статьясыннан криминал төшерелеп калдырылганга күрә, 2016 елда Россия Федерациясе Җинаять кодексының 157 статьясындагы 1 өлеш буенча кузгатылган җинаять эшләренең саны кимегән. Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тикшерүчеләре 798 җинаять эше ачкан, шулардан 571 эш буенча – гаепләү хөкеме, 112 эш буенча җинаять эшен туктату турында суд карарлары чыгарылган.

127 нче диаграмма

2013 – 2016 елларда алиментлар түләтү буенча җинаять эшләре ачу



Әлеге категориядәге төгәлләнгән җинаять эшләренең шактый артуы шулай ук Россия Федерациясе Җинаять кодексының 157 статьясыннан криминал төшерелеп калдырылу һәм административ преюдиция кертелү белән аңлатыла.

Балаларны тәэмин итү өчен алиментлар түләтү турында суд карарларын үтәмәүнең тагын бер сәбәбе бүгенге көндә алиментлар буенча зур бурычлар булуга мөмкинлек бирә торган үтәтү эшләре турындагы законнарның камил булмавында.

Соңгы елларда намуссыз ата-аналарга җәза чараларын кырыслandыру мәсьәләсе турында фикер алышулар күп булды, «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде. 2015 елда бу юнәлештә нигъаять уңай алга китеш күренде. «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законга кертелгән үзгәрешләр 2016 елның 15 гыйнварыннан үз көченә керде. Алар үтәтүче суд приставына бурычлының транспорт чарасы белән идарә итү хокукын вакытлыча чикләргә мөмкинлек бирә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: бурычлыны үтәтү документларының таләпләрен тулысынча һәм үз вакытында үтәүгә мәҗбүр итү максатыннан иң уңай һәм нәтиҗәле үтәтү гамәлләрен яки аларның кушылмасын сайлау мөмкинлеге бирү өлешендә башкару эше турындагы законнарда тулаем алга китеш бар. Билгеле инде, бурычлының махсус хокукыннан файдалануын вакытлыча чикләү алиментлар түләтү турында суд карарларының үтәлешендә мөһим профилактик чара да булып тора.

Күтәрелгән, аерым алганда, 2012 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендә гамәлләрнең милли стратегиясендә күтәрелгән икенче бер актуаль тема балалы гаиләләр арасында хәерчелекне киметүгә юнәлдерелгән чара буларак федераль алимент фондын төзүдән гыйбарәт. Кызганычка каршы, бу мәсьәлә әлегә кадәр хәл ителмәгән.


Алиментлар түләтү турында төгәлләнмичә калган үтәтү эшләренең санының кимүенә Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Ре-

спубликасы буенча идарәсе үтәтүче суд приставларының хезмәт хакыннан акча тотып калу, мөлкәтләрен ачыклау һәм аларны сатып түләттерү, Россия Федерациясеннән чыгуга чикләү билгеләү, бурычлының махсус хокуктан файдалануын чикләү, административ һәм җинаять юрисдикциясе вәкаләтләреннән файдалану рәвешендә бурычлыларга йогынты ясау чараларын кулланулары ярдәм итте.

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның мөлкәт хокуклары бозылу, аерым алганда, ата-аналардан алиментлар алуга кагылышлы өлешендә, еш кына опекуннар, попечительләр яисә тиешле дәүләт учреждениеләренең үзләренең турыдан-туры бурычларын тиешенчә үтәмәве (бөтенләй үтәмәве) нәтиҗәсе булып тора.

128 нче диаграмма

2013 – 2016 елларда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның алимент алуга хокукларын үтәүне тәэмин итүнең торышы



Югарыда китерелгән белешмәләрне анализлаудан күренгәнчә, 2016 елда ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга алиментлар түләтү турындагы 1 185 үтәтү эшенең таләпләре үтәлүгә бәйле рәвештә 264 эше генә, ягъни 22,3 % төгәлләнде (2015 елда – 172, ягъни 10,3%, 2014 елда – 271 яисә 15,8%, 2013елда – 206 яисә 12 %), әлеге күрсәткеч узган елгы белән чагыштырганда югарырак. Моның белән бергә, күрсәтелгән мәгълүмат алимент буенча бурычлыларның бары тик биштән бер өлешенең генә балигъ булмаган балаларын тәэмин итеп тору буенча үз йөкләмәләрен үтәвен күрсәтә. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, опека һәм попечительлек органнарына ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның законлы вәкилләре эшчәнлеген контрольдә тоту, ата-анадан алимент алуга хокукларын яклау һәм тәэмин итү буенча эшне көчәйтү (активлаштыру) зарурлыгы турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип уйлыйм..

ЙОМГАКЛАУ

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов 2016 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасында билгеләп үткәнчә, «Республиканың социаль-икътисадый үсешенең уңай тенденцияләре, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны, тынычлык һәм татулыкны саклау безгә иң мөһим бурычны – кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләсен хәл итәргә мөмкинлек бирә. Озак еллар дәвамында уңышлы эшләү нәтиҗәсендә үзенчәлекле капитал – ышаныч капиталы формалашты. Без халык һәм партнерлар алдындагы барлык йөкләмәләребезне үтибез, актив рәвештә республиканы яхшы якка үзгәртәбез, үзебез дә уңай үзгәрешләргә омтылабыз.» Татарстан Республикасында балаларның хәле дә уңай якка үзгәрүне танырга кирәк.

2016 елда яшь татарстанлыларның һәм балалары булган гаиләләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга корылган, нигезенә бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тулысынча тәэмин итү принцибы салынган максатчан дәүләт сәясәте дәвам итте. Әлеге сәясәтне гамәлгә ашыру өчен дәүләт структуралары, җирле үзидарә органнары, дәүләтнеке булмаган оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, балалар белән һәм алар мәнфәгатьләрендә хезмәт итә торган барлык белгечләр, ата-аналар һәм җәмәгатьчелек тырышлыгы бергә тупланды.

Бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылуның аерым очраклары булуга карамастан, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2016 елда Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен тәэмин итүне уңай дип бәяли. Бала хокукларын гамәлгә ашыруның әлеге докладта күтәрелгән аерым мәсьәләләре буенча, аларның үтәлешен тәэмин итү өчен, чаралар күрергә кирәк.

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясында каралган Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен тәэмин итү, әлеге хокукларны һәм мәнфәгатьләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан тануны һәм үтәүне тәэмин итү максатын гамәлгә ашырып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына әлеге докладны региональ сәясәтне балалар мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашыруны мөстәкыйль бәяләү һәм тикшерү механизмы итеп карарга тәкъдим итә. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, кызыксынучы ведомстволарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларыннан 2016 елда Татарстан Республикасында балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча еллык докладта бирелгән төп тәкъдимнәрне һәм рекомендацияләрне үтәү буенча мөстәкыйль һәм ихтыярый тәкъдимнәр һәм гамәлләр көтеп кала.

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча
Вәкаләтле вәкил Г.Л.Удачина

2017 елның марты